Фәрзәнә Кулеева

# Әнием – нәселем йөзек кашы

Казан 2017

**УДК 82-94**
**ББК 84 (2 Рос=Тат)6-442. 3**
**К 14**

**Кулеева Ф.**
**К 14** Әнием – нәселем йөзек кашы / Ф. Кулеева. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе нәшрияты, 2017. – 188 бит.

Китапта 17 яшендә ерак Иртыш ярларыннан килеп, Казан дәүләт университетының физмат факультетын тәмамлап, 40 ел югары математика фәнен укыткан, 20 ел буена репрессия корбаннарының оешмасын,
15 ел «Гөлҗамал» ансамблен җитәкләп, татар халык җырларын яратып башкаручы Фәрзәнә Галләм кызы Кулееваның нәселенең фаҗигале тормышы, тирән кичерешләре, балаларының, оныкларының яшәешләре белән аны горурландырулары турында язылган.

© Кулеева Ф., 2017
© ТРФА нәшрияты, 2017



# КЕРЕШ СҮЗ

Бу китабым – нәселемнең гомер тасвирламасы, чөнки монда язылган барлык вакыйгалар әнием, әтием, туганнарым хәтирәләре, үземнең истәлекләрем нәтиҗәсе.

Габделгазиз карт бабам (прадедушкам) һәм Мәликә карт әбием (прабабушкам) 19нчы гасыр ахырында ялган яла ягу аркасында җиде балалары белән Себер урманнарына сөреләләр, Габделгазиз бабам аяктагы корыч богаулары белән. Кышын чана, җәен арба тартып җәяү киләләр. Иртыш буйларындагы куе тайганың бер аланында туктап, стражниклар карт бабамның богауларын салдырып, шунда яшәргә әмер бирәләр. Шуннан хәзер танылган, Көнбатыш Себердә урнашкан, биш күл янында Малатсау дигән авылга нигез салына.

Китапта Рус-япон сугышында катнашкан әтиемнең әтисе Мөхәммәтшәриф бабамның, Беренче дө-

нья сугышында яраланып кайткан әниемнең әтисе Фәтхулла бабамның, тагын 8 туганымның 1937 елда атылулары, аларның сөякләрен Бөек Ватан сугышында саклап сугышкан 10 ир туганым, әниемнең әтием «халык дошманы» булып концлагерьга озатылгач, җәфа чигүләре тасвирлана, Туган шәһәрем Тарадагы татар мәктәбемнең барлык мәктәпләргә үрнәк булуы мине һәрвакыт канатландырды.

2017 елда Сталин репрессияләренең югары ноктасына 80 ел.

Мин китабым белән нахактан атылган, концлагерьларда, төрмәләрдә һәлак булган милләттәшләребез, ата-бабаларыбыз, туганнарыбыз, НКВД балалар йортында ата-аналарын күрү бәхетенә ирешә алмаган ятимнәр турында искә төшерәсем килде. Сталин репрессияләрендә һәлак булган зыялыларыбызга да китабымда урын бар. 20 ел буена репрессияләнгәннәргә оешма җитәкчесе буларак ярдәм итүем турында да яздым. Иң зур хыялым – Татар милли университетының ачылмауы – безнең милләтнең зур югалтуы турында ачынып фикерләрем белән уртаклаштым.

Кулеева Фәрзәнә

## 1. Алтынбаевларның Себергә сөрелүе

Себер кешесе табигате, холкы, үз-үзен тотышы белән күпләрдә соклану һәм ярату, ис китү хисе тудыра. Моңа кырыс табигать шартларында яшәү: салкын, эссе, чебен-черки һ.б. генә түгел, ә бәлки бу – кешеләрнең бер-берсенә карата булган күркәм мөнәсәбәте: ышанычлылык, намуслык, кыюлык, кирәк чакта бер береңә ярдәм итәргә әзер булу сәбәпчедер. Бөек Ватан сугышының иң катлаулы 1941 елның декабрь аен искә алсак, бер миллион себерлеләр иңгә-иң куеп, гәүдәләре белән Мәскәүне якладылар һәм һәлак булдылар.

Күптән түгел генә безнең Себер якларында (Омск өлкәсен күздә тотам) татар, урыс авыллары белән бергә поляк, эстон, чуаш, латыш, немец, украин, белорус һ. б. авыллары бар иде. Алар ничек барлыкка килгән соң? Ә бу – Россиянең төрле милләт халыкларының я бәхет эзләп, ә күпчелеге, сөрелү аркасында Себергә күчеп килүе нәтиҗәсендә оешкан авыллар ул.

Төрле милләттәге кешеләргә исән-имин калыр өчен бер-берсенә ихтирам, сабырлык белән тату яшәргә зарур була. Бу матур сыйфатлар себерлеләрдә тормыш итү дәверендә тәрбияләнә, буыннан-буынга, балаларына, оныкларына күчә, геннарына сеңә.

Минем әнием ягыннан туганнарым – Алтынбаевларга да XIX йөзнең азагында Себернең кара

урманнарына, тайгасына мәҗбүри рәвештә күчеп килергә туры килә. Карт бабам (прадедушка) Габделгазиз Алтынбаев, карт әбием (прабабушка) Мәликә җиде балалары Хәйрулла, Фатыйма, Фәтхулла, Мөбин, Сәрә, Сөләйман, Каюм белән атаклы Себер тракты буйлап китереләләр, Габделгазиз бабамның аякларында корыч богаулары була.

Мәликә әбием сөйләве буенча, күршеләре ялган акча ясап яткан һәм бөтен эш коралларын читән аша аларның бакчасына ташлаган икән. Бер көнне тентү ясаганнар, әлеге әсбапларны табып, бөтен гаиләне, олысын-кечесен Себергә сөрәләр. Нәни балаларны җәен арбага, кышын чанага утыртып, бабамнар җәяү Инсәс дигән авылны 3 чакырым узып, Тары елгасының биек ярында, юан наратлар белән уратылган бер аланга җитәләр. Шунда стражниклар бабамның аягыннан богауларны салдыралар һәм шул урында яшәргә әмер бирәләр. Алтынбаевлар белән бергә шунда тагын бер гаилә, Алим бабай һәм Садри бабай Ахмановлар гаиләсе дә утырып кала. Кыш була. Тирә якта куе урман булгач, уңган ирләр ике көндә нарат агачларыннан бурап, зур мунча җиткерәләр Шунда бала-чаганы, хатын-кызны урнаштыралар, ә үзләре шалаш корып яшиләр. Тора-бара йортлар, сарайлар, абзарлар һ. б төзиләр.

Шулай итеп, Себернең географик картасында «Малатсау» («Молодцово») дигән яңа авыл пәйдә була. Аның нигез ташын салучысы минем Габдел-

газиз бабамның булуы безнең өчен зур горурлык. Авылның атамасы ерак Идел ярларындагы туган җирнең яңгырашын, кайтавазын хәтерләтә. Сарытау (Саратов) губернасы, Кузнецов өязеннән сөрелгәннәр ирексездән себерлеләргә әвереләләр.

Мәликә әбиемнең куенында яшерен саклаган күпмедер акчалары булып, шуңа бер карт ат сатып алалар һәм җир кишәрлеге арендалыйлар. Габделгазиз бабам балалары белән ерак югалган, инде бер дә кайтып җитеп булмый торган, Россиядәге шөгыле – иген игүгә тотына. Әмма игенчелек белән шөгыльләнү җирле халыкны пошаманга төшерә, чөнки алар нигездә аучылык белән көн күргән. Килгән-килмешәкләр урман кисеп, ышна ясап, җирләрне сөрә, кыргый җәнлек-кошлар качып бетә дип каршылык күрсәткән. Нәтиҗәдә кеше гомерләре өзелгән очраклар да булган.

Тора-бара тормыш рәтләнгән, җирле халык та мунчалар төзегән, иген игүне хуп күрә башлаган. Бабаларым исән-имин яшәгәннәр дип әйтер идем, тик мунчада яшәү чорында бер ир бала телсез уянган һәм бер көнне урманга кереп югалган. Аны күпме эзләсәләр дә, таба алмаганнар. Тайгада кешене эзләү ул вакытта печән кибәнендә энә эзләү белән бер булгандыр инде.

Бүгенгедәй хәтеремдә, миңа 14-15 яшьләр, җәйге чиллә, тайгада туганнарым белән шалашта яшәп, һәрберебез заготконторага көненә 4-5 чиләк вак чия

(брусника) җыеп тапшырабыз. Кигәвен, озынборын, чебен-черки болыт кебек булып, аларның зыңлавы бер музыка иде. Шулар битемне тешләп, күзләремне күренмәслек итеп шештергәнәре әле дә хәтеремдә.

Әнием сөйли иде: Габделгазиз бабам баһадирдай озын буйлы, таза, көчле булган. Уңганлыгын сөйләп торасы да юк, гаиләсе белән бергә эшләп, яңа шартларда мул, бай тормыш төзегән. Күп итеп мал асраган. Елгага су эчерергә көтүен алып төшкәндә малларының бер очы су янында булса, икенчесе капка төбендә булган. Бабамның ат көтүе дә булгач, әлбәттә, мал туарга печән күп кирәк булган, аны махсус үлән чабу, җыю машинасы башкарган.

1917 елда, 80 яшьлек Габделгазиз бабам төпчек улы Каюм белән йортын сүтеп, үз җилкәсендә бүрәнәләрне ташып, Тара, Иртыш, Аркарка елгалары буенча сал итеп агызып, Тара шәһәренә күчереп сала.

Бер гасыр элек төзелгән йорт минем туган шәһәрем Тараның Нерпинская урамы, 20 адресы буенча әле һаман тора, 2015 елда туган якка кайткач, йортны махсус барып карадым. Бүрәнәләре гәрәбәдәй шыгырдап тора, нигезе җиргә сеңергә уйламый да, анда һаман да кешеләр яши. Әмма минем туганнарым тугел шул! Шунда уйлап куйдым, ничек Габделгазиз бабам шундый мәһабәт, нык йорт салды икән! Бирегә мин бала чагымда Каюм бабай белән Гайшә әбиләргә еш килә идем, алар озак, бик

тату матур яшәделәр, урыннары оҗмахта булсын! Кайчан карама Каюм бабай култык астына каен себеркесен кыстырып, мунча юлында иде. Бәлки шуңадыр ул 105 яшькә җитеп, бакыйлыкка күчте. Гайшә әби дә озын гомерле булды, аларның кабер-ләре Тараның иске зиратында, авыр туфраклары җиңел булсын!

Габделгазиз бабамның тырышлыгы һәм аның уң-ганлыгы балаларына, оныкларына, онықчыкларына (правнуки) күчте. Мин шәхсән үземне дә күбрәк Ал-тынбаевлар нәселенә кертәм. Алтынбайлар нәселе башкаларга үрнәк булырдай итеп яшәделәр, яшиләр һәм, ышанып әйтәм, яшәячәкләр. Аларның һәрбер-сенең, ир-ат булсынмы, хатын-кызмы зур йорты, бакчасы, мал-туары, кош-кортлары, тулы хуҗалыгы гөрләп тора иде. Хәзер инде туганнарымның уңай-лыклары булган, яхшы җиһазландырылган фатирла-ры, иркен коттеджлары, затлы машиналары, дачала-ры бар.

Үзем дә күп көчем кергән 4 бүлмәле кооператив фатирга, менә дигән бакчага ия. Аллаһның рәхмәте, балаларым, оныкларым да тырышып матур тормыш алып баралар. Быел, 2016 елда, 30 яшьлек оныгым Тимур һәм 29 яшен дә тутырмаган оныгым Артур бер елда коттеджлар төзеп, гаиләләре белән күче-неп, яши башладылар, икесе дә малай белән кыз үстерәләр. Йортларын тизрәк төзеп бетерер өчен оныкларым көне-төне, армый талмый эшләделәр.

Санап, мин шуны ачыкладым, әниемнең әтисе Фәтхулла бабам 1937 елда атылган, бу котычкыч факт аның реабилитацияләнү (аклану) белешмәсендә язылган, ул чакта аңа 58 яшь була, 1937 ел – 58 яшь = 1879 ел. Димәк, Фәтхулла бабам 1879 елда туган. 17 яшендә ул Себергә гаиләсе белән сөрелгәндә, 1879 ел + 17 яшь = 1896 ел була. Шулай итеп, Габделгазиз бабамнар Себергә 1896 елларда сөрелгәннәр.

Сталин репрессияләрендә ата-бабаларымны атып, тамырларыбызны корытырга тырышсалар да, моңа ирешә алмаганнар. Мәсьәлән, мин дүртенче буындагы (әнием ягыннан) кайбер туганнарымны хәтерлим әле. Минем кадерле Габделгазиз бабама һәм Мәликә әбиемә балаларым Айдар белән Җәмилә – бишенче буын, оныкларым Тимур, Артур, Марат, Мәрьям, Әскар, Әдилә – алтынчы буын, оныкчыкларым Артур, Кәрим, Амалия, Радель, Регина – җиденче буын варислар булалар.

Малатсауда Габделгазиз бабам белән Себергә килгән балалары үсә, үз гаиләләре белән яши башлыйлар. Кагыйдә буларак, төпчек малай эти-әни йортында торып кала, төпчек – Каюм бабай була.

1907 елда минем булачак бабам Фәтхулла Габделгазиз улы Алтынбаев булачак әбием Бибигәзизә Сибгатулла кызы Хәмитовага өйләнә. Бибигәзизә әбием бик матур, зифа буйлы, озын каштан толымлы була, чәчен тараганда эскәмиягә басып тарый иде дип әниемнең сөйләгәне бар. Минем чәчем дә

әбиемнекегә охшаган, кояшта бронза кебек ялтырый. Еш кына буядыңмы әллә, Фәрзәнә, дигәч, көлә идем, безнең яшьлектә кая ул чәч буяу, иннекне дә 40 яшемдә генә беренче мәртәбә сөрттем, шуңа күрә үз яшемне бирмиләрдер. Чәчем әле дә билемә кадәр, бу Гәзизә әбиемнең мирасы дип уйлыйм.

Фәтхулла һәм Бибигәзизә гаиләсендә беренче булып, 1908 елда әнием Васфиҗамал дөньяга килә. Аннан соң янә 5 бала: Гарифулла 1910 елда, Әсхәпҗамал 1912 елда, Калимулла 1914 елда, Муллагали 1916 елда, Хәтифә 1918 елда. Әниемнең сөйләгәннәренә караганда, алар нык тату эшчән гаиләдә үсәләр, Фәтхулла бабам караңгыдан караңгыга кадәр үзенең хуҗалыгында эшли: иген игә, күп итеп мал-туар асрый. Яз җитүгә Малатсау авылы халкы, шул исәптән бабам да олауларга җыелып, такталар, мичкәсе белән сумала, дегет, мүк җиләге, эрбет чикләвеге, сары май – бу барлык байлыкны көньяк ярминкәләренә алып барганнар. Шулар урынына төрле сорттагы он, ярма, мануфактура, хуҗалык кирәк-яраклары алып кайтканнар.

Бу матур тормышны 1914 елда Беренче бөтен дөнья сугышы җимерә. Фәтхулла бабамны, аның энеләрен Мөбин һәм Каюмны сугышка алалар. Фәтхулла бабам яралана, аның уң кулы хәрәкәтләнмәс булып кала. Әлбәттә, бу бик зур фаҗига була, чөнки аның бөтен көнкүреше авыр физик эш белән бәйләнгән бит. Яралы госпитальдә ятканда, солдатларның

хәлен уртаклашырга дип патша Николай II кызлары килеп йөри, алар тәм-томнәр китерә, хәл-әхвәлләрен сорашып, тизрәк терелеп, гаиләләренә кайтуларын теләгәннәр. Бабам сәлам хатларны шигырь белән язган.

1918 елда гаиләдә алты бала үсә: иң олысы минем әнием Васфиҗамалга 10 яшь, ә төпчек кыз Хәтифәгә биш ай була. Әнием истәлекләреннән: «Әниебез казан тутырып тәмле аш-су әзерли иде, бер көнне итле ботка булса. икенче көн итле аш була, әни ипине үзе сала иде. Без барыбыз да сәке остендәге тәбәнәк өстәл артына аяк бөкләп утырып ашыйбыз да кайвакыт, төрлебез төрле якка тәгәрәп, йоклап та китәбез».

Бер көнне Гәзизә әбием елгага төшеп, чиләгенә су алганда, кинәт давыл чыгып, судан бер мәет торып баскан. Әлбәттә, әбием бик каты курыккан, бу курку аның башына җиткән дә. Ул авыруга сабыша, урын-җиргә ята. Аның авыруы озакка сузылмый, бер мәлне авызыннан да, күкрәгеннән дә сөт урынына кан килә башлый, кечкенә Хәтифә имми башлый, имидән аерыла. Әбиемнең бөтен кайгысы: «балаларым кем кулына калырлар икән», – дигән уй була. Аның хәле менә шул дүрт юллы шигырьдә ачык чагыла, күңеле тулганда, ул шуны җырлаган:

*Лимон сары, лимон сары,*
*Санап чыкмый бөтене,*
*Эчләремдә ут янсада,*
*Тышка чыкмый төтене.*

Табиплар фикеренчә әбекәемнең йөрәгендәге бер клапан ябылмый калган икән. Бүгенге көндә, операция ясап, әбием бәлки исән дә калган булыр иде. Бу фаҗига 1918 елда булган. Ул чорда билгеле булганча, Россиядә гражданнар сугышыы бара, аның ялкыны Себерне дә читләтеп узмаган. Әнием сөйләве буенча, авыл аша я аклар, я кызыллар узганнар, өйдә авыру барын ишетүгә, йогышлы авыру дип бусагадан да атлап кермәгәннәр. Тик шулай да бабамның яхшы атларын алып киткәннәр. Утызны да тутырмаган әбием шәм кебек сунә.

Бу вакытта әниемә нибары 10 яшь була, аның җилкәсенә барлык авырлык төшә: мал-туар карау, ипи салу, эне-сеңелләрен тәрбияләү, бөтен хуҗалык эше. Алты бала ятим кала, әни булмагач, ятим инде. Әлбәттә, әниемә мәдрәсәдә укуын да ташларга туры килгән, гәрчә үзе бик зирәк һәм зиһенле кыз булса да. Ул яттан дин китаплары белгән. Шулай итеп, газиз әнкәенең куенындагы бәхетле тормышы челпәрәмә килә.

Баласыз кешеләр биш айлык Хәтифәне асрамага сорыйлар, ләкин аның апа-абыйлары: «бер кемгә дә бирмибез, үзебез карыйбыз», – дип нык торалар. Әнием сөйләгәннәрдән: «Хәтифәне йокларга яткан-да энем Гарифулла белән уртабызга сала идек». Әбием авырганда күрше тол хатын Миннехәят апа балаларны караша, хуҗалык эшләрендә булыша. Фәтхулла бабамның туганнары ул балаларны ка-

рашты, балалар да аңа ияләнде дип аны бабама димлиләр.

Фәтхулла бабам риза була, бер елдан алар өйләнешәләр. Миннехәят, миңа үги әби була инде, балаларны ашау ягыннан кысмый, тик каты бәгырле, кызу канлы булып, балаларны кыйный, кулында ни булса, утын пүләнеме, кисәү агачымы, шуның белән ора торган була. Балаларның башларында, тәннәрендә җәрәхәтләр булып, «әтиегезгә әйтеп кенә карагыз, мин аны үтерәм», – дип куркыта. Ә Фәтхулла бабам көне-төне эштә була, көз җитүгә гөмбә, мүк җиләге җыя, балык тота, күмер яндыра һәм шул хәзинәне көймәгә төяп, су юлы белән барып, сата. Аңа, сугыш инвалидына, гаиләсен тәэмин итәргә җиңел булмагандыр.

Гәзизә әбиемнең кыз туганы Мәрфуга апа әниемнәргә килеп, кызларның канга баткан киезләнгән чәчләрен елый-елый тарый. Бабам кайткач, аңа бөтенесен дә сөйли, бабам сугыш чукмарын куып та карый, ләкин үги ана ялына, тәүбә кылып, «балаларны яратам, инде кыйнамам», – дип сүз бирсә дә, гаилә башлыгы эш белән сәфәргә киткәндә, барыбер, балаларны кыйный һәм хәтта базда тота. Эне-сеңелләре җәберләнгәндә әниемнең йөрәге әрнегәндер.

Алты бала өстенә килгән, ялгыз яшәгән Миннехәят әби белән уртак тел табуы кыен булуын аңларга мөмкин. Кырыс табигатьле бу хатын балаларны кыйнап тәрбияләү ягында булган, чөнки хәт-

та үзенең туган балаларын да, оныкларын да суккалап-каккалап үстерде. Әмма Миннехәят әбинең бер яхшы ягы бар иде – ул ифрат кунакчыл, юмарт булды. Өйгә берәр чит кеше килеп керү белән, самавырын куеп, табын әзерләр иде.

1922 елда Фәтхулла бабам гаиләсе белән Тара шәһәренә күченгән. Бу чорда гаилә яңадан бер кешегә – бабамның Миннехәят әбидән туган улы – Сафиуллага арта. Күченү вакытында юлда Уба авылында тукталып, табын корганда бу сабый, самавырга пешеп, авыртуга чыдамастан Тарага җиткәнче үкереп елап бара. Үсеп җиткәч, Бөек Ватан сугышы вакытында шушы абыем 21 яшендә танкында икенче булып Берлинга бәреп керә. Хәзер дә күз алдымда Сафиулла абыемның бөтен күкрәге орденнар, медальләр белән тулы иде.

Тара – Себердә данлыклы шәһәр, беренчедән, заманында биредә атаклы Күчем-ханның хәрби ставкасы булган. Икенчедән, күренекле милләтпәрвәр, мәгърифәтче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы һәм публицист, сәяхәтче Габдеррәшит Ибраһимовның туган каласы, өченчедән, Себергә сөрелгән халыкның барысы да диярлек Тара аркылы узган.

Әлеге шәһәр Иртыш (Җиртиш) һәм аңа койган Аркарка елгалары буенда урнашкан. Октябрь революциясенә кадәр шәһәрдә 14 чиркәү һәм бер мәчет булган. Революциядән соң чиркәүләрдән берсе генә кала, мәчетне һәм аның каршында эшләп кил-

гән, татарларга мәгърифәт нуры тараткан мәдрәсәне җимерәләр. Калган чиркәү биналары ат абзары да, склад та, музей да булып файдаланылды.

Тара татарлары һәм дин кардәшләре берләшеп иганәчеләр ярдәме белән ике мәчет торгызды. Аллаһның биргәненә шөкер, шул ике манарадан азан яңгырый.

Тарага күчеп килгәч, Фәтхулла бабам Нерпинская урамы, 51 нче йортны сатып алган. Авылдан алар өч олау азык-төлек, өч олау йорт җиһазы, көнкүреш кирәк-ярагы, эре терлектән өч сыер һәм өч ат алып киләләр. Бабам чана, арба, тәгәрмәч, кошевка ише әйбер җитештерүче инвалидлар артеленә эшкә урнаша. Моннан тыш ул йөк ташу белән дә шөгыльләнә. Миннехәят әби янә алты бала таба. Игезәк ике кыз бала яшьли үләләр, ә бишесе: Сафиулла, Рәхмәтулла. Зәнфирә, Хаҗәр, Нурҗиһан исән-имин үсәләр, гаиләдә барысы 11 бала була, уңган туганнарымның урыннары җәннәттә булсын!

Тарага күчеп килгәндә, әниемә 14 яшь була. Ул үзлегеннән тегәргә өйрәнә һәм өйдәгеләрнең барысына, туган-тумачага киемнәр тегә, әмма бу хезмәте өчен беркем дә аңа сукыр бер тиен дә түләми. Барысы да киләчәктә, кияүгә чыкканда бәхилләтергә вәгъдә итеп котыла. Әнием гаять чибәр, зифа буйлы кыз булып җитешә. Көтү озатканда, каршы алганда, чиләк-көянтә тотып су буена барганда аңа егетләрнең күзе төшми калмагандыр, Бервакыт әнием кер

чайкаганда басмада аягы таеп, суга егылып төшә. Ул чакларда хәтта минем бала чагымда Аркарка елгасы зур сулы була иде. Аңа хәтта баржалар, аларны тартып йөрүче буксир катерлар да керә ала иде, хәзер ул кипкән инде, хәтердә һаман якты нур кебек ялтырый. Шунда, яр буенда зур 5 х 5 метр, бәлки зуррактыр да басма бар иде, шул басманың башыннан әнием суга төшеп китә дә инде. Су буенда булачак әтием Галләметдин, аның туганы Абуталип һәм башка егетләр сүз көрәштерәләр, кем Васфиҗамалны коткара, нәкъ шул егет аңа өйләнә имеш. Шунда ук, басмада бер хатын-кыз була, әнием кинәт калкып чыкканда, әлеге апа аны чәченнән эләктереп, басмага чыгара. Шулай итеп әнием исән кала, егетләр авызларын гына ачып калалар.

## 2. Кулеевлар нәселе турында

Болгар, гагауз, кыпчак, ногайлар һәм башка төрки халыклар үз нәселләрен ким дигәндә тугыз буынга кадәр белгәннәр. Илебездәге Сталин репрессияләре аркасында бу күркәм традиция юкка чыкты. Ата-бабалар үзләренең тамырларын белмиләр Мин әнием ягыннан туганнарымны тулы булмаса да дүрт буынын беләм, әлбәттә, күреп түгел, ә әнием сөйләгәннәрдән. Әтием ягыннан өченче буынны, әмма алар турында мәгълүмат бик сай. Алтынбаевлар турында әнием сөйләсә, әтием ягыннан сөйләүче булмады диярлек, аз-маз булса да белешмәләр бар. Әнием сөйләве буенча әтиемнең әтисе – бабам Кулеев Мөхәммәтшәриф Әбүбәкер улы турында дөреслекне безнең гаилә 1990 елда гына белде. Шул елны без бабамның реабилитацияләнгәнлегенә, акланганлыгына белешмә алдык. Аның исеме дә кыскартылып, Кулеев Шәрип Бакировичка әверелгән иде. Шунда ук аның атып үтерелүе турында да белдек.

Бабамның төп чыгышы Сембер губернасы, Буа шәһәрендә тууы хакында да хәбәрдар булдык. Хәзер Буа Татарстанга керә. Бабам тире эшкәртүче гаиләсендә 1864 елда туган, Тара каласына авыру әнисе, энесе Рәхим, сеңлесе Зарифа белән алар җәяү килгәннәр. Җәен арбаларын тартып, кышын юл өстендәге авылларда кышлап калганнар. Шәһәрдә урнашкач, бабам тегүчелек белән кәсеп итә башлый.

Туннар, төрле фасонда ирләр баш киеме тегә, гомүмән, кием тегүдә, осталыкта, пөхтәлектә аңа шәһәрдә тиңнәр булмый.

Тарада Мөхәммәтшәриф бабам минем булачак әбием Гани кызы Фәгыйләгә өйләнә. Бу никахтан туган балалардан алтысы исән кала: Минзифа, Хөснинур, Сәрвәр, Мирсаеф, әтием Галләметдин һәм төпчек бала Гайнетдин. Шәриф бабам Ерак Көнчыгышта рус-япон сугышында катнаша, Маньчжуриядә 9 елга якын гомерен сарыф итә һәм шуннан соң, гаиләсе янына яраланып, имгәнеп кайта да җиң сызганып эшкә тотына. Тормыш дәвам итә. Кеше көнләшерлек хезмәт сөючән булганга, бабам акча туплап, Нерпинская урамында ике катлы йорт сатып ала. Бабам искиткеч хәтергә һәм сәләткә ия була: армиядә хезмәт иткән чакта ул камил рәвештә кытай, япон телләрен өйрәнә, әлбәттә, урыс телен дә яхшы белә.

Тара каласында йөзгә якын милләт вәкиле яшәгәне билгеле, кем генә сөрелмәгән дә кем генә үз иреге белән иксез-чиксез Себергә килеп тормыш кормаган. Гаҗәп бит, туган телләрен онытмас өчен кытайлар бабама кытайча сөйләшергә килә торган булганнар. Ел саен көзен кыр эшләре тәмамлангач, бабамның рус-япон сугышында катнашкан полкташлары аулак өйгә җыелганнар. Бу очрашуларТара округының яңадан яңа авылларында, чиратлашып полкташларның йортларында узган. Солдатлар хәр-

би тормышның авырлыкларын, үзләренең командирларын, һәлак булган иптәшләрен искә алганнар, яңа тормыш вакыйгалары турында фикер алышканнар. Шәриф бабам бу очрашуларның «җаны», оештыручысы булган, хәтере яхшы булгач, ул хәрби хезмәтнең нечкәлекләре турында түкми-чәчми тәфсилләп сөйләгән.

1926 елда әнием Васфиҗамал Фәтхулла кызы белән әтием Галләметдин Мөхәммәтшәриф улы өйләнешәләр. Тарада туганнарыбыз күп була. Әниемә туйда күп кенә затлы бүләкләр бирәләр: атаклы «Зингер» тегү машинасы, идәннән түшәмгә тиеп торган матур итеп инкрустацияләнгән көзге, саф мәрҗәннән ал төстәге муенса, ул вакытта шул муенса бер сыер бәясе торган, күлмәклекләр, урын-җир, бизәнү әйберләре: комплектта алтын алка брошкасы белән, аны әниемә Фәгыйлә әбием бүләк итә, 1938 елда әнием өйдән балалары белән куылгач, брошканы өй алганда сата, алканың әле дә берсе миндә саклана, йөзекләр, бозавы белән сыер, аларны әтиемнең апасы Хөснинур тәтә җитәкләп китерде дип әнием сөйләгән иде. Әнием әйтә иде: «кайната белән кайнана өе тагы да ямьләнеп китте, бәрәкәт инде», – дип.

Әнием яңадан зур ишле гаиләдә яши башлый. Мөхәммәтшәриф бабам киемнәр тегә, гаиләне тәэмин итә, әтием Галләметдин мәктәп директоры булып эшли. Башлангыч мәктәпне җидееллыкка әйләндерү өчен күп көч куя. Ә бөтен өй эше әни-

ем өстендә була: ашарга пешерү дә, кер юу да, су китерү дә, мунча ягу да кунакка килгән туганнарны: әтиемнең өч апасын, абыйсын, энесен, балаларын тәрбияләп, сый-хөрмәт күрсәтү дә аның җилкәсендә була.

Бабамнан башкаларга әнием килен кеше ким кеше булып санала. Әтиемнең кыз туганнарының кочак-кочак керләрен юа, аның хәтта селте белән куллары ашалып бетә. Әниемне бабам гына яклап, хөрмәт иткән, чөнки ул үзе дә тормышның ачысын-төчесен күргән кеше бит.

1928 елда беренче бала булып Фәрхәнә апам дөньяга килә, әнием бала табарга җыенып йөргәндә, мунча кергәндә, бик курка. Морҗадан ут шары чыгып, яныннан үтеп китә, әнием һушы китеп егыла. Ихтимал, бу шарлы яшен булгандыр. Без бала чакта шайтан ут шары булып, очып йөри диләр иде. Әнием аңына килә һәм берничә көннән кыз бала таба. Аңа Фәрхәнә дип исем кушалар. Апам 9 айлык чагында менингит белән авырый. Әниемнең куркуыннанмы, әллә шушы авырудан апам чукрак булып кала. Аны кемнәргә генә күрсәтмәгәннр, кая гына алып бармаганнар, табиплар да, им-томчылар да калмаган. Телдән ризык пешергәндә әнием аның очын апама ашата иде. Кемдер әйткән имеш файдасы тия дип, бернәрсә дә ярдәм итмәде.

Фәрхәнә апам бик матур, зифа буйлы, шомырт кебек кап-кара чәчле, эшкә уңган-булган, оста те-

гүче иде. Сугыш елларында абыем белән мине тәрбияләде. Әнием хәрби заказны үтәп, һөнәрханәдән кайтып керми иде. Әнием бала табып өлгерми, тагын өй эшләренә чума. 1929 елның 30 октябрендә икенче апам Фәһмия дөньяга килә. Шул вакытта Минзифа тәтәмнең дә малае туа, бер үк вакытта әнием дә, тәтәм дә бала табу йортыннан кайталар, Минзифа тәтәй, мин малай таптым дип, караватта баласын кочаклап утыра, ә әниемә, килен кеше ким кеше дигәндәй хуҗалык эше. Беренче баласына бер яшь. ә икенчесе яңа гына туган, ничек чыдады икән энекәем! Өйдәге бөтен ардага, олысы-кечесенә ризык пешереп, барысының керләрен юып, өй җыештырып, эштән бушаган арада Мөхәммәтшәриф бабамның тегүчелек эшенә булышып, балаларын үстергән. Шулай итеп, әнием үги ана белән яшәп, яңадан зур гаиләгә туры килә һәм анда да авыр көндәлек хезмәттә гомер кичерә.

## 3. Канлы репрессияләр – минем нәселем дә фаҗигасы

Миңа калса, егерменче гасыр тарихта СССР һәм Россия халыклары язмышында иң дәһшәтле, фаҗигале чор булып калыр. Әгәр һәрбер гасырны ниндидер бер төскә буый алсак, 20 нче гасыр кызыл төстә булыр иде, чөнки кызыл төс, ул кан төсе. Безнең ил кичергән трагедияләр санап бетергесез. Бу – рус-япон сугышы, 1905 ел революциясе, беренче Бөтен дөнья империалистик сугыш, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы. Бу – авылларда көчләп күмәк хуҗалыклар төзү, аларны коллективлаштыру һәм шуның нәтиҗәсендә, эшчән, тырыш авыл кешеләрен «кулак» дип тамгалап, сыйныф буларак юк итү һәм илдәге коточкыч ачлык. Мәчетләрне, чиркәүләрне җимерү. Бу – үз халкың өстендәге репрессия, күпме челпәрәмә килгән язмыш, киселгән гомер!!! Ниһаять, БөекВатан сугышы дистәләгән миллион кешенең тормышын алып китте. Ә күпме гөнаһысыз зат концентрацион лагерьларда ятып калды, аларның гаебе – әсирлектә булу иде.

20 нче гасырда безнең ил кебек фаҗигалар кичергән ил юктыр. Бу фаҗигаларның иң коточкычы дип Сталин репрессиләрен санап була. Кешеләрне сугышта, дошманга каршы яуда түгел, ә тыныч тормышта күпләп юк иттеләр. Мәгълүматлар буенча Россиядә 1923 елдан 1953 еллар арасында 41 млн.

кеше кулга алына, әмма бу сан тулы түгел, чөнки бу статистикага 10 миллион репрессияләнгән крестьяннар һәм депортацияләнгән халыклар кермәгән.

1956 елда, КПСС ның XX нче съездында Н.С. Хрущевның «Сталинның шәхес культы һәм аның нәтиҗәләре», дигән докладны яңгырый. Әлеге докладта 1930 еллардагы партиядәге чистартулар, КПСС ның XVII съезды (1934) делегатлары язмышы, С.М. Киров үтерелгәч, репрессия масштабларының киңәюе турында әйтелә, моны Сталинның 383 атарга хөкем ителгәннәрнең исемлеген раславы дәлилли. Бу исемлектә: партия – совет, хәрби, хуҗалык хезмәткәләре һәм гади халык була, шулай ук докладта НКВД ның Сталиннан төрле җәзалау (пытки) ысулларын кулланырга рөхсәт алуы ачыклана. Н.С. Хрущев үзе дә репрессияләрдә катнаша, аның, Мәскәүдә һәм Украинада эшләгәндә күп кешенең башына җитүе билгеле.

Өлкәләрдә, союздаш республикаларда НКВД тарафыннан үткәрелгән репрессия масштаблары тетрәндерә. Шундый планлы рәвештә халыкны күпләп кырып бетерүне бөтендөнья тарихы әле белмәгән. Бүген Европаның хокук яклаучы оешмалары иле бездәге коммунистик режимны фашистик режим дип тамгалауны алга сөрә. Хәзерге көнгә кадәр Советлар Союзының Верховный Суды, Россиянең Конституция Суды Сталинның җинаятен карамады-

лар һәм бөтендөньядагы иң коточкыч җинаятьчегә хөкем чыгармадылар. Бу – Бөек Ватан Сугышында безнең халыкның нацист Германияне Җиңүен ялгыш Сталин җиңүе дип атаудан килә.

Гәепсездән репрессияләнгәннәрнең үзләре, балалары, хатыннары, ата-аналары, туганнары дистәләрчә еллар буенча «халык дошманы» к у ш а - матын күтәреп йөрделәр, дистәләрчә меңләгән хатыннар балаларыннан аерылып 8-10 елга төрмәләргә ябылып, лагерьларга озатылдылар, ә аларның бертуган балаларын бер-берсеннән аерып, төрле шәһәрдәге НКВД карамагындагы бала йортларына җибәрделәр, исем-фамилияләрен үзгәрттеләр, күпләре ата-анасын күрү бәхетенә ирешә алмадылар.

Билгеле булганча, 1919 елда ук безнең илнең тарихында беренче мәртәбә «Мәҗбүри хезмәт лагерьлары» барлыкка килә. Нәкъ шул елның 11 апреленда ВЦИК Президиумы «Мәҗбүри хезмәт лагерьлары» турындагы карары белән концентрацион лагерьларның барлыкка килүен һәм аларның эшләүләрен законлаштыра. Шул документтан репрессия аппаратының һәм хезмәт белән төзәтү лагерьларының (исправительно-трудовые лагеря) оештыру этабы башлана. 1930 елда ОГПУ ның алты хезмәт белән төзәтү лагерьлары идарәсе формалаша. Бу – Төньяк Кавказ, Ак диңгез районы һәм Карелия, Вышний Волочек, Себер, Ерак Көнчыгыш һәм Казахстан.

1934 елда НКВД төзелә һәм бөтен лагерьлар Гулаг, (Главное управление лагерей, Лагерьларның баш идарәсе) системасына керә.

«Зур террор» елларында масса-күләм репрессияләр белән партия җитәкчелек итә, КПСС Политбюросы, Сталин һәм аның даирәсе кешеләрне ату яисә концентрацион лагерьларга озату планын, «лимитлар «билгелиләр, раслыйлар.

Даһи юлбашчы Бөек Ленин авызыннан беренче булып концентрацион лагерьларга дин әһелләрен, дворяннарны, зыялыларны һ.б. ны урнаштыру турында, баш күтәргән өязләрдә 100 кешене аттыру яисә асу, һәрбер 10 нчы кешене аттыру, урысча әйткәндә, «чтобы другим неповадно было» дигән сүзләр чыга.

Гитлерга баш ватырга туры килми, күз алдындагы безнең бай үрнәк ярдәмендә ул чит илләр халкын планлаштырылган рәвештә юк итүгә килә. Гитлерның халыкны юк итү технологиясе халыкара трибунал тарафыннан кешелек дөньясы алдында җинаятьлек дип танылды. Тик Сталинның үз ватандашларын планлы рәвештә юк итү режимы халыкара тарафыннан да, Россия ягыннан да юридик яктан бәяләнмәде дә, бу җәлладка хөкем дә чыгарылмады.

Күп еллар дәвамында репрессиягә дучар булганнар үзләренең хәсрәтләре, фаҗигале язмышлары турында хезмәттәшләре таныш-белешләре, хәтта туганнары белән уртаклашмаска тырышканнар.

Үзләренең өстендә «халык дошманы» я «халык дошманы» гаиләсе әгъзасы, я «кулак» тамгалары ятканын белгертергә курыкканнар.

1991 елның 18 октябрендә Россия Федерациясенең «Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү» законы чыккач кына, күпләргә ниһаять шушы тамгалардан котылырга мөмкинлек булды. Реабилитация һаман дәвам итә әле.

Хәтта 30 октябрь – сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне ирек өчен көрәшкән һәм шул көрәштә җиңеп чыккан сәяси әсирләр казанышы. 1974 елның 30 октябрендә Мордва һәм Пермь лагерьларының сәяси әсирләре ачлык игълан итү белән сәяси әсирләр көнен билгеләделәр. Һәм 1991 елның 18 октябрендә Россиянең Югары Советы карары белән 30 октябрь көне дәүләт календарена «Сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне» булып керде.

Кайчан кешелек җәмгыяте, халыкара суды, ниһаять, Россия дәүләте репрессия корбаннары алдында гаебен таныр, кайчан гафу үтенер, аларга бурычын түләр икән! Николай патша һәм аның гаиләсе бөек газап кичерүчеләр булып танылды, ә Сталин репрессияләре нәтиҗәсендә газап чиккән тоткыннар, кыйналып, аяк куллары сындырылып, ахыр чиктә атылган яисә ач күселәргә азык булган (Раифа монастыре төрмәсендә) кемнеңдер газиз әтиләре, уллары, туганнары бөек газап кичерүчеләр түгелме! Гулаг лагерьларында, төрмәләрдә газап чиккән ке-

шеләр җаннарын сыкраткан сорауга кабат-кабат җавап эзлиләр: ни өчен безнең халык мондый геноцидка дучар булды, ни өчен бернинди гаебе булмаган миллионнарча кешеләр атып үтерелде, Себердә, Колымада туңып ачлыктан үлде, сал агызганда батты, ятим калган балалар интекте, һәлак булды!

1937 елның канлы репрессияләре башлангач, минем газиз туганнарым да шул геноцидка дучар булалар. Туган шәһәрем Тарада Октябрь революциясенең 20 еллыгы уңаеннан, ноябрь аеннан башлап, 1938 елның башына кадәр энә очы кадәр дә гаепләре булмаган 350 ләп кеше кыйналып, җәзаланып, җәзаларга түзә алмыйча, бәлки исән калуларына ышанып, эшләмәгән җинаятьләрне танып, җәзалардан үлгәннәр яисә атылганнар. Сорау алу көннәрендә «халык дошманнары» процессиясенең башы базар мәйданындагы НКВД да булса, ахыры – төрмәдә, ә бу өч километрга якын ара, үзләре бара алмаганнарны ат арбаларына төяп алып баралар, миңа бу юлларны язу бик авыр, чөнки бу процессияләрдә, инанам, минем туганнарым да булган.

1937 елның октябрь аеның төнендә, барлык кешеләр йоклаганда, К-Либкнехт урамындагы 51 нче йортның капкасын дөбердәтеп йорт хуҗасын аякка бастыралар. Фәтхулла бабама киенергә кушыла, ул өйдәгеләрне тынычландырырга тырыша, җиде айлык сабый баласын – Нурҗиһанны үбә һәм мәңгегә югала. Бу чакта аңа нибары 58 яшь була. Бер

кулы зәгыйфь, искиткеч кешелекле, сабыр, тырыш 11 бала атасы.

Нәкь шул төнне Фәтхулла бабамның сигез ир туганын кулга алалар Менә алар: Сәлахетдин Ахманов бабамның сеңлесе Сәрәнең ире, биш бала атасы, Зәйнулла Рәхматуллин бабамның апасы Фатыйманың ире, тугыз бала атасы һәм аның уллары Самигулла – 23 яшьтә, Мостафа – 21 яшьтә. Ибраһим Яхеев Фәтхулла бабайның туганнан туган сеңлесе Мәүлиханың (Фатыйма апаның кызы) ире, биш бала атасы абыйлары Каюм Яхеев, ике бала атасы һәм Идрис Яхеев өч бала атасы, Гәйзулла Хәмитов Гәзизә әбиемнең абыйсы ике бала атасы. Аларның берсе дә кире әйләнеп кайтмый. Мөхәммәтшәриф бабамны кичке ашны ашарга җыенганда алып китәләр. Бабам әниемә; килен, хәзер кайтам, көтегез, дип чыгып китә. Ул да кайтмый. Аңа 73 яшь була, ә ул вакытта закон 70 яшь тулган граждannарны кулга алудан тыйган, бабамны барыбер алып киткәннәр.

Балалар, хәләл җефетләре, барлык туганнар кулга алынганнарны көтәләр, әнә кайтырлар, менә кайтырлар дип, чөнки аларның бернинди дә гаебе булмаганын яхшы белгәннәр. Мөхәммәтшәриф бабам кайтмагач, әнием 9 яшьлек Фәһмия апамны бер шешә сөт һәм ипи тоттырып, бабам янына җибәрә, апам кайткач, сөйләгән: үзенең каравылчыларның араларыннан үтеп, бабамны табып, ризыкны

тапшыруын, тоткыннар аягүрә басып, тәкбир әйтеп торганнар икән.

Шул көндә кулга алынган 350 кешенең язмышын әниемә Бөек Ватан сугышы вакытында күрше Сәйбаттал абый сөйләгән. Ул милициядә эшләгән иде. Сәйбаттал абый Гәйшә тәтәй белән безгә каршы йортта яшәделәр. Без, балалар, Сәйбаттал абыйдан бик курка идек, ул бердә елмаймый иде. Гайшә тәтәй җәй көннәрендә безгә яшел батун суган кертә иде, аның чисталыгы, пөхтәлеге истә калган. Бүгенгедәй исемдә, бер салкын кышкы көнне мин ниндидер йомыш белән Гайшәттәйләргә кергән идем. Капкалары бикле иде. Байтак көтеп тордым да капканың тоткасына телемнең очы белән орынуым булды, ул ябышты да калды, шунда куркудан телемне тартып алдым, әмма аның тиресе капка тоткасында калды Шунда телемнең әрнүен мәңге онытасым юк. Сәйбаттал абый үләр алдыннан әниемә: «Күрше, әтиеңне, кайнатаңны, туганнарыңны көтмә, алар барысы да шәһәр читендә, чокырда яталар, аларны аттылар», дип хакыйкатьне әйтә. Мин хәзер генә, бу юлларны язганда, аның нигә һәрвакыт күңелсез, моңсу йөрүен аңладым, чөнки Сәйбаттал абый бу зур җинаятьнең шаһиты булган, атылуларны күргән, белгән.

Атылган Мөхәммәтшәриф бабама 73 яшь, ә иң яше, сабантуйларда көрәштә батыр исемен яулаган Сәмигуллага нибары 23 яшь була. Минем туганнарым 1937 елның октябрендә «халык дошманы» бу-

лып тамгаланып 2-5 ноябрь көннәрендә атып үтерелгән. Атылганнар шәһәр читендәге чокырларга мал кебек күмелгәч, аларның каберләредә юк. Бүгенге көндә безнең газиз ата-бабаларыбызның җәсәдләре өстендә йортлар урнашкан, кешеләр, машиналар йөри, чынбарлык шул вәхшилекне хәзерге көннәрдәге хакыйкать белән дәлилли. Шуңа да «кеше каны җирдә ятмый» дигән халык әйтеменең ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүен аңлыйсың. 2012 елның 25 октябрендә туган шәһәрем Тараның «11 нче линия» урамында суүткәргечуздыру өчен канау казыганда, кеше сөякләре күмелгән каберлек ачыла. Килгән күршеләр бакча, чокыр казыганда, кеше сөякләре чыгуы яңалык түгел диләр. Ә бу юлы – зур каберлек ачыла: кеше сөякләре, бөтенесенең баш сөякләре арткы ягында пуля тишеге, бер читтә кием калдыклары. Экспертлар шуны да ачыклаганнар: тоткыннарны ялангач килеш тезләндереп, башларына арттан атканнар. Алдымда туган якларда чыгып килүче «Тарский курьер» дигән гәҗит ята. Аның бер сәхифәсе шушы темага багышланган. Фотода төсле, арты тишекле ике баш сөякләре сүрәте, Кем миңа бу минем газиз бабаларымның баш сөякләре түгел дип әйтә ала!

## 4. Әтием дә сәяси репрессиягә дучар булган

1938 елның 16 февралендә әтиемне дә, Кулеев Галләметдин Мөхәммәтшәриф улын, кулга алалар, Фәтхулла бабам 58-10, Мөхәммәтшәриф бабам 58-2-10-11 УК РСФСР статьялары белән атылган булсалар, әтиемне 58-2-7-9-10-11 УК РСФСР статьялары белән 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерына (ИТЛ га), концлагерьга озаталар. Ул алты ел буена Воркута-Котлас трактында арба (тачка) белән тимер юл полотносына гравий ташый. Соңгы дүрт елын Яросавль өлкәсе Углич колониясендә уздыра. Ул колониянең мәйданы 4 х 4 километр була, бу бер шәһәр чамасы. Кулга алганда әтиемә нибары 32 яшь булган. Аны укытучылары ихтирам иткән, укучылар яраткан. Ул эш өчен янып, көеп йөрегән, Омск шәһәре techинститутының, физмат факультетының өченче курсында укыган вакытында, өч бала атасын, дүртенчесенә, миңа, дөньяга килергә бер ай чамасы калган чорда, төгәл итеп әйткәндә, бер ай да сигез көн, гаиләсеннән аералар. Әтиемнең көләч йөзе әлдә күз алдымда, аның елмаючан булуы лагерь каравылчыларының ачуын чыгара торган булган, ул кешегә игелек теләп карый иде, мин әтиемнең намуслылыгы белән гомерем буена горурланам, аңа ошарга тырышам. Фәһмия апам сөйләвенчә: «әтиемне алырга килгәндә, һәрбер тәрәзәдә кара киемле кеше иде», апам 9 яшендә әтиемне кулга алула-

рын күреп кала һәм 19 яшендә генә аны яңадан күрү бәхетенә ирешә.

Ул заманада беркем бер кая качмаган, чөнки һәркем үзенең гаепсез икәнен белгән, яла ягуны ниндидер аңлаешмаучылык дип уйлаган. Әтиемне алып киткәндә, әнием һушсыз егыла, күзләрен ачканда, урындык башында әтиемнең галстугы гына эленеп калды дип әниемнең сөйләгәне бар. Шул арада әтиемнең әнисен, Фәгыйлә әбиемне паралич суга, нинди йөрәк түзсен, ире, Мөхәммәтшәриф бабам, юкка чыга, яраткан улын, Галләметдинен кулга алалар. Мин мартның 24 ндә дөньяга киләм, әнием мине бала тудыру йортыннан алып кайткач, Фәгыйлә әбием әниемә: «килен, кызымны яныма китереп сал әле, бәлки йөрәгемнең януы басылыр», – ди. Әнием мине әбием янына салгач, ул: «кызым әтисенә охшый икән, әтисе исән-сау кайтып, кызымның игелеген күрсен», – дип елый. Әтием кайткач, һәрвакыт «мин әниемнең догалары белән кайттым, кызым, син минем бәхетсезлегемнең яшьтәше», – дип әйтә иде.

Әтием кулга алынгач, 38 көннән дүртенче бала булып, мин дөньяга киләм, әнием мине бала тудыру йортыннан алып кайтканда, өйдә бабам да, әтием дә юк, авыру Фәгыйлә әбием һәм өч кечкенә бала гына, нинди аяныч хәл! Фәтхулла бабамның өендә дә шул ук чарасызлык, ул кулга алынган, Миннехәят әби 11 бала белән ярдәмчесез газап чигә, аларга тешне кысып, тормышны алып барырга туры килә.

Ә май аенда әтиемне башка тоткыннар белән пароходның трюмында Омскига озаталар. Әтием еламастан сөйли алмый иде: «безгә тозлы селдь балыгын ташлыйлар, эчәргә су бирмиләр иде», – Күз алдына китереп була бу коточкыч хәлне, борт артында су, ә эчәргә юк, ул чакларда Иртыш суы бик чиста булган, чөнки мин яшүсмер чакта Аркарка белән көймәдә барып, Иртыш суын тәмле дип, алып кайталар иде. Омскига кадәр агымга каршы пароходлар дүрт тәүлек йөзәләр иде. Пароход киткәндә «халык дошманнарын «озатырга туганнары килә, кием-салым, азык-төлек китерәләр, сакчылар беркемнән бернәрсә дә алмыйлар. Озатучы ата-аналар, балалар, туганнар елап калалар Безнең зыялы якыннарыбызга, мөртәтләргә (изгойларга) караган кебек караганнар, нинди мыскыл, мәсхәрә!

Әнием пароходта матрос булып эшләгән күршебез белән сөйләшеп, әтием киткән пароходка эләгә һәм Омскига кадәр бара, анда әтиемне күреп кала, бу ачы аерылу ун елга сузыла, әниемнең үзсүзлеге һәм бер үзе генә булуы сакчыларны йомшарта дип уйларга кала, алар әниемә әйберләрне (азык, кием, иң мөһиме тире тунны) тапшырырга рөхсәт итәләр. Максатына ирешкәч, әнием Омкидан кайту ягын карый, шунда мин – ике айлык Фәрзәнәсе исенә төшә, ике апамны, абыемны, мине әнием килендәше Хәбибә җиңги белән калдырган була, мин ачлыктан үлгәндер дип уйлый, күкрәкләре сөт белән тулып,

өйгә кайтып кергәндә, кайда анда миңа үләргә, аякларым белән тибенеп ятам икән. Мине Бүксим татар авылыннан, ул Тарадан 4 чакрым, базарга сатышырга килгән апалар имезгәннәр, и, ходаем, ул апаларның рухлары шат булып, урыннары җәннәттә булсын! Мин берничек тә үләргә тиеш булмаганмын, чөнки миңа әниемне, әтиемне, Фәһмия апамны соңгы юлга озатып, аларга чардуганнар, ташлар куярга язган. 2015 елның сентябрендә абыемның 80 яшенә кайтканда Фәрхәнә апама да чардуган ясаттым, шуңа мин чиксез шат. Әтием, мәрхүм дөрес әйтә иде: «сиңа, кызым, малай булып туарга иде», дип. Мин дә, абыем булса да, әниемә эшләргә туры килгән кебек ирләр эше белән шөгыльләндем. Алтынбаевлар нәселе геннары миндә аз түгел ахыры.

Репрессиягә әниемнең энеләре дә дучар була. Әниемнең энесе, Калимулла абый Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткач, әтисе, туганнары кулга алынганны белеп, үзен дә кулга алырлар дип курка һәм китәргә була. Чита шәһәрендә курслар узып, эшли башлый, тик монда да «стукач» табыла, НКВД га барып, аның әтисе «халык дошманы», ди. Озак та үтми, Калимулла Фәтхулла улы Алтынбаевны да кулга алалар, аны 22 яшендә 10 елга концлагерьга озаталар. Урман кисүдә (лесоповалда) 9 ел гомерен уздыргач, аны яхшы эшләүе өчен бер елга алдан азат итәләр. Искиткеч! Концлагерьдан бер елга алдан азат булыр өчен ничек эшләргә кирәк булган? Кали-

мулла абыемның кайткан көне исемдә, әнием аның кайтуын ишеткәч, аңын югалтты. Әниемнең икенче энесен Муллагали Фәтхулла улы Алтынбаевны «халык дошманы» улы дип, мәктәп директорлыгыннан алалар, ә ул бит бөтен Кызылкаш авылы халкы ихтирам иткән, укытучылар, укучылар яраткан, белемле, гармунда өздереп уйный, матур җырлый торган ике бала атасы була. 1941 нче елда сугыш башлангач, үзе теләп, сугышка китә. Рокоссовский армиясендә сугыша. Муллагали абыем кайтмады, кем белә, репрессияләр 1945 елдан соң да дәвам итте бит. Муллагали абыемның исеме Тарада сугышта һәлак булганнар белән бер рәттән мемореаль ташта теркәлгән.

Әниемнең кыз туганнары да ир туганнары да барысы да бик чибәр иделәр, әнием үзе, Гарифулла абый, Калимулла абый, Хәтифә апа-аларны мин күреп белдем, ә Муллагали абый белән Әсхәпҗамал апаны күрү бәхете миңа тәтемәде, алар да матур булганнардыр, алар барысы да Гәзизә әбием белән Фәтхулла бабамның балалары бит, авылларында алар бик чибәр пар булып саналганнар.

## 5. Әниемнең йорттан йортка йөрүе

Миңа ике ай тулгач, әниемне дүрт бала белән: телсез Фәрхәнә апага 10 яшь, Фәһмия апага 9 яшь, Булат абыйга 2, 5 яшь, миңа әйткәнемчә, ике ай – өйдән куып чыгаралар, әнием куарга килгән НКВД холуйларыннан ишек алдындагы кечкенә генә өйдә калдыруларын сорый, әмма ләкин аны беркем ишетми, шул фаҗиганы күз алдыңа китерсәң, йөрәк сыкрый, Совет властенә хезмәт итүчеләрнең миһербансызлыгы, ваемсызлыгы, каты күңеллеге шаккатыра, кем дип уйлыйсыз уңган, тырыш мул тормышта яшәүче гаиләләрне таркатып, бернәрсәсез урамга куып чыгаручылар? Бу – ялкау ярлы-ябагайлар дәртләнеп, шатланып кара эшләрен тормышка ашырганнар, таланган мөлкәтне, йортларны бушлай үзләштергәч, үзләре тир түгеп, тапмагач, талаган байлыкның кадерен белгән мени алар?

Казанда биш ел буена салган ике катлы йортымны бандитлар яндыргач, мин үземне уйламадым, торыр квартирам бар әле, менә әнкәем дүрт бала белән өеннән куылгач, ничек түзде икән дип еладым. Бер баласы телсез, малае хроник үпкә авыруы белән, мин кулда, шуларны күз алдына китергәч, үкерәсе килә. Кайберәүләр миңа, болар репрессиягә дучар булмаганнар, «оныт инде» диләр. Ничек оныттыйм? Хәзер яшь олылангач, тагын да авыр, нахаксызлык йөрәкне әрнетә.

«Эчемдә генә минем утлар яна. Ник җилкенә икән бу йөрәк?» – дип әтием мәрхүмнең җырын җырларга кала.

Бөтен минем нәселем тар-мар килде. Ни өчен? Яши белгән өченме? Уңган, эшчән булгангамы, алла тәгаләне ихтирам иткәнгә, ярлы-ябагайларга булышкангамы? Бәйрәмнәрдә ял итеп, җырлый, гармуннарда уйный белгәнгәме, сабан туйларында көрәшләрдә катнашып, беренче булгангамы? Нигә тормышлар челпәрәмә килеп таралды? Бу сорауларга җавап бирүчеләр бар, бу тарихчеләр, сәясәтчеләр эше дип уйлыйм. Кайбер репрессиягә дучар булмаганнар арасында тиккә генә атмаганнар, сөрмәгәннәр, концлагерьларда черетмәгәннәр диючеләр бар һәм Сталин заманаларын сагыналар. Ә репрессия иттарткычын (мясорубкасын) узган кешеләрнең йөрәге һаман елый, әрни, гаепсездән, нахактан һәлак булган әби-бабайларын, әти-әниләрен, балаларын, туганнарын юксына.

«Килер шундый вакыт ки, гаделле тикшеренүләр нәтиҗәсендә юк ителгән, лагерьларга озатылган, сөрелгәнәр саны ачыклангач, бөтендөнья үз күзләренә һәм колакларына ышанмас», – ди язучы, сәясәтче Иван Ильин. Репрессияләнгән совет гражданнарын законсыз мәҗбүри рәвештә кол хезмәтендә файдалану дәүләтнең эчке экономик сәясәтенә әверелә.

ГУЛАГ системасы эшчеләр көчен махсус җирләргә күчерергә мөмкинлек бирә. Бер төзелеш тә,

бер җир казылмаларының, урман запасларының һ.б. эшкәртелеше дә социаль инфраструктураларга аз чыгымнар тотып бернәрсә дә түләп итәргә хакы булмаган арзан көчсез, зекларсыз башкарыла алмаган.

Шагыйрә Елена Жукова яза:

*«Жизнь зека в ГУЛАГе совсем не важна,*
*Цена за работу повсюду одна:*
*Лишь пайка с баландой, да ватный бушлат*
*И нары в бараке, где спали внакат».*

Өйдән куылгач, әнием башта балалары белән сеңелесе Хәтифә апага сыена, аның үзенең дә гаиләсе була, ике бүлмәнең берсенә ул безне кертә, үскәч, күрдем шул бүлмә бик тә кечкенә булган икән, анда киң тимер карават, әниемнең тегү машинасы һәм минем бишек эленеп торган. Караватта әнием дүрт баласын: Фәрхәнәсен, Фәһмиясен, Булатын, Фәрзәнәсен кочаклап йоклый. Күрше бүлмәдә Хәтифә апа уллары Әкрәм, Хәлил, Камиль белән. Рәхмәт инде безне сыендырганнар. Ул вакытларда чит кешеләр «халык дошманнарын» фатирга кертергә курыкканнар, аларга да статья тагарлар дип.

Берничә айдан соң без әтиемнең абыйсы Мирсаеф абыйларда яшибез: Хәбибә җиңги, аларның биш баласы, без әнием белән бишәү – барыбыз бер бүлмәдә, Мирсаеф абыйларда озак тормаганбыз, Миннехәят әбиләргә күчкәнбез, анда да бер көтү бала, Фәтхулла бабам кулга алынгач, әниемнең үги әнисе үзе генә балалар белән газаплана. Миннехәят әбидә

кышлагач, Фәһмия апамны калдырып, без авылда Муллагали абыемда торабыз, көзен ул безне Тарага китерә, безгә сөтле сыер Белянканы алып бирә.

1940 елның декабрь аенда әнием, ниһаять, кечкенә генә өй сатып ала, бу өй минем 17 яшемә кадәр яшәгән өем, аны сүтеп яңадан салсалар да, тик ул гына минем төшләремә керә, түшәмгә кадәр үскән кисмәктәге гөле аспарагус, әниемнең аяк машинасы «Зингер» белән. Ул машина әнием белән бергә эшләде, безгә йорт алырга, тамак туйдырырга ярдәм итте, барыбызны да тегәргә өйрәтте, 8 яшемдә инде мин Хәбибә җиңгигә күлмәк теккән идем. Өебезнең ишек алдындагы зур сараенда минем яраткан карлыгачларым оя корып, бала чыгаралар иде, аларның чырылдап өер булып очулары күз алдымнан китми, Казанда бер дә карлыгач күргәнем булмады.

Шулай итеп, без үз өебезгә җитешәбез Ул өйнең кечкенә генә күхнәсе һәм бер бүлмәсе кемне генә сыендырмады. Әнием әйткән: «әгәр үз йортыма җитешсәм, кунырга сорап кергән бер кешене дә кире борып чыгармас идем», дип. Ул үз сүзен тотты, гомер буена ярлы-ябагайларны да, кунакларны да, туганнарны да кундырды, тотты. Исемдә: мин бала чагымда безгә авылдан авылга йөрүче, хәерче дип әйтим, Мәчит бабай кереп китә иде, җилкәсендә киндер капчык булып. әнием аны чәй эчертеп, ипиләр биреп чыгара иде, чәчләре ап-ак, күзләре зәп-зәңгәр иде аның, ул һәрвакыт шат күңелле иде,

өстендәге киеме, капчыгы ямаулы булса да, аннан пакьлек бөркелә иде. Тагын безгә биек буйлы, чәчәк (оспа) авыруынан соң сукырайган шадра битле бер егет сәдака сорап керә иде, мин кечкенә кыз баласы аны җитәкләп базарга алып бара идем, аның тавышы бик моңлы иде. ул җырлагач, кешеләр биргән акчаны ул абыйга җыеп бирә идем, мин кечкенә чактан мохтаҗ кешеләрне кызганып, аларга ярдәм итәргә омтылдым. Бу кешеләргә карата булган мәрхәмәтлелек кадерле әнием белән әтиемнең мирасы, балаларыма да, оныкларыма да шәфкатьлелек чит түгел, моңа алар минем үрнәгемдә өйрәнделәр, моңа мин бик бәхетле

Без йортка күчкәндә миңа 2 яшь тә 9 ай була. Шул кадәр вакыт без туганнарыбызга сыендык, һәрберсенең бер көтү балалары булды, барчасына алламның рәхмәтләре яусын, урыннары җәннәттә булсын! Минем исемдә «күпме телисез, шул кадәр сикерегез, бу үз өебез», – дип әнкәемнең әйтүе. Өебез, сөтле сыерыбыз була, әниемне мастерскойга (һөнәрханәгә) эшкә алалар. «Халык дошманнары» хатыннарын эштән куалар, ә минем әнием норманы 300% ка үти, шуңа күрә аны калдыралар. Әнием өйне 7 мең сумга сатып ала, 3,5 мең сумны шунда ук түли, калганын хуҗалар белән бергә яшәп түләргә тиеш була. Хуҗалар дүртәү: ике балалары, этиләре Степан, эниләре Мария бер караватта йоклыйлар, әнием балалары белән үз караватында, ул кечкенә бүлмәгә ничек сы-

йдык икән. Калган 3, 5 мең сумны түләү өчен әнием көне-төне эшли, көндез һөнәрханәдә, төнлә белән өйдә. Бездән ерак түгел механизаторлар мәктәбе бар иде. Әнием анда укыган егетләргә москвичка дигән ярым пәлтә тегә. Шул москвичканы курсантлар чират торып алалар. Әнием базардан одеал, сарык тиресе сатып алып кичен кисеп, таң атканда тегеп бетерә торган булган, ә иртән яңадан эшкә барырга, өч-дүрт айдан әнием бурычны түләп бетерә. Ул заманаларда өйдә бернинди дә хезмәт белән шөгыльләнергә ярамый иде, исемдә мин урамда чирәмдә ятып, китап укып, фининспекторлар килмиләрме дип күзәтә идем. Әнием өй өчен бурычын түләп бетергәндә, донос язучы табыла һәм безгә бурыч зурлыгында налог (салым) килә.

Сугыш вакытында безнең өйдә урман кисүче Уыш татар авылы егетләре яшәде. Әнием аларны сыерга печән, тавыкларга солы булыр дип кертә, Атфан абый, Чаббар абый, Камали бабай, Равиль абый, калганнары исемдә түгел көнозын салкында, ә бу себер салкыннары, урман кисеп, утынны мәктәпләргә, бала йортларына, хастаханәләргә ташыйлар. Кичен арып талып туңып кайталар, салкында боз булып каткан ипиләрен мичтә эретеп ашаулары аларның гаять тә туңганнарын күрсәтә иде. Аннан соң алар киемнәрен дә салмыйча, идәндә тәгәрәп йоклыйлар һәм төне буе йөткерәләр, нигәдер ул Уыш авылы халкы үпкә авыруыннан интегәләр, сәбәбе – Уыш

елгасы суы дип әйтәләр иде. Ә иртән яңадан урманга чи утын кисәргә.

Бервакыт урман кисүчеләр бездә торганда, әнием төнен ике атны алып, Тарадан биш чакрым булган Бүксим авылы артындагы кордонга коры утынга бара. Урманчылар утын алып кайталар, тик ул чи, янмый. Исемдә, шул кордонда зур чиста сулы күлдән чишмә агып чыгып тегермәнне эшләтеп, кешеләр он тарттыралар иде. Анда Маня апа, тегермәнче Яша абый балалары белән яшиләр, татар авылында торгач, алар теттереп татарча сөйләшәләр. Әнием килүгә алар коры каен пүләннәрен хәзерләп куялар һәм ике ат чанасына төяп бирәләр. Озакламый әнием юлга чыга, бүреләр чыкмасын дип куркып кайта, ашыга да, иртән атларны кайтарып өлгертергә кирәк, чөнки бездә торучы егетләрне урман көтә.

Әнием Иртыш буена килеп туктый, ни эшләргә, яр биек, ничек атлар белән төшәргә? Әгәр атларны чанага җигелгән килеш төшерсәң, әнием бу атларның я аяклары, я сыртлары сынар колхоз атлары бит дип уйлаган, өстәвенә үзе «халык дошманының «кызы булса, Фәтхулла бабамның, икенчесенең хатыны, әтием Галләметдиннең, өченчесенең апасы Калимулла абыемның, дүртенчесенең килене Мөхәммәтшәриф бабамның, акылга сыймый торган кощунство, мәсхәрә!!! Гаиләдән аерылган, кайсы атылып, кайсы концлагерьга озатылып, яшьнәп торган ир-туганнар юкка чыккан, ә чынбарлыкта

30 яшен генә тутырган дүрт бала анасы, балаларын тукландыру, туңдырмау өчен бәргәләнә, җәфалана Сугыш вакыты, барысын да төрмә көтә, балалар ни эшләр? Әнием атларны туара, аннан туп-тулы утын төялгән чаналарны Иртыш уртасына этеп төшерә. Кайдан гына көчләр алды икән әнекәем? Хәзер әйтәләр: экстремаль очракларда кешегә әллә кайдан көч керә дип. Әнием белән балалары һәм курку җитәкчелек иткәндер. Шуннан соң ул атларны җитәкләп төшереп, аларны яңадан җигеп, өйгә кайтып өлгерә. Инде коры каен утыны белән мичне ягу сабан туена әйләнә, чи утыннар өстәсәң дә, мич дөрләп яна.

Бу юлларны мин туган шәһәрем Тарада язып утырам, әнием юк инде, аның газаплары йөрәгемне әрнетә, аңа күпме җафа чигәргә туры килде, барлык ир эшләрен башкарды бит ул, җәен төнне эштән соң, җәяү 12 километрда яткан печәнлеккә барып, ай яктысында бүреләрдән курка-курка печән чабумы, утын ярумы, кадак кагумы, өйне ремонтлаумы, кырда бәрәңге үстерүме, ул эшләр санап бетергесез. Әтиемнән әнием 30 яшендә калып, аны 10 ел буена көтте. Минем исемдә: әниемә ял туры килгәндә, безгә Шихова дигән марҗа килә иде, әнием аңа Романовна дип эндәшеп, аның килеп керүе була, самыварын куеп җибәрә. Чәй эчеп алгач, Шихова карты салып «вернется, девка, твой муж, вернется», – дип әйтә иде. Әниемнең йөрәгенә бу сүзләр май бул-

гандыр. Шул марҗаның карта салуын карап, үзе дә өйрәнде, карта салып әтиемне көтте, ул минутлар сирәк булды, әниемә эшләргә дә, эшләргә туры килде, төне көне эшләде газиз әнекәем, төп эше: безне, дүрт баласын тукландыру, әтиемә тиешле вакытта посылкалар җибәрү иде.

Әнием зур урыс мичендә прәннек пешереп, аны он итеп төеп, каяндыр сало табып, әтиемә җибәрә иде. Без. «Гү-гү, күгәрчен, эти, кайчан кайтырсың, кулыңдагы прәннекне безгә кайчан бирерсең?», – дип җырлый идек Әбиемнең догалары, әниемнең посылкалары безне, балаларны, әтиемне күрү бәхетенә ирештерделәр.

Әнием дөньяда нәрсә тегелә ир-заткамы, хатын-кызгамы, аяк табаны астыннан баш түбәсенә кадәр киелә торган кием-салым тегә иде, бу: ирләр пәльтәсе, костюм, күлмәк. кепка, бүрек, тире тун, һ.б., һ.б. Ул оста тегүче генә түгел, оста кием кисүче дә иде. Мәсьәлән, һөнәрханәгә берәрсе кием тектерергә килсә, аңа бу материалыгыздан (тукымагыздан) теләгән киемегез чыкмый дип әйтәләр, әнә барыгыз М. Горький урамындагы Кулеевага, ул сезгә җиткерер, әнием, геометр булып, кием кискәндә, калган тукыма кисәкләре ямауга да җитми иде. Күз алдымда, әнием клиентларны мөләем йөз белән каршы алып, матур фасоннар тәкъдим итеп, әйткән вакытка өлгертеп, тегелгән кием элек әниемнең үзенә ошап, аннан соң клиентка ошарга тиеш

иде. Шуңа миңа нәрсәдер эшләсәләр, башкаручыга үзеңә ошыймы дип сорыйм әйе дисәләр, мин канәгать булам.

Әнием тегү тегә иде, ә минем эшем: күмер белән утюг кыздыру, финанс инспекторларын күзәтү иде, бу эшне мин ярата идем, чөнки урамда, өебез каршында чирәмдә ятып, рәхәтләнеп китап укый идем. Ул чакта урамыбыз тулысынча яшел чирәм иде, машиналар бөтенләй йөрми, ә атлар безнең урамга сирәк керәләр иде. Урамыбыз тупик белән тәмамланып, балалар мәйданын тәшкил итә иде. Күрше үсмер егетләр безгә уйнарга төрле җайланмалар, уеннар оештырып, хәтта карусель да ясадылар, балаларны аңа утыртып әйләндереп, үзләре дә күп төрле уеннар оештырып, ярышып, көч сынашалар иде, барысының да рухлары шат булсын! Мин аларның сүгенгәннәрен ишетмәдем, тәмәке тартуларын күрмәдем. Рәхәтләнеп татары, урысы татарча сөйләшә идек. Эх, кайда ул күңелле балачак! Күршеләрнең бер-берсе белән туганнар кебек аралашуы!

Сугыш башлангач, әнием гади тегүчедән һөнәрханәнең кием кисүчесенә әйләнә, НКВД эшчеләренә «халык дошманы» хатынының хәрби заказны үтәүдә җаваплы эш башкаруы ошамый. Ләкин сугыш бара, кисүче юк, әниемне алырга мәҗбүр булалар. Кисү бүлмәсендәге озын өстәлдәге өлге ерыклары (прорези) күз алдымда, ике хатын-кыз хаки төсендәге диагональ дигән тукыманы шул өстәлгә кат-кат итеп

җәяләр, әнием шул күп катлы тукымада гимнастерка, галифе һәм башка хәрби киемнәрнең детальләрен акбур белән сыза, анан соң берьюлы аларны иллеләп данә пычак белән кисә. Әнием бу хәрби заказны аның кулы астында эшләүче 75 тегүчегә хәзерли, бер тәүлектә алар 75 комплект сугыш киемнәрен өлгертергә тиеш булалар, әниемнең куллары сөял генә иде, киемнәрне пычак белән кисүнең нәтиҗәседер.

Барлык эшчеләр әниемне яраталар, ул эшчән, уңган, бик миһербанлы, эшчеләренең хәленә керә торган көләч йөзле, ике бите алсуланып торган гүзәл ханым иде. Эштә хатын-кызлар бәхәсләшкәннәр әнием битен буеймы – юкмы дип, бервакыт бер тегүче ак кулъяулык белән әниемнең битен сөртеп алгач, анда буяу эзе булмагач, барысы да көлгәннәр, бәхәс тәмамланган.

Сугыш вакытында «халык дошманы» хатыны булгач, әниемә тиешле орденын да бирмәделәр, аны прокуратурага чакырып, каршысына өч-дүрт ир бастырып үзеңә ир сайла, кияүгә чык яисә фамилияңне үзгәрт, аның фамилиясе түрәләргә тынгылык бирми. Ленинчылар, сталинчылар нинди генә пычрак ысуллар кулланмыйлар.

Исемдә, әниемнең безне толыпка урап, кышның суыгында абыем белән икебезне чанада балалар бакчасына алып баруы. Шундый рәхәт иде шул чак шыгырдавык кар тавышына йокымсырап барырга, ә өйдә 12 һәм 13 яшьлек апаларым кала иде

Магазиннарда (кибетләрдә) киштәләр буш булып, карамелька-кәнфитләрне без сугыштан соң гына тәмләдек. Безгә ипине карточка белән бирәләр иде, исемдә: без-биш кешегә: әниемә һәм дүрт балага 1 килограмм 600 грамм ипи ала идек, барыбер кичтән иртәнгә кадәр чират торып, иртән кибет ачылганын түземсезлек белән көтеп, 10 лап кына кеше кертәләр иде, алар алып чыккан ипинең хуш исе, аның тәме әле дә хәтеремдә!

Кайвакытта безгә, балаларга ашханәдә төшке ашны ашарга талоннар бирәләр иде, бер мәртәбә апам айлык карточкаларны урлатты, шунда безнең бик нык елауыбыз исемдә калган, ни эшләмәк кирәк, балалар бер катлы бит, ә әниебез эштә.

1947 елның декабрендә генә ипигә карточкалар гамәлдән чыкты, ул көнне безнең шатлык чиктән ашты, тик чиратлар әле кала торды.

Сугыш барганда безнең Тара шәһәренә Мәскәү драма театры эвакуацияләнде, аннан сугышта кулы яраланып кайткан Михаил Ульянов чыкмый иде, башта ул театрда гади эшче булып эшли, аннан массовкаларда катнаша, кечкенә рольләр башкара башлый, ниһаять, эвакуациядән соң аны театр белән алып китәләр. Тарада драма театры, бер урам аның исемен йөретә. Михаил Ульянов туган иленә кайткан саен, якташларына зал тутырып бушлай концерт биргән. Таралылар аның белән бик горурланалар.

Исемдә әнием эвакуацияләнгәннәрдән 100 пластинкасы белән патефон сатып алды, шул пластинкалар арасында классик музыка, халык җырлары һәм хәтта Коръән сүрәләре бар иде, бу искиткеч хәл! Мин кечкенә булгач, әйтәм икән, инде мулланы чакырмасак та ярый, пластинканы гына уйнатабыз да хәтем укытабыз дип. Себер ягында аш уздыруны хәтем укыту дип әйтәләр. Минем туган ягымда дин тоту бер дә туктамады: ураза, корбан гаетләре, мәүлед айлары, гашүрә бәйрәмнәре һ.б. үткәрелделәр. Исемдә, без хәтем укытканда әнием әйткән сәгатькә элек мин бабайларны чакыра идем, аннан соң әбиләрне, бу ашлар дини бәйрәмнәрдә, вафат булган туганнарны искә алганда уздырыла иде. Шәйдә мүллинә, бик укымышлы әби, аның да ире атылган, Фатыйма мүллинә, башка әбиләр, Абдулла бабай мулла, башка бабайлар, чиста, пөхтә мөселманнар матур атлап, ашка киләләр иде.

Безнең гаиләдә барысы да диярлек җырлыйлар, шуңа күрә, патефон алу зур хәзинә була, тик эвакуацияләнгәннәргә аннан аерылу җиңел булмагандыр. Бала чагым патефон белән узгач җырлыймдадыр, бер группадашым әйтте «ни эшләп йөредең син физматта, сиңа җырчы булырга иде», – дип, ә мин математик булдым, шулай кирәк булгандыр, чөнки мин дүрт оныгым белән урта мәктәпне дә тәмамладым, Тимур, Артур белән КГУ ның физфакына, Марат белән КАИга, Мәрьям белән банк мәктәбенә кердем,

алар белән бергә укыдым, математикага өйрәттем. Мин шуңа чиксез шат, үземә бер әбиемнең дә, бер бабамның да назын, җылысын тоярга насыйп булмады. Сталин репрессиясе аларның башын ашады. Бала чагымда өстәл өстендә утырып, шулай стенадагы тәлинкә – радиога якын булганмындыр, сугыш сводкалары белән рәттән тулаем опералар тыңлый идем. Исемдә йотлыгып Чайковскийның «Иоланта» дигән операсын тыңлавым. Шундый әхлаклы тапшырулар тыңлап үстек без! Ә хәзер телевидениеның мәдәният каналы гына якынча булса да зәвыклык тәрбияли, бөтендөнья казанышлары белән таныштыра.

## 6. Бөек Ватан сугышында минем туганнарым да катнашты

Минем әтием ягыннан булган бабам Кулеев М.А. Рус-Япон сугышында катнашкан, 9 ел буена Ерак Көнчыгышта үзенең Ватанына инану һәм турылык белән хезмәт иткән, ә аны 1937 елда, 73 яшендә пулей в затылок «халык дошманы» дип атып үтерәләр. Әнием ягындагы бабам Алтынбаев Ф.М. беренче дөнья сугышы каһарманы була, сугыштан яраланып кайта, инвалид булып санала, 11 бала атасы, 1937 елда 58 яшендә «халык. дошманы» булып ул да атыла шулай ук пулей в затылок, кечкенә кызы Нурҗиһанга җиденче генә ай булган чакта, ул миннән бер яшькә олы иде, бергә үстек, икебез дә бик шаян идек. Әнисе, минем үги әбием, безне бакчага кертмәгәч, без бакча артындагы бәдрәфнең бер такtасын каерып, бакчага төшеп, түтәлләр арасыннан шуышып, куенybызга кыяр, кишер тутырып, кергән юл белән чыгып, урамда рәхәтләнеп көлә идек. Бәйрәмнәрдә мәктәптә концертларда икәү бии идек, исемдә матрос биюендә мин егет, ул кыз, өстебездә матроскалар, украин биюе гопакта өстебездә матур чигелгән кофталар, башыбызда такыялар, аякларыбызда черевичкалар урынына кара итекләр.

Нурҗиһан ире Рәкыйп белән бик уңган иделәр. Үз йортларына җитешер өчен акча эшләргә ике елга Казахстанга киттеләр, кайтып, зур бакчалы йорт

алдылар, шул бакчада яшелчәләр, карлыган, кура җиләге һәм башкасы гөрләп үсә иде, мунчалары үзенә бер могҗиза булып, йомшак хуш исле себеркеләр әл дә хәтердә. Мин Казаннан кайтып аларга кунакка барганда, өстәлендә нәрсә генә юк иде: пәрәмәч, пилмән, кыздырылган балык, чәйгә төрле эчлек белән сумсалар. санап бетергесез нигъмәтләр барысы да берьюлы, әнисе, Миннехәят әби кебек Нурҗиһан ифрат та кунакчыл иде. Кинәт кенә Фәһмия апам белән бер көннәрдә дөнья куйдылар, икесе дә уңган, юмарт, чиста, пөхтә иделәр, сәдакаларын биреп, коръән ашларын уздырып тордылар, урыннары җәннәттә булсын!

Бөек Ватан сугышы башлангач, газиз бабамнарның билгесез урында күмелгән сөякләрен яклап уллары, бертуганнарының уллары, бертуганнары (братлары), оныклары сугышалар. Мөхәммәтшәриф бабамның улы Гайнетдин 1945 елның 16 июнендә Көнчыгыш Пруссиядә һәлак була. Омск пединститутының физмат факультетын тәмамлаган математик, аспирантурада укыганда аны сугышка алалар, ул немец телен, рацияне яхшы белгәч, разведкада хезмәт итә. Мөхәммәтшәриф бабамның өч 19 яшьлек оныклары Нариман, Агзам, Шаһимурат 1943 елда һәлак булалар. Нариман – Сәрвәр тәтәмнең улы, аның әтисе Каюм «халык дошманы» тамгасы белән 1937 елда атылган. Агзам – Мирсаеф абыйның улы, Шаһимурат – Хөснинур тәтәмнең улы. Фәтхулла ба-

бамның улы Муллагали, энесе Хәйрулланың уллары: Хәлиулла аңа да 18 генә яшь була һәм Хайбулла, энесе Каюмның улы Абелхасим– барысы да Алтынбаевлар башларын сугыш кырында салганнар, һәлак булганнар. Хайбуллага похоронка килгәч, әнисе Сәгидә әби шул ук минутта сукырая.

«Халык дошманы» булып атылу һәм сугышта һәлак булулары аркасында күпме туганнарымны, аларның туачак балаларын күрмәдем һәм белмәдем, бу – һичнәрсә белән алыштыра алмаслык югалту!!! Фәтхулла бабамның уллары Сафиулла абыем 21 яшендә, Рахматулла абыем 19 яшендә Бөтен Ватан Сугышында катнашалар һәм исән имин кайталар, аларның күкрәкләре орденнар, медальләр белән тулы иде. Сугыш беткәндә миңа 7 яшь булып, мин үз күзләрем белән баһадир абыемнарның матур көләч йөзләрен күрдем. Сафиулла абыем сугышта энә очы кадәр дә яра алмый, үзенең танкында икенче булып Берлинга керә, беренче кергәнгә герой исемен бирәләр. Алтынбайлар уңган дип мин һәрвакыт язып килдем, Сафиулла абый да калышмый, төп йортта әнисе, сеңелләре белән яшәп, аны зурайтып сала.

Шулай итеп, минем 10 туганым нахактан гаепләнеп Совет власте белән атыла һәм 10 туганымнан сигезе шул властьне, халкын яклап сугыш кырларында ятып кала. Атылганнар, сугыш кырларында ятып калган туганнарымның саны, бәлки, күбрәктер дә, мин хәбәрдар түгел, күп еллар үтте, алданрак яза

башларга кирәк булган, ул чакта ниндидер сорауларга җавап та тапкан булыр идем, хәзер инде сорау бирерлек туганнарым да юк, үкенергә генә кала.

Репрессиягә дучар булганнар элек беркем белән дә үзләренең фаҗигалары, кайгылары турында уртаклашмаганнар, Әниемнең хәтере бик әйбәт иде, ул миңа туганнары, үзенең тормышы турында күп сөйләде. Әнием белән әтием исән чакта, аннан соң әнием генә, мин ел да туган илемә җәен ике айга кайтып, укытучы булгач, ялым озын иде, аларга ярдәм итә идем: ремонт ясаумы, түбәне (крыша) буяумы, ватык утюгны төзәтүме һ.б. Балаларым, ата-аналарым һәрвакыт минем өчен беренче урында булдылар. 1978 нче елда әнием белән әтиемнән интервью алдым, әтиемнең коръән укуын, әниемнең туган-тумачалары турында сөйләүләрен яздырдым. Ниндидер дәрәҗәдә әнием белән аның туганнары турында шәҗәрә төзедек Шуңа мин чиксез бәхетле!

## 7. Һич онытасым юк!

1948 елның 23 февралендә дәрестә утырам, дүртенче сыйныфта укый идем, ишекне әкрен генә ачып, ярыктан күрше малае Яхеев Ильдус (аның 1937 елда атылган әтисе аклангач, мөмкинлек ачылгач, Ильдус прокуратурада әтисенең делосын укый, сорау алганда, әтисен ничек газаплауларын, тузга язмаган ялалар ягуларын белеп, тетрәнә, авыруга сабышып, ул озак яшәмәде. Әнисе өч бала белән калып, аларны бик авырлык белән үстерде, тамаклары туймаган чаклары аз булмагандыр) миңа ишаралап, кайтты, мыеклары барлыгын күрсәтә, мин аңладым, әтием кайткан. Укытучы Алимә ападан дәрестән китәргә рөхсәт сорадым, ул җибәрмәде, шуннан соң мин аны ихтирам итә алмадым.

Минем бер дә күрмәгән әтием кайткан, мин әтиемне кулга алгач, бер айдан туганмын, ул вакытта ашкынган йөрәкне онытып буламы? Дәрес тәмамланды, мин букчамны күкрәгемә кысып, урамга йөгереп чыктым, тротуардан түгел, урам уртасыннан чаптым, бөтен сыйныфым минем артымнан. Иң элек К.Либкнехта урамы, аннан Август Бебель, ниһаять, үземнең М.Горький урамына төштем, капкага килеп җиттем, керергә куркам, әтием кумас микән дип, чөнки Хәбибә җиңги һәрвакыт куркыта иде «әтиең кайткач, сине куа», – дип. Мин бик җитез, шаян булып кушаматым да «кара шайтан» иде. Әтием

миңа ут-ялын, нигә малай булып тумадың дип әйткәне бар. Өйгә кергәч, ишек чаршауы арасыннан карыйм, куркып торам, шунда әтием күреп алды, «кызым, кил яныма, «дип чакырды. Без абыем белән аның алдында кичкә кадәр утырдык. Туган-тумачалар, күршеләр, дуслар килделәр дә килделәр. Әтием бетерешкән, мыеклы, колаклары өшеп, шешкән, ул өйгә бик ашкынган. Омскига ике тәүлек поездда, аннан соң Тарага кечкенә самолетта очкан, 70 ел элек Себердә салкыннар бик каты була иде, шуңа әтиемнең колаклары да өшегәндер.

32 яшендә кулга алынган әтием 42 яшендә кайтты. Иң башта без аның мыегын кырдырдык, нигәдер мыек безгә ошамады, бәлкем, безне сөйгәндә битебезгә кадалгандыр. Әтием төне буена безгә җафа чигүләрен, ничә мәртәбә үлемнән калуларын, әбиемнең догалары белән кайтуын сөйләде. Алты ел буена: җәен дә кышын да өстеннән тире тунын салмавын, барыбер урлатканын, ярты үлем хәлендә еврей дустының әрдәнәләр (штабельлләр) белән яткан үлекләр янына чыгартмавын, әтиемне карауын һ.б. авырлыклары турында сөйләде дә сөйләде.

Сугыш вакытында әтием өч мәртәбә сугышка җибәрүләрен сорап хат яза, тик аны Ватанын сакларга лаексыз дип табалар. Бервакыт әтиемнең кулына Солженицынның «Иван Денисовичның бер көне» дигән романының кулъязмасы эләгә, ул безгә

«андагы язылган барлык хәлләр хак, ничек моны уздырдылар икән», – диде.

Әтиемне 1938 елның 16 февралендә кулга алалар һәм 10 елдан соң, 1948 елның 16 февралендә төнге сәгать 12 дә азат итәләр, ул иртәнгә кадәр калырга сорый, «чит шәһәрдә төнлә белән кайда барыйм», – дип. Аңа «син төнге 12 дә азат, шуңа чыгып китәргә тиеш», – диләр. Нинди пунктуальлек! 1948 елның 23 феврален, әтиемнең совет концлагереннан кайткан көнен һич онытасым юк! Ел да халык бу көнне бәйрәм итә, ә минем бәйрәм – 42 яшендә карт бабай булып тоткыннан кайткан газиз әткәем!!! Урыннары җәннәттә булсын аның!!!

Миңа 10 яшь иде, мин әтиемне күрү бәхетенә, аллага шөкер, ирештем.

Безнең Тара шәһәренә өч кеше генә әйләнеп кайтты. Минем әтием, Рәхматулла исемле бер абый һәм бер урыс кешесе, бары өч кеше, ә 1938 елның маенда әтиемне башка «халык дошманнары «белән пароходның трюмын тутырып алып китәләр, Иртыш буйлап Омскига таба йөзгәндә, трюмында «халык дошманнары» тулган пароходлар аз булмагандыр.

Минем атылган туганнарымның 40 ка якын (38) балалары ятим калды, сугыш кырларында ятып калганнарны санасаң, 60 ка якын. Шул кадәр баланың атасыз үсүен, аналары белән бергә газаплануларын күз алдыңа китерсәң, йөрәк әрни, күзгә яшь тула, мин шул атасыз балаларны күреп үстем, әтиләре

сугышта яисә кулга алынган соңгыларының тормыш-көнкүрешләре авыррак иде, чөнки алар «халык дошманнары» балалары иде һәм аларга мөнәсәбәт тә кырыс булды, шуны үзем дә бик яхшы тоеп үстем.

Бу юлларны язганда әтиемнең сөйләгән бер очрагы исемә төште: бер көнне зэкларны строй белән эшкә алып барганда берәү миләш яфракларына үрелә, ул яфракларны ачлыктан ашаганнар икән, сакчы шунда ук аны атып үтерә. Ул атылган кеше әтием кебек Тарадан була, танылган оста табиб, балалар атасы, туган илендә авырулар аның кабул итүен түземсезлек белән көткәннәр, ә «халык дошманы» булгач, аның зыялы булуы, тормышы палачларга кирәкмәгән, табиб булып, туган илендә эшләгән булса, күпме кешенең гомерен саклап калган булыр иде ул, әтием кайткач, аның хатынына иренең ничек үлүен сөйләмәде, ә ул аны еллар буена көткәндер, бик кызганыч язмыш һәм үлем!

Табибләр әтиемә бер биш ел яшәр диделәр. Кадерле әнкәемә рәхмәт, ул әтиебезнең гомерен 30 елга озынайтты. Барлык авыр эшләр тагын да әниемнең җилкәсендә булды: печән чабу, кибән салганда әтием кибән өстендә, ә әниемә астан өскә печән ташлау дисеңме, бакча казу һ. б, һ.б. ул эшләрне санап бетереп булмый.

Әтием тоткынлыктан авыру, хәлсез кайтса да, сынмый, рухы нык була, өенә, балалары, туганнары янына кайтуы аңа көч биргәндер. Кайткач та, ул

РОНОга (районный отдел народного образования) бара һәм безнең шәһәрдә яисә теләсә нинди районда, авылда укытучы булып эшләргә теләген белдерә, әмма ләкин әтиемнең үтенечен кире кагалар, аның өстендә әле һаман да «халык дошманы» ярлыгы булып, реабилитациягә 9 ел калып бара. Шулай итеп, әтиемә яраткан эше белән шөгыльләнергә юл ябыла.

1952 елда Тарада яңа зират ачуга әтием күп көчен һәм тырышлыгын куя. Элек җир кишәрлеген законлаштыру, аннан соң зират мәйданы кырыеннан хайван кермәсен өчен канау казыту артыннан йөри. Ул чакта әтием элек директор булган мәктәбендә завхоз булып эшли. Ат караучы Хәсән абый белән мәктәп атында алар Тара лесничествосыннан нарат үсентеләрен ташып, зиратта утырталар. Исемдә, миңа ул чакта 14 яшьләр иде, көзен, яңгырлы көндә әтиемнең арып-талып, чыланып зираттан наратчыклар утыртып, канәгать булып кайтуы. Ул нарат үсентеләре хәзерге көндә зур наратлар булып җитешеп, зиратны бизиләр, анда яткан, зиратны ачкан энтузиастларны, барлык мөселманнарны саклыйлар. Әтиемнең тырышлыгы белән зиратта каравылчыга йорт салынды, аны утын белән тәэмин итү, каравылчыга зиратны тәртиптә тотуда ярдәм шәһәр халкы исәбенә булды. Зират алдында Сталин репрессиясе корбаннары истәлегенә таш ята.

## 8. Әнием – нәселем йөзек кашы

Минем әнием Фәтхулла кызы Кулеева 1908 елның 12 июлендә Омск өлкәсе Муромцев районы Малатсау авылында туган. Күп еллар буена без әниемнең туган көнен белми идек, ул һаман мин Петров көнендә туганмын дип әйтә иде. Әниемнең 70 яшенә кадәр минең башыма килмәгән бу көннең нинди числога туры килгәнен белергә, ә ул ел да 12 июльдә була икән.

Әниемнең 70 яшьлек юбилеенда әтием исән иде әле. Мин алар янына кайттым, радиога тәбрикләү хаты яздым һәм Илһам Шакировның «Әниемә хат» дигән җырын башкарырга сорап, пластинка алып бардым. Тара радиосы минем барлык тәбрикләү сүзләремне тапшырды, әмма ләкин, җыр мәсьәләсенә килгәндә, ул Марк Бернесның «Темная ночь» ен тапшырды, бу җыр безнең кәефебезне бозды, без үзебезнең татар җырын ишетәсебез килгән иде. Һәр вакыттагыча тәгәрмәгәчкә таяк тыктылар.

Тапшыруны магнитофонга яздым, бу хәл 1978 елның җәендә булды. Мин, аллага шөкер, әниемнән интервью алдым, әтиемнең Коръән укуын да яздырдым. Ул намазын калдырмады, матур тавышы белән ашларда коръән укып, теләк тели иде, аның вафат булуына ике ай калып барган икән. И, ходаем, нинди әдәпле, мәрхәмәтле, көләч йөзле кешеләр иде минем әтием белән әнием! Һәркемгә шундый ата-ана

насыйп булсын! Нинди генә авырлыклар алар җилкәсенә төшмәде, нинди генә газаплар, яла ягулар кичермәде газиз әнкәем белән әткәем, сөйләп, язып бетергесез!

Кадерле әниемә 100 яшь тулган көнне, ә бу 2008 елның 12 июле, әнием турында язмам бар иде. Себердә, Тарада Фәһмия апам авырып китте, 2008 елда миңа апам янына Казаннан дүрт мәртәбә кайтырга туры килде. Апамны карап, соңгы юлга озатып, алланың рәхмәте белән барлык коръән ашларын уздырдым. Фәһмия апамны 2008 елның 7 маенда югалттым, аны югалту минем өчен бик авыр булды, ул мине әнием кебек кайгыртты, мәктәптә укыган чагымнан үзенең ярдәменнән калдырмады.

Фәһмия апам хатын-кызлар киеме тегү ательесенда кисүче (закройщица) булып эшләде, ул оста тегүче иде, мәктәптә укыганда, студент елларымда, укытучы булып КАИ (Казан авиация институты) да эшләгәндә апам миңа матурдан матур киемнәр текте, КДУ да укыганда, каникулга Омскига кайтып төшкәндә, ничек кенә сыйларга белми иде, аннан соң Тарага әнием белән әтиемнәргә озата иде. Апам үзенә дә матур фасоннар белән күлмәкләр тегеп, миңа ошаса, шул фасонны миңа да тегә иде, ул бик чибәр булып, кеше сокланырлык зәвык белән киенде. Әнием дә, апам да, мин дә башкалар кызыгырлык итеп киенә идек.

Фәһмия апам минем балаларымны бик ярата иде, алар да аны. Мин бик соң җырлый башладым, апам исе китеп дискымны тыңлый иде, ул үзе дә моңлы, матур тавышлы җырчы булып, үзешчән концертларда катнашканда, аны махсус тыңларга киләләр иде. Ул мин җырлаган Хәсән Туфан сүзләренә Марс Макаров көенә язылган «Киек казлар» җырын бик яратты, шуны көненә өч мәртәбә тыңлавын, сүзләрен язып калдыруымны, өйрәнәсе килүен әйтте, ул чакта апам авыру иде инде. Гаиләдә без дүрт бала булып, иң яратканым Фәһмия апам, миһербанлы зат иясе, ялгыз карт туганнарыбызны карашып, соңгы юлга озатып, бөтен ашларын уздырды.

Концертларда мин «Су буйлап» дигән җырның «мәңге шиңмәс гөлләр булып калдың күңелләремдә «дигән сүзләрен җырлаганда, һәрвакыт Фәһмия апамны исемә төшерәм. Апам гомере буена чисталыкның, пөхтәлекнең, уңганлыкның, юмартлыкның эталоны булды, балалар бик яратты, үзенең балалары булмады, балалар йортыннан бала алырга килгәч, аңа сайларга балалар күрсәтергә булганнар, беренче китергән бала апамның муенына кочакланган, ул шунда ук бу баланы алган, аңа Рәшит дип исем бирделәр, Рәшит бик авыру булып, апамның йокысыз уздырган төннәре аз булмады. Фәһмия апам аны иркәләп үстерде, оста тегүче булгач, матур киемнәр текте, армиядә хезмәт иткәндә, Паневежис дигән шәһәргә барды, матур итеп туйларын уздырды, оны-

кчыгын караштым, тик Рәшитнең гомере озын булмады.

Әнием турында күптән язасым килгән иде. Уңган, булган күп газаплар кичергән хатын-кызлар бик күп алар безнең илдә, берсе минем әнием Кулеева (Алтынбаева) Васфиҗамал Фәтхулла кызы, әнием турында алда яздым, тагын язасым килә, минем оныкларым, аларның оныклары аларның нәселендә нинди каһарман әбиләре (прапрабабушкалары) булуын белсеннәр, үрнәк алсыннар, тормыш авырлыкларыннан сынмасыннар. Әниемнең эшләгән эшләре – балалары, оныклары эшләгән эшләрне бергә кушсаң, күпкә артык. Әнием-нәселем йөзек кашы!

Әниемнең тагын бер каһарманлыгы турында язасым килә. Быел, 2017 елда экраннарда «Черная кошка «дигән кинофильм чыкты, мин аны махсус карамадым кәефем кырылыр дип, чөнки «Черная кошка» бандалары сугыш тәмамланган елларда аннан соң да безнең илдә чәчәк аттылар. Бу бәхетсезлек минем туган шәһәремә – Тарага да күп бәла китерде. Талаулар, үтерүләр беркемне дә кызганмадылар аналарны да аларның балаларын да. Безнең шәһәрдә бу юлбасарлар шайкасы 1945-1947 елларда үзләренең кара эшләрен башкардылар. Ул чакта әнием дүрт баласы белән кечкенә өендә яши һәм һөнәрханәдә кием кисүче булып эшли, безне бай дип уйлаганнардыр, ул вакыттагы җиһазны күз алдыма китерәм:

ике карават, мич буенда зур сандык, өстәл, комод, почмакта зур көзге, клиентларның тектерергә китергән тукымаларыннан, тегелгән киемнәреннән, әгәр алар булса, башка алырлык бернәрсә дә булмаган, белмим шуңа өметләнделәрме икән.

Бер көнне бандитлар ике хатын-кызны балалары белән суеп чыкканнар дигән хәбәр таралды, аларны дүрт табутта җирләделәр. Аннан соң бездән өч йорт аркылы Деметковлар гаиләсен суеп чыктылар. Мин уйлым, бу бандада безнең зыялы ата-бабаларыбызның баш артларына аткан хәшәрәтләр өере, НКВД иярченнәре, ялчылары булган дип.

Озак та үтмәде, әниемне милициягә чакырып, бер бандитны кулга алуларын, аның исемлегендә безнең адресның да барлыгын әйткәннәр, чарасын күрегез, әгәр сезгә төнлә белән керә башласалар, юшкәгә кычкырыгыз, безнең кешеләр урамда шакылдавык (колотушка) белән йөриячәкләр дигәннәр. Әнием эштән «Чкалов «исемендәге заводка йөгереп барып, анда тимер-томырдан хуҗалыкта кирәкле әйберләр: тәгәрмәчләр, чүкечләр, кошевкалар, ат дугалары һ.б. әйберләр ясыйлар иде, болтлар эшләүләрен үтенә, аңа шунда ук ясап бирәләр, беренче ясаулары булмагандыр.

Безнең өйнең өч тәрәзәсе ишек алдына чыга иде, берсе капкадан кергәч тә, икесе – өйнең сарайга карап торган ягында, ярый әле ул чакта аларның капкачлары була. Кичен әнием тәрәзә капкачларын

ябып, йөзлеккә (наличникка) кагылган тимер прут белән беркетеп, тишегеннән өйгә озын болт кертеп, ул болтның бер башы эшләпәле металл беркеткеч икенче башы өйгә керә торганы ерыклы, шул ерыкларга чәнечке я пычак, я кашык кертеп бау яисә сөлге белән бәйләгән Исемдә, тәрәзәне дөбердәткәндә алюмин кашык сынып китте, әнием чак сөлгене уратып өлгерде.

Әнием балалары, кунакка килгән икедән туган Гәрифә апа белән йокларга яталар. Бер мәлне күк күкрәп, яшен яшнәп яңгыр коя башлый. Сәгать өчләр, капка ачылганлыгы ишетелә, шунда ук өч тәрәзәне, ишекне дөмбәсли башлыйлар, ачыгыз, барыбер керәбез дип кычкыралар, әнием белән Гәрифә апаның куркудан аяклары йөремәс була, кая анда юшкәгә кычкыру.

Бүгенге көнгә кадәр мине бер сорау газаплый: нигә милиция безнең сарайда засада оештырмый, ул чакта бөтен банданы кулга алыр иде. Әллә туполобый аңгыра булганнар, әллә «халык дошманнары» гаиләсен талый, үтерә бирсеннәр дигәннәр микән, белмим. Шулай итеп, әнием белән Гәрифә апа чыдаганнар, бирешмәгәннәр. Икенче көнне Гәрифә апа китеп бара, кунарга беркем атылып тормый, хәтта күршедәге милиционер Зөфәр абый коралы булуга карамастан, безгә керүдән баш тарта, күз алдына китереп була әнкәемнең кичерешләрен, ир туганнары кайсы атылган, кайсы лагерьда, кайсы сугышта.

Беркем ярдәмгә килми. Бәхетебезгә Уыш авылыннан колхоз председателе Насеретдин бабай килә, ул Тарага колхоз эшләре белән килгәндә, бездә кошевкалы атын калдырып, эшләре тәмамлангач, шул ук көнне кайтып китә иде. Әнием аны калырга сорый юк-юк дип Насертдин бабай да тая, ярый әле мылтыгын калдыра. Икенче төнне тагын капка ачылуы ишетелә, бандитлар яңадан килгәннәр, ничек әнкәемнең йөрәге түзде икән, аның белән дүрт бала һәм мылтык! Ул аңа көч биргәндер. Ишекне, тәрәзәләрне бәргәли башлагач, әнием өйалдына чыга, анда чыгарга да батырчылык кирәк бит һәм мылтыктан атып җибәрә. мылтык отдача биреп, әниемнең иң башына бәрә, куркудан, авыртудан ул егыла һәм барлык көчен җыеп яңадан ата, шуннан соң тынлык урнаша, беркем дә ишекне тартмый, тәрәзәләрне дөбердәтми, әниемнең каһарманлыгы аркасында без исән калабыз.

Иртән күршеләр ах-вах итеп керәләр, мылтык аткан тавышны ишетеп, безне атканнар дип уйлаганнар Мин иртә белән өй тирәли йөреп, финка дигән пычак таптым, бандитлар төшереп калдырганнар, аның лезвиесе ике яклы, бик үткен иде, кургаштан коелган сабында йөрәккә пычак кадалган сүрәт чокылып ясалган, ул финка әл дә күз алдымда. Шул көннән башлап, мин көн дә кичен тәрәзәләрнең капкачларын ябып. болтларны кертеп, ерыкларына пычаклар беркетеп, бәйли идем. Ул чактагы курку

гомеремә калды, бурларның безгә керергә маташулары төшләремә кереп аптыратты. Кызым Җәмиләгә күптән түгел мин: «ярый әле исән калганмын, кем барсына да чардуганнар кордырган булыр иде», – дим, ә ул: «әни, берегез дә калмаган булыр идегез бит», – дип, мине аекландырды.

Әнием кичергән авырлыклар санап бетергесез: әтисен, кайнатасын, сигез ир туганын аталар, ирен, энесен концлагерьга озаталар, дүрт баласы белән урамга куып чыгаралар, берничә ай төрмәдә тоталар. Әнием төрмәдән кайта торган төнне мин бер дә йокламадым, миңа, җиде яшьлек балага, таңның атуын көтеп алырга бик авыр булды, дүрт бала әниемнең кайтуын түземсезлек белән көттек, һич онытасым юк ул төнне! Төрмәдәге түрәләр үзләренең хатыннарына, балаларына, туганнарына әниемнән кием тектереп рәхәтләнгәннәр, уфтаганнар әнием зур срок белән утырмый дип. Нинди генә авырлыкар күрсә дә, газиз энкәем сынмый, көне-төне эшләп, өй дә сатып ала, әтиемә хатлары, фотолары (без әтиемә җибәрергә еш карточкага төшә идек) посылкалары белән кайтырга ярдәм итә, ул кайткач та, баланы тәрбияләгән кебек тәрбияли.

Югары белемне алуыбыз белән дә без абыем белән әниебезгә бурычлы, ул безне тегеп киендерде, күп еллар буена миңа Казанга әтием белән бергә посылкалар җибәрде. 1950 елларда, аннан соң да яшәүләр җиңел булмады. Бервакыт кышның салкы-

нында Тарадан пәрәмәч белән тулган 8-9 килолык почта ящигы килде, мин үзебез, студентлар, төзегән тулай торакның бүлмәсендә группадаш өч кыз белән яши идем, болар: Лида Рожкова, Лира Гыйзатуллина, Рима Суринова, рәхәтләнеп бер көн ашыйбыз әнкәемнең пәрәмәчләрен икенче көн, карасак, ящик төбендә, ысланган колбаса түгәрәкләре ята. Әнием мин колбаса яратканга тырышкандыр. Миңа дүртбиш яшьләр булгандыр, безнең сыерыбыз Пестрянка авырып китте, ветеринар аны ит комбинатына колбасага тапшырырга кушты, без сөтле сыерыбызны елый-елый озаттык, безнең зур җиз тазыбыз өелеп ысланган, ысланмаган, ливер колбасалары белән тулды, әнием мине җитәкләп таз янына китерде дә: кызым, күпме телисең, шулкадәр аша», – диде.

Әнием абыемның биш баласын, ике апамның дүрт баласын, минем ике баламны үстерешергә, тәрбияләргә ярдәм итте. Моннан 40-50 ел элек декрет ялы бала туганчы 56 көн, тугач, 56 көн генә иде. Айдар улымны авырлыклар белән үстердем, Җәмилә кызым тугач та, җиңел булмады. Кооператив квартирага түләргә, ике баланы тәрбияләргә эшләмичә булмый иде. Шуңа күрә кызымны 8 аенда соңгы мәртәбә имезеп, елый-елый әнием белән әтиемә калдырып Казанга кайтып киттем. Тарага кызым янына елына ике мәртәбә кайттым, сагынып кайтам, ә ул мине бар дип тә белми, утырып елыйм, үзем белән алып китәр идем, мөмкинчелек юк.

Җәмилә кызым Себердә әби белән бабасы назына рәхәтләнеп өч ел яшәде. Нинди генә матур күлмәкләр, пәлтәләр әнием текмәде, нинди генә тәмле ризыклар ашатмады аңа, кызым авырыганда аның белән хәстәханәгә дә кереп ятты, ә этиемә өй эшләре белән маташырга, әнием белән Җәмиләгә азык ташырга туры килде. Кызымны Казанга алып киткәндә әбисе белән бабасына аерылу бик авыр булды, кызыма да, ул Тараны икенче туган иле дип саный, әби бабасын тирән җылылык белән һәрвакыт искә ала, әбисе кебек уңган, аш-су остасы, юмарт, балалары өчен җаны фида, абыйсының балаларын да бик ярата, аларга ярдәм итәргә һәрвакыт әзер.

Әнекәем гөлләр үстерергә яратып, тәрәзә төпләре гөлбакча булып, өй алдында да күп төрле гөлләр үсеп, көзен шәһәр күргәзмәсенә алыналар иде. Әнием белән әтиемнң гөлләр үстерергә яратуы миңа, оныкларына күчте. Фәрхәнә апамның улы Камиль армиядә хезмәт иткәндә частенең ишек алдын гөл бакчасы иткән, хәзер үз йорты тирәсендәге кишәрлекнең (участокның) өчтән бер өлешендә нинди генә гөлләр үсми: төрле төстәге розалар, пионнар, лилияләр, аквилигияләр һ. б, бөтен Камиль биләгән кишәрлек тирәли зур наратлар үсә.

Әнием 89 яшькә кадәр яшәде, аның зиһене саф, үзе, гәүдәсе матур, билләре уелып тора иде. Ул гомере буена башы белән эшләде ничек тукыманы җиткерергә, бүрек, туннар теккәндә мехны матур

итеп рәтләп куярга. Әнием җырлый-җырлый кисә, тегә иде, аның тавышы бик матур булып, нинди тональлектә җырлаганын дә әйтә алмыйм, үзем әниемне югалткач, җырлый башладым, шуны әйтә алам, минем тавышым әниемнекегә караганда калын, эх, нигә безгә бергә җырларга насыйп булмады икән! Хәтеремдә, мин бер өйгә кайтканда, күршебез Вәрисә апалар әниемне ашка, коръән укырга чакырдылар. , шунда әнием укыганда, минем күзләремнән яшем елга кебек акты, хатын-кыз тарафыннан шундый матур коръән укуны бүтән мин бер дә ишетмәдем.

Язмыш әниемә һаман авырлыклар өстәп торды, без гаиләдә өч кыз һәм бер малай идек, минем бер абыем 1 яшьтә 8 айда кызамыктан үлеп китә, әнием сөйләгән иде шул абыемны тапканда, тулгак тотканда, йокымсырап киткәндә, төш күрә, бер матур пәке табып, аны коега төшереп югалта икән, шунда ул уйлаган, малай табам, тик яшәми икән дип, уйлары материяльләшкән.

Минем тагын бер абыем дөньяга килә, әнием һәрвакыт ул үлә дип курыкты, шуңа аны бик иркәләде, иркә аны бозды, эгоист итеп үстерде. Абыем әти-әнисен дә кыз туганнарын да бик ихтирам итмәде, хатыны да чиләгенә капкачы булды. Бер дә мин абыем барлыгын тоймадым, үзем аңа күп ярдәм итсәм дә. Җәмилә кызым бу турыда язмаска куша, әнием мине иң дөреслекле (правдивая) баласы дип саный иде, барлык минем истәлекләрем чын дөрес, аларны

мин киләчәк буыннарыма гыйбрәт өчен калдырасым килә, начарлык эшләсәләр, белсеннәр, киләчәктә бу билгеле булыр дип.

Иң ачысы шул: әниемә улының безнең нигездә салынган 120 квадрат метр да урын табылмады әниемнең даими рәвештә ярдәм итүенә карамастан: акча, төзү материаллары, утын һ.б. белән, өстәвенә улы аңа яшәячәк бүлмәсен күрсәтеп торды, әнием үзенең яшәгән йортыннан да коры калды.

Әниемә 87 яшендә миңа Казанга туган җиреннән аерылып килергә туры килде, ул кичергән барлык авырлыкларның коточкычы: туган иленнән аерылуы булгандыр, әнием Тараның яңгыр яуса, аякларны көчкә суырып ала торган баткакларын сагынды, кайтып, аларны кочаклар идем дип елый иде. Әниемә тәмле ризыклар ашаттым, матур күлмәкләр алдым. күңеле аның һәрвакыт туган илендә булды. Мин ул чакта ТМУ (Татар милли университеты) артыннан чаптым, анда эшләдем, алдагысын, университетның сүнәсен белгән булсам, әнием белән күбрәк вакыт уздырган булыр идем, ул Тарага кайтуын ашкынып көтте, ә мин әниемне ничек калдырып кайтырмын икән дип кайгырдым. Отпускама ун көн калганда әниемә инсульт булды, аны озатырга бик күп дусларым, ТМУ-студентлары, Тарадан Фәһмия апам килделәр. Әнием ун көн генә авырыды, күзләре белән абыемны көтте, ә ул саубуллашырга да, озатырга да килмәде. Әнием вафат булгач, мин җиде ел буена

Тарага кайтмадым, үпкәм зур иде, аннан соң Фәһмия апам янына кайта башладым.

Бер кайтканда әтиемнең каберендәге бурасы бөтенләй бетеп барганын күрдем, элек таш куярга булдым, чардуганга да акчам җиткәч, аны да куйдырдым. Зиратның директоры яңа гына Казанда булып, безнең шәһәрне яратып кайткан, чардуганны яшел төскә буяуларын сорадым, ул аларда яшел төскә буямыйлар диде, икенче барсам, эшчеләре әтиемнең чардуганын матур яшел төскә буилар һәм аны ясау өчен мин сораганча калын трубалар кулланганнар. Мин бик шатландым, чардуганны, ташны ясаган көннәрдә көн дә яңгыр яуды, ә куйган көнне, кояш чыгып, көн аязланды. Мин бөтен нәрсәне төпле эшләргә яратам, шуңа күзәтеп тордым, эшчеләргә, алар икәү иде, яхшы эшләгез, сезгә аерым түләрбез дидек. Барысы да без теләгәнче эшләнгәч, апам белән шатлыгыбыз эчебезгә сыймады.

Икенче көнне мин Тараның клубында туганнарым, классташларым, дусларым алдында концерт бирдем, баянда икедән туган сеңелем Җинан уйнады, ул Тара музыкаль мәктәбенең укытучысы, 9 ел совет концлагеренда утырып кайткан әниемнең энесе Калимулла абыемның кызы – татар гүзәле. Калимулла абыем Мөнифә җиңги белән биш бала үстерделәр, барысы да тыйнак, уңган, менә алар: Шамиль, Фәридә, Әлфия, Җинан, Ринат Алтынбаевлар. Алланың рәхмәте, Мөнифә җиңгигә 2015 елның 1 ян-

варенда 90 яшь тулды. Исемдә туйның килүе, Мөнифә җиңгинең йөзе матур яулык белән ябык иде, белмим минме, Нурҗиһанмы бисмилла әйтеп аның йөзен ике бармак белән ачып җибәрдек, элек бер аз күтәрдек, аннан соң бөтенләй ачтык, бездә шундый йола булганга, безнең күз алдыбызда матур йөзле, ике җирән төсле толымын алдына төшергән, ике битендә чокырчыклары (ямочки) булган оялган кәләш күренде, оялырсың, шулкадәр күзләр сиңа төбәлгәч, Калимулла абый үзе дә чибәр иде.

Мин әниемне 89 яшь тулырга бер ай калганда, 1997 елның, 12 июнендә, пәнҗешәмбе (четверг) көнне, ул көнне үлгән, гүргә кергән кешеләрне изге дип саныйлар, минем өчен әнием изге, соңгы юлга озаттым, газиз әнием белән әтиемнең рухлары шат, гүрләре якты туфраклары җиңел, урыннары җәннәттә булсын! Әниемнең каберенә Дәрвишләр (Дербышки) бистәсендә, биек наратлар арасында, чардуган кордырып, гранит таш куйдырдым. Бер яктан, мин шатланам, әнием минем янымда, Казанда дип, аның әнисе Бибигәзизә әбием Казаннан булган, кан тарткан диләр, икенче яктан, әнием Тара зиратында әтием белән янәшә ятса, күңелемә тынычрак булыр иде.

## 9. Мәктәбебез белем бирү генә түгел –мәдәни-агарту үзәге дә иде

Һәркемнең йөрәгендә укыган мәктәбе бик тирән эз калдыра дип уйлыйм. Шуңа үземнең мәктәбем, укытучыларым турында язасым килә. Быел, 2015 елда, Омск өлкәсе, Тара шәһәренең 8 номерлы татар урта мәктәбен тәмамлауыма 60 ел тула. Мәктәбем күптән юк, тик ул яшьлек мәхаббәте кебек һаман истә.

Безнең мәктәпнең Тара шәһәрендә эшли башлауы 1831 елга туры килә дигән чыганаклар бар. Шул елда безнең шәһәрдә мәчет салына, һәм аның каршында мәдрәсә ачыла. Бу мәдрәсәдә Рахматулла Юнысыв дигән мөдәррис, ягъни укытучы эшләгәне билгеле. Соңыннан Хәмидов Абделхак, Мамлеева дигән мөгаллимнәр эшләгән. Совет чорында, күп еллар, мәктәп башлангыч була, аны күп көч салып башлангычтан җиде еллыкка әверелдерүче һәм директоры минем әтием Кулеев Галләметдин Мөхәммәтшәриф улы булган, ул 1932-1938 елларда мәктәпне бик күтәреп, тырышып эшләп торганда, 73 яшьлек этисе, бабам, атылгач, 1938 елда «халык дошманы» улы дип, 58 нче матдә (статья) белән кулга алына, 10 елга хөкем ителә, бер гаепсез булуына карамастан әтием тулы срогын тутырып кайта. Ул заманада андый кешеләргә үз эшләренә кайтып, яңадан эшләргә юл юк иде, әтиемне хәтта авыл мәктәбенә дә укытучы итеп алмыйлар. Нинди гаделсезлек!

Бөек Ватан сугышы алдындагы елларда безнең татар мәкәтәбендә Каримова Мәлүфә апа, аннан соң Каюмова Мәрьям апа эшләгәннәр, аларның исемнәрен замандашлары хөрмәт белән искә алалар.

Бөек ватан сугышы тәмамланган елны, 1945 елда, мин беренче класска кердем, сугыш буена балалар бакчасына йөреп, бер ләм-мим сүз татарча белмәгәч, әнием бу бала урыска әйләнә инде диеп, мине татар мәктәбенә биргән, әниемә олы рәхмәтләремне укыйм, гаиләм миндә телемә, милләтемә зур ихтирам тәрбияләде, югыйсә бу язмам туган телемдә дөнья күрмәс иде. Мин беренче класска кергәндә, әтиемнең тоткыннан кайтуына әле өч ел бар иде, нинди фаҗига! Балалар атасы нахак яла ягу нәтиҗәсендә төрмәдә, нәрсә мин шаккатам, ә кем бер ятак, бер кәнди баланда өчен зур төзелешләрдә эшләр иде, сугыштан соң илне күтәрер иде. Ярый әле әниемнән озакка аермаганнар, күпме гаиләләрдә әтиләрен атканнар, ә әниләрен 8-10 елга концлагерьларга, балаларны – балалар йортына озатканнар. Идел буе районы репрессия корбаннары оешмасында өченче өлешенең әтиләре атылган иде. Оешманың рәисе итеп сайлангач, архивта мин кемнең әтисе атылган, кем ерак Көнчыгышка гаиләсе белән сөрелгән, төрмәдә туган, концлагерьда күп елларын уздырган, шуларны ачыкладым.

Беренче укытучым Ниязова Нафига апа иде, йомшак табигатьле, тыйнак, укучыларын яратып,

миңа белем биргән минем Нафига апам, бер генә дә тавышын ул безгә күтәрмәде, укучыларын ихтирам итә иде ул. Мәктәбебез ике катлы зур булмаган йортта булып, дәресләр икенче катта бара иде, анда нибары өч уку һәм бер укытучылар бүлмәсе булып, уку беренче һәм өченче, икенче һәм дүртенче классларда берьюлы барды. 1948 елга кадәр мәктәп 7 еллык булып килде, 1948-1949 уку елында 8 нче класс ачылды һәм шушы елдан башлап, мәктәп 8 номерлы татар урта мәктәбе дип йөретелә башлады.

Урта мәктәпне ачучы кеше – Иштиряков Кафи Абдулла улы булды, ул 1958 елга кадәр мәктәпнең директоры булып, 6-8 нче классларда география һәм конституция фәннәрен укытты. Аның дәресләре искиткеч кызык иде, ул дәресләрне мавыктыргыч, күтәренке рух белән алып бара иде, чөнки Кафи абый Бөек Ватан сугышында ярты Европаны үткән, илебезне яклап йөргән солдат. Ул көчле укытучы, көчле директор булып, үз милләтен сөюче, үз милләте өчен җанын фида итәргә әзер иде. Шундый кеше булып, җаннары җәннәттә булсын, кадерле Кафи абый минем хәтеремдә саклана.

Мәктәпнең материаль нигезен ныгытуда, кадрлар булдыруда, укытучының сыйфатын, дәрәҗәсен күтәрүдә күп эшләде ул. Чирек саен гомуми мәктәп җыелышында Кафи абый һәрбер укучы турында аерым сөйли иде, минем фамилиямә килеп җиткәч, мактап: «Кулеева Фәрзәнә безнең мәктәбебезнең

йолдызының йолдызы», – дип оялта иде. Аның ышанычын мин акладым, мәктәбебезне алтын медальгә тәмамладым, Кафи абый миннән дә артыграк шатлангандыр дип уйлыйм. Мәктәп тарихында бу алтын медаль бер генә булды, миннән соң берничә укучы көмеш медаль алдылар. Мин яхшы укый идем, чаңгы ярышларында катнашучы да. концертларда Мухаметов Шамил белән биеп, фестивальләрдә җиңеп, Омскиның клубларында биеп йөрүче дә, мәктәп спектакльләрендә уйнаучы да, мәктәпнең иҗтимагый эшләрендә катнашучы да идем. Ә җырлауым пенсиягә чыккач ачылды, мәктәптә җырлаган булсам, бәлки математик та булмаган булыр идем. Зур тәнәфестә без, укучылар, баян астында танцыга өйрәнә идек, мәхсус баянчы уйный иде. Мөгаен, директор юк-бар җирләрдә йөремәсеннәр дип, шулай эшләгәндер дә, шуңа күрә без вальсны да, фокстротны да, краковякны да, назаны да, башкасын да теттереп бии идек, мәктәп хорына да өлгердек.

Безнең мәктәп белем бирү үзәге генә түгел, ул мәдәни агарту үзәге дә иде. Исемдә, без кышын, атларга төялеп, татар авылларына барып, колхозчыларга концертлар бирә идек, концерттан соң алар безне бик каты сыйлыйлар иде. Ул вакытларда авылларда телевизорлар юк иде әле, авылга аена бер кино килсә ярый, шуңа безнең концертлар авыл халкына зур бүләк булгандыр. Безнең мәктәп шәһәребез татарларына спектакльләр дә куя иде. Хәтеремдә,

укытучылар укучылар белән бергә Мирхәйдәр Фәйзинең» Галиябануын «куйганда, мәктәп директоры Кафи абый Исмәгыйльнең дусты булып, ә Хәлильнең дустын минем икедән туган абыем Тельман уйнадылар, ул Кафи абыйның муенына ябышкач, елау урынына халык көлде, бик кызык булды. Безгә, кайбер укучыларга, билетлар тараткач, спектакльне карарга рөхсәт бирделәр, без идәндә утырып, рәхәтләнеп, карадык. Галиябануны матур тавышлы рус теле укытучысы Алимә апа Абдрахманова, Хәлильне мәктәптә бухгалтер булып эшләгән, 5 ел совет концлагеренда утырып кайткан Хәмидә апаның ире – көр тавышлы Ахмадриса абый уйнады.

Бу спектакльдә уйнаганнарның берсе дә исән түгел инде, рухлары шат булып, урыннары җәннәтә булсын! Урыс телендә дә спектакльләр куя идек, мәсьәлән, Александр Фадеевның «Молодая Гвардиясен» 8-10 нчы класс укучылары уйнады, мин Радик Юркин ролен башкардым. Һәрбер календарьдәге бәйрәм, ә алар ул чакта бик күп иде: яңа ел, 23 нче февраль – Совет армиясе көне, 8 нче Март хатын-кызлар көне, 29 нчы Октябрь – ВЛКСМ оешкан көн, 5 нче декабрь – Совет конституциясе көне һ.б. мәктәбебездә зур хәзерлек белән, югары дәрәҗәдә уздырыла иде. Яңа ел бәйрәме аеруча күңелле, искиткеч матур булып истә калган, чыршы үзебез ясаган уенчыклар белән бизәлеп, икенче катка менгән баскыч рәшәткәләре чыршы гирляндылары

белән уратылып, хуш ис тарата иде, шуның өстәвенә бал-маскарадлар оештырылып, төрле персонажларны очратырга була иде: «Татьяна Ларинаны», «черкесны», «төнне», 16 Совет Республикаларын Герблары һәм хокуклары белән «СССР Конституциясе «һ.б. образларны.

Үзебезнең костюмнар белән без хәтта шәһәр конкурсларына чыгып, призлар ала идек. Миңа киемнәрне мине бик яраткан укытучым Наталья Михайловна тегә иде, бер яңа елда ул мине тынычлык күгәрчене (голубь мира) итеп киендерде, шул костюмым белән мин мәктәп бал-маскарадында да, шәһәрнекендә дә беренче урынны яуладым, мәктәптә «Кремль» дигән духи, шәһәр ярышында матур күн портфель бүләк иттеләр, бу минем 10 нчы класска җитеп, беренче саллы портфелем булды

Беренче ачылган 8 нче класста 19 укучы була. 8 нче класс ачылу безнең татар балалары язмышында хәлиткеч фактор булды. Күп кенә укучылар, сугыш һәм башка сәбәпләр аркасында укый алмый калып, 18-19 яшьләрдә 8 нче класста укый башладылар. Барысы да мәктәбебезне тәмамладылар. Беренче чыгарылыштан 8 кеше укытучы профессиясен сайлады, менә алар: Ниязова Наҗия, Шарыпова Айнур, Шарыпова Хурия, Шугурова Мөнәвәрә, Мухамадеева Зәкия, Мучипова Шәмсия, Шамсетдинова, Хамитова. Әгәр 1948 елда 8 нче сыйныф ачылмаган булса, алар бәлки укымыйча да калган

булырлар иде Икенче елны 9 нчы сыйныф ачылды, аннан соң 10 нчы.

Омски өлкәсенең: Тара, Тевриз, Евгащин, Үләнкүл, Усть-Ишим һ.б. районнарының күпме татар җидееллык мәктәпләрен тәмамлаган укучылары безнең мәктәптә урта белем алдылар! Кафи абый тырышлыгы аркасында башлангыч классларны гына сыйдырган йорттан без ике катлы зур мәһабәт бинага күчтек. Безнең өчен ул бина сарай иде. Аны революция вакытында Төркиягә киткән Айтикин байлар калдырган, ул аларның йорты булган. Шул мәктәбемнең һәрбер классы, директор, укытучылар бүлмәсе күз алдымда, Мин яхшы укый идем, бервакыт «Основы дарвинизма «дигән дәресне бишлек сөйләмәгәч, шул фәнне укытучы Анна Михайловна миңа икеле билгесе куйды, укытучылар бүлмәсенә чакырып, минем фәнемне яратмыйсың дип бик зур үпкәсен белдерде.

Мәктәпкә укырга йөрү безнең өчен көн дә бәйрәм иде. Яңа мәктәбебезнең зур ишек алды, бакчасы булып без бакчачылык һәм спорт белән рәхәтләнеп шөгыльләндек. Ә нинди зур уңышлар ала идек без бакчабызда! Үзебезнең бакчада алган уңыш җимешләребезне шәһәр юннат күргәзмәләренә чыгарып, бүләкләр, призлар алдык, мәктәп гөлләр бакчасында нинди генә гөлләр үсми иде: бу георгиннар, левкойлар, анюта күзләре (анютины глазки), бархатцалар, һ.б. Бакчага, гөлләргә сибәргә суны без ул вакытта

суы мул булган Аркаркадан тау астыннан көянтәләр белән ташый идек.

Шулай итеп, татар урта мәктәбебез гөрләп эшләде. Башлангыч класслар укыган бина урынына интернат – тулай йорт хасил булды, анда тирә-як авыллардан, районнардан килгән укучылар яшәде. Балалар, укучылар тәүлек буена укытучылар күзәтүе астында иделәр, Минем хәтеремдә бер тәртип бозу очрагы булмады, мин бер дә тәмәке тарткан укучыны күрмәдем. Мәктәпнең укытучылар коллективы зур түгел иде, башлангыч классларда саф татар телендә Мәрвия апа Мифтахетдинова, Фәймә апа Ахунова, Нурия апа Муртазина укыттылар. Мәрвия апа күз алдымда: зифа буйлы, ике чәч толымнары тез асларына кадәр төшкән, аңа беренче класска эләккән бала да, ата-аналары да бәхетле булды, чөнки ул каллиграфия язмасының остасы булып, барлык укучыларын матур язарга өйрәтте. Элек бит чиста язу (чистописание) предметы бар иде. Хәзер бик күп фәннәр юкка чыкты, арифметиканы дүрт ел буена укый идек, нинди безнең миләргә яхшы гимнастика булган бу хәл дип әйтергә генә кала!

Мәрвия апа безнең мәктәптә 35 ел эшләгән. Кайбер гаиләләрнең барлык балалары Мәрвия апада укыган. Мәсьәлән, Рахмангуловлар: Идрис, Ильдус, Ильяс, Кашшаф, Мөкәррәмә, Шариповлар: Айнур, Хурия, Люция, Нурания, Җәлил, Нурия, Маннур. Мәрвия апа эше белән дә, бөтен тормышы белән

чын укытучы иде. Антон Павлович Чехов әйткәнчә, аның йөзе дә, киеме дә, эше дә, уйлары да, җаны да гүзәл иде. Башлангыч классларлагы укытучыларга: Фәймә апага, Нурия апаларга карап, безнең күп кызлар укытучылыкны, балалар белән эшләүне сайладылар.

5-8 нче классларда математиканы татарча Фатыйма апа Бакирова укытты, ул бик таләпчан иде, аннан математика белән дус булмаган укучылар бик шүрли иделәр, тарихны татарча Зәлифә апа Бәширова, рус телен Алимә апа Абдрахманова, физиканы Мөбәширә апа Фәтхуллина укыттылар, болар барысы да минем исемдә калган, мине укыткан укытучылар. 5-7 нче классларда рус телен һәм әдәбиятен Щербакова Наталья Михайловна укытты, ул укыту эшенең остасы иде, аны барлык укытучылар, укучылар, барлык Тара татар халкы нык хөрмәт итте. Урысча грамоталы язуым, рус классикларын белүем белән мин кадерле Наталья Михайловнага рәхмәтлемен, урыннары җәннәтләрдә булсын! Аның өйрәткән шигырьләре әлегә кадәр онытылмаган.

Наталья Михайловна безне үз фәненә генә түгел, ул безне матурлыкны, гүзәллекне яратырга өйрәтте: гөлләр үстерергә, үзенең гөлбакчасындагы, кечкенә генә өендәге пөхтәлек, чисталык бу дөньяда барлык авырлыкларга. югалтуларга карамастан матур яшәргә үрнәк иде. Мәктәптәге спектакльләр дә ансыз үтми иде. Октябрь революциясенә кадәр Ната-

лья Михайловнаның гаиләсе бай булып, сарай кебек йортта торганнар, ә аннан соң ул кеченә генә йортта ире белән яшәде, ире озак яшәмәде, балалары да булмады.

Югары класслардагы класс җитәкчем булган Корней Аронович Варкентинны искә алмый булмый, ул безне немец теленә өйрәтте, бик яхшы өйрәтте ул безне үз теленә, Корней Аронович Идел буеннан сөрелгән интеллигентлы, эрудицияле, көчле укытучы, үзенең укучыларын кайгыртучы булды. Ничек инде физкультура укытучысы Георгий Петровичны искә алмыйсың? Тәлапчан, киң күңелле, миһербанлы кеше иде. Спорт буенча безнең мәктәп шәһәр мәктәпләре арасында 1 нче урынны тота иде, менә алар безнең спортчы җиңүчеләр: Алтынбаев Линнур, Алтынбаева Мая әтиләре Муллагали абыем сугышта ятып калды, Тулякова Ратифә, Иксанова Нәфисә, Шәрипова Мәрьям, Бакиров Рифкать, Ахметова Мәдинә! һ.б., һ.б.

Мәктәптә көчле патриотик рух, оешканлык, бердәмлек, дуслык, үзебезнең мәктәп өчен горурлык сөрде. Кайда гына барсак та безнең максат: беренче булу «Партизанка» колхозында җитен җыеп, көлтә бәйләгәндә дә, Колтюгино авылында сыерларга азык хәзерләгәндә дә, әйе, безнең мәктәп беренче иде. Әйдәманыбыз (пионервожатыебыз) Акжигитова Сәкинә апабыз һәрвакыт безнең белән булды колхозларга эшләргә барганда да, походларга барганда

да. Мин 5 нче класста укыганда ул безне Иртыш буйлап югарыга 60 чакрымга пароходта алып барды, кайтканда, без авылларга кереп, искиткеч матур Иртыш буйларын иңләп, җәяү атладык. Безнең мәктәптә эшләгән урыс укытучылары татар балаларын зирәкләр, аларны укыту җиңел дип табалар иде. Әлбәттә, ул заманда безнең ата-бабалар алкоголь эчмиләр иде әле, балалар саф миләр белән дөньяга килгәннәр.

Мәктәптә җирле кадрлар булмаганлыктан, укытучылар Казаннан алдырыла иде. Шулай итеп, безгә Фания апа Хөсәенова, Лия апа Хәйдарова – татар теле һәм әдәбияте укытучылары килеп, бездә калдылар, кияүгә чыктылар, балалар үстерделәр. Фания апа безне бөек татар язучылары һәм шагыйрьләре белән таныштырды, татар әдәбиятен яратырга, әдәбичә сөйләшергә өйрәтте, үзе себерчә өйрәнде. Башта килгәндә аннан, «син кемтәйте» дип сорагач, ул аңламаган, «син кемсең», дип сораган бер себер татары.

Берничә ел бездә Флера Төхватуллина, Амирова Камилә апа, Шарафеев Мансур абый, мин 9 нчы класста идем, безгә физиканы, Галиуллина Әминә апа химияне татарча укыттылар, ә Гимадеева Рәмзия апа математика укытучысы иде. Барысы да яшь, матурлар, без аларны ихтирам итеп, ярата идек. Ерак Себердә аларга җиңел булмагандыр, беренчедән, салкын, икенчедән туган илдән аерылу. Күп еллар

узгач, мин моны аңладым, үземнең өемне сагынып, мендәремне чылатып елауларымны искә төшереп.

Башлангыч классларда укыту тулысынча ана телебездә алып барыла иде. 6 нчы класстан башлап кайбер фәннәр, укытучылар булмагач, русча укытылды.

Безнең мәктәптән укучылар ныклы белем алып чыгалар иде, укучылардан, безнең мәктәпне тәмамлаганлыктан, институтка керә алмадым дигән сүзне укытучыларга ишетергә туры килмәде.

60 нчы елларның уртасында югарыдан милли мәктәпләрдә укытуны 1-нче класстан башлап урыс телендә алып барырга боерык килә. Бу – балалар өчен дә, ата-аналар өчен дә, милләт өчен дә фаҗигале хәл булды. Бер авыз урысча белмәгән авыл баласын урысча укыта башлауда нинди мәгънә булырга мөмкин!

Тоталитар режимның милләтләрне бетерергә, бердәм ясалма совет кешесе хәзерләп чыгарырга юнәлтелгән сәясәт иде бу. Ә безнең илдә яшәгән, урыс булмаган һәрбер милләтнең телен, мәдәниятен, этносын, йолаларын онытыргамы, хәтердән чыгарыргамы? Мин татар мәктәбен тәмамлап, үз телемне, урыс телен камил белеп, Казан Дәүләт Университетының физматында белем алуым, югары уку йортларында математиканы укытуым нәрсәне дәлилли?

Һәрбер милләт үз телен сакларга тиеш, югыйсә урыс теле дә бетәчәк, галимнәр урыс теленең нигезе

төрки теле икәнлеген күптән исбатлап киләләр, татар телен белгән кеше, күп төрки телләрне аңлый: үзбәк, азербайҗан, башкорт, кумык, төрек, кыргыз һ.б. КХТИ да югары математика кафедрасында эшләгәндә, минем Урта Азиядән килгән бер төркем студентларым булды, һәркем үз телендә сөйләшеп, без бер беребезне аңлый идек.

Безнең телебез җир шарындагы 14 халыкара аралашу телләре рәтендә булуын онытмыйк! Әгәр Пушкинның шигырьләре урыс телендә җыр кебек яңгырасалар, безнең Тукаебызның «Туган теле», «Әллүкие, «Тәфтиләүләре» – моң чишмәсе түгелме? Укытуны урыс теленә күчерү укыту – тәрбия эшен күтәрергә дә юл ачмады, безнең укучылар өчен генә түгел, укытучылар өчен дә зур кыенлык тудырды. Казаннан килгән укытучыларга урыс телендә укытуга күчү җиңел булмады, икенче елны ук алар кире Татарстанга кайтып киттеләр Шул елларда инде милли мәктәпләрнең бетәчәге көн кебек ачык иде.

Безнең мәктәп урта мәктәп булып 24 ел яшәде. 1972-1973 уку елында соңгы чыгарылыш булды.

Телне бетерү өчен бернинди карар, тыю кирәкми, мәктәпләрне генә ябарга кирәк. Бу гамәл барлык урыс булмаган милләтләргә дә кагыла Безнең мәктәпне япкач, аның бинасында үсешләре белән артта калган балалар өчен (вспомогательная)8 нче номерлы мәктәп ачылды. Хәтта безнең татар мәктәбебез-

нең номерен дә үзгәртмәгәннәр, янәсе монда акылга зәгыйфләр укыган булып чыга түгелме? Мин Тарама кайткач, РОНОга барып, ичмасам номерын үзгәртегез дип әйтеп карадым, бу чүлдә кычкырган тавыш (голос вопиющего в пустыне) булды. Бер вакыт мәктәп яныннан узып барганда улым, шаяртып: «әни, мин дә вспомогательная школаны алтын медальгә тәмамлар идем», – диде. Бу – яшь аркылы көлү иде, әлбәттә.

Шул 24 ел дәверендә Омски өлкәсенең төньяк районнарында урнашкан татар милләтен рухи, мәдәни яктан, аң, белемен үстерүдә, милли кадрлар хәзерләүдә безнең мәктәп искиткеч роль уйнады.

Кадерле мәктәбебездә һәрвакытта да директорлар булып Тукайның «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын» дигән өндәвен гамәлгә ашыручылар эшләде. Бу – минем әтием Кулеев Г. Ш., Каюмова М., Иштиряков К. А. һ.б., күпләр алар.

1950 нче елда Тара шәһәрендә бер генә югары белемле татар – агроном Шугуров Сафиулла абый иде Аның кызы Рәйсә апа мәктәбебездә эшләде, ә улы Рубин белән ун классны без бергә тәмамладык, энесе Алмаз түбән класста укыды.

Хәзер исә безнең мәктәпне тәмамлаган югары белемле белгечләрне санап бетерерлек түгел.

Мин үземне 8-нче номерлы Тара шәһәре мәктәбендә укып, анда белем алуыма, зыялы укытучылар-

да укуыма бик бәхетле саныйм, татар мәктәбендә укып, институтка керә алмам дигән уй бер дә башыма килмәде. Без мәктәптә укыганда, мәктәптән мәктәпкә күчеп йөрергә рөхсәт юк иде, ә урта уку йортларына – мөмкин булып, минем бертуган абыем Булат, икедән туган абыем Марат 7 – нче класстан соң педагогик училищесына киттеләр, аны тәмамлагач, аларга юл педагогик институтка гына иде. Мин кадерле мәктәбемнең патриоты идем, кайда анда аны ташларга?

Габдулла Тукай бер шигерендә: «Җырлап торам торган җирем тар булса да, курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да», – ди.

Мин Казанда 1955 нче елдан бирле яшим. Үземнең туган шәһәремне, Тараны, яратам, җир шарында минем туган почмагымнан да йөрәгемә якынрак җир юктыр, 17 яшемдә аннан китсәм дә.

*Китми күңелемнән минем һич*
*Шул сөекле илкәем,*
*Анда минем газиз халкым*
*Анда минем нигезем.*
*Анда таңнар җәйге диңгез*
*Балкуыннан нурлырак,*
*Анда җырлар сандугачның*
*Сайрауыннан моңлырак.*
*Анда уйный гармоннары*
*Өзелеп-өзелеп моңланып,*
*Анда калды туган илем*

Ал томанга чолганып, – дип мин концертларда җырлыйм, шул чак күз алдымда Иртыш буйлары, тайга урманнары, Себер авыллары, туганнарым, якташларым.

## 10. Очрашу

1995 елның 5 августында Казаннан Тарага кайтып мин «Очрашу» бәйрәме уздырдым. Бу очрашуда безнең мәктәпне тәмамлаган укучылар, берничә класс кына укыганнар да, укытучылар, кунаклар катнашты. Мәктәбебез ябылгач, аның тарихында бу беренче күңелле вакыйга булды. Бу бәйрәмне уздырырга мин бер ел хәзерләндем.

1994 елның августында Тара шәһәренең 400 еллыгы уңаеннан ял паркында оештырылган бәйрәм тантанасында татарларга нибары сәгать ярым вакыт бирелүенә күңелем рәнҗеде, кәефем кырылды. Һәм миңа мәктәбебезнең, Тара татарларының бәйрәмен уздыру уе башыма килде. Шуннан шәһәр мәдәни һәм ял паркы директоры Соколова Раиса Васильевнаны табып, аңа 1995 елның 5 августында, шәһәр көне алдыннан, көндезге 12 дән кичке 8 гә кадәр «Очрашу» бәйрәмен оештыру теләгебезне белдердем, ул бу теләкне бик хуплады, миңа гариза язып калдырырга гына калды.

Бу очрашуны мин, беренчедән, мәктәбебезне тәмамлаганга 40 еллык юбилей уңаеннан, икенчедән, әтием 1932–1938 е елларда минем мәктәбемнең директоры булганга, өченчедән, якташларымны уятасым килде, халкыбызның динен, телен, моңын онытмасыннар дип Тара шәһәрендә татар үзәге булдырырга ниятем булганга оештырырга булдым.

Бер елдан, бәйрәмгә бер атна калганда, мин туган илемә кайтып, хәзерлекне башладым, әнием исән иде әле. Иң элек шәһәр администрациясе башлыгына акча сорап бардым, ул вакытта шәһәр башлыгы Голубев Борис Иванович иде, ул мине шәхсән кабул итте һәм бәйрәмебезне уздырыга акча бирде, акча булгач, материаль яктан тәэмин ителгәч, әлбәттә, эш җиңеләйде, үзебезнең көч белән концертны хәзерләргә, төрле оештыру эшләрен башкарырга тотындым.

Ул вакытта мин җырламый идем әле. Репетицияләрдә төп режиссер булып, кем нинди җыр җырлый, нинди номерларны программага кертүләрне хәл итеп утырдым, минем җырлау сәләтем булган икән, шунда «Гөлҗамалым» ны җырлаган булсам, барлык якташларымны таң калдырган булыр идем дип уйлыйм. Минем балачактагы күршем Мөнзир абыйның скрипкада уйнаган татар халык җырларындагы моң, сагыш менә инде 1995 елдан бирле истән чыкмый, безнең моң йөрәккә, һәрбер күзәнәккә үтеп кереп, татар булуыбызны онытырга хакыбыз юклыкны исбатлый, мондый моңы булган татар халкы яшәргә тиеш.

Бәйрәмебез коръән укудан башланып китте, озын, өсләренә эскәтерләр җәелгән, матур гөлләр белән вазалар торган өстәлләр артына Тараның аксакаллары кереп утырды. Минем әниемнең энесе Сафиулла имам коръән укыды, матур кояшлы көндә

Тара шәһәре ял паркында тирә-якка безнең ата-бабалар йөргән, гомер кичергән җирләрдә безгә таныш сүрәләр яңгырады. Бу бәхет түгелме? Мин зур шатлык һәм канәгатьләнү тойгысы кичердем. Сафиулла имам үзенең багышлауында, миңа калса, бер әрвахны да калдырмады. Халык өстәлгә садәка сала башлады. Мәчет казначее Рәхматулла абый Ниязов миңа бу бәйрәмне оештыруыма, мәчет кирәк-ярагына шулкадәр акча җыелды дип олы рәхмәтләрен әйтте, халык дәррәү кул чабып, үзенең шатлыгын күрсәтте, ә минем куанычым чиксез иде.

Аннан соң сүзне безнең яраткан татар теле һәм әдәбияты укытучысы, мәктәбебезнең алыштыргысыз завучы Хөсәенова Фания апа алды, ул безнең мәктәбебез турында саллы чыгыш ясады, аның чыгышы мәктәп ябылганчы аның хронологик яшәүен яктыртты дияргә була.

Шуннан соң сүзне шәһәр администрациясе мәдәният бүлеге мөдире Аскаленко Надежда Геннадиевна алды, үзенең чыгышында ул татарлар турында тирән ихтирам белән сөйләде. Тара шәһәрендә, районында аларның алыштыргысыз урыннарда эшләүләрен, талантлы халык булуларын әйтте. Аңа, бу бәйрәмдә безне микрофоннар, көчәйткечләр белән тәэмин итүенә без бик рәхмәтле булдык. Официаль өлештә һәркем чыгыш ясый алды. Бу очрашуда Тара татарлары үзләренең үзәген булдыру теләген әйттеләр һәм без татар мәдәни һәм агар-

ту (просветительство) үзәге ачтык, идарәсен, рәисен сайладык.

Ниһаять, официаль өлеш тәмамланды. Концертны башларга вакыт җитте. Аны матур итеп Рәис Садыков алып барды. Концертта мәктәбебез «артистларыннан» тыш Уыш авылы үзешчәннәре, кунаклар катнашты. «ОЧРАШУ» бәйрәмебездә кызык-кызык конкурслар уздырдык: мәсьәлән, иң яхшы гармунчы, җырчы, биюче, татар гореф-гадәтләрен матур итеп сөйләп бирүче, иң кызык татар анекдоты, иң матур иттереп мәхәббәт турында ачылу, иң оста татар милли ашын пешерүче һ.б. Барлык укытучыларыбызга, концертка катнашучыларга, конкурсларда җиңүчеләргә бүләкләр, призлар бүләк иттек. Спонсорларның иң юмарты – Сафиулла имамның улы, минем икедән туган энем Алтынбаев Идрис булды, ул безгә өч зур хрусталь ваза китерде, аларны иң яхшы җырчы дип табылган Алеева Саниягә, иң яхшы гармунчыга һәм иң яраткан, зур хөрмәткә лаеклы булган укытучыбыз Мифтахутдинова Мәрвия апага призлар итеп тапшырдык Призларны башка җиңүчеләр дә алдылар, беркем дә бүләксез калмады. Татар милли ашын иң оста пешерүче ачыклангач, барлык тәмле әйберләр белән халык чәйләр эчте. Бәйрәмгә кадәр мин кафе – ресторанда өстәмә татар ашлары: Плау, пәрәмәч, өчпочмак, бәлешләр, баурсак, соклар, компотлар, чәй, заказать иттем.

Зур капкаларны бикләп алып, пиво, аракы төялгән зур машиналарны кертмәдек, монда миңа Раиса Васильевна ярдәм итте. 20 ел үтте, ә минем бу мизгелләр күз алдымда. «Ачыгыз капканы, безгә аракыларны сатырга кирәк», ә мин «Без татарлар эчмибез, иртәгә, шәһәр көнендә планны үтәрсез», – дидем. Раиса Васильевнаның и, ходаем, урыннары җәннәттә булсын, ул гүзәл ханым иде, безгә эчкерсез ярдәм итте, шундый зур бәйрәмне оештыруыбызга карап, чын күңелдән сокланды, шатланды.

Шулай итеп, безнең зур мәҗлестә бер шешә пиво, бер шешә аракы эчелмәде. Тәртип саклаучылар әйткәннәр: «Татарлар бер дә эчмиләр, ничек күңелле ял итәләр», – дип. Бу сүзләрне ишетү минем себер якташларым өчен зур горурлык иде. Тәмле ашап, күңелле концерт карап, төрле конкурсларда катнашып, җырлап, биеп көннең үткәне сизелмәде. Ахырда мин йомгаклау сүзе белән чыктым, сайланган идарәне, рәисне сәхнәгә чакырып, халык белән таныштырдым, алар барысы да шәһәрдә таныш кешеләр, яңадан күрсеннәр, сайланганнар җаваплылыкны тойсыннар дип уйладым.

Аннан бу очрашуны хәзерләүдә ярдәм итүчеләр сәхнәгә чакырылды: Фания апа Хөсәенова, Шарипова Люция, Садыков Рәис, Вәлия, Алтынбаева Җинан, парк директоры Раиса Васильевна, аларга олы рәхмәтләр әйтелеп, бүләкләр бирелде. Кинәт сәхнәгә, безнең мәктәпне тәмамлаган, Алимбеков Җиһанша чыкты, ул Новосибирскидан килгән, бу очрашу-

ны оештырганга миңа зур рәхмәт әйтеп, ераклардан Казаннан килгәнсең, юлыңа булыр дип акча бирде, моны барысы хуплап каршы алды.

Фотога төшү дисеңме, адреслар, телефоннар белән алышулар, күптән күрешмәгәннәрең очрашулары, бик күп көтелмәгән күңелле мизгелләр! Тара шәһәренең паркында 1995 елның 5 августында көнозын татар теле, моңы яңгырады. Барысы тәмамлангач, минем икедән туган, әниемнең энесе Калимулла абыемның улы, Алтынбаев Шамиль кулыма кассета тоттырды, ул безнең бәйрәмне башыннан ахырына кадәр язып алган, махсус Севердан кайткан, мин аны күптән күргәнем юк иде, аны күрү үзенә бер шатлык булса, кассета – патшалар бүләге иде.

Барлык «Очрашу» бәйрәмен оештыручыларга Тара, тирә-як авылда яшәүче, чит шәһәрләрдән кайткан милләттәшләр зур рәхмәтләрен укыдылар, без яңадан бу көннәргә кайтып кала алабыз, чөнки безнең видио язмабыз бар. Шәһәр башлыклары бик канәгать булганнар: «монда тәртип саклаучылар да кирәкмәгән, бәйрәм җыр-музыка, тәмле милли ашлар, соклар, сулар белән узды, шәраб, аракы эчелмәде», – дигән сүзләрне аларга җиткергәннәр.

Тарада, тирә-як авылларда яшәүче милләттәшләр шул бәйрәмне һаман сагынып сөйлиләр, аны уздырырга бик күп көч, зур теләк һәм оештыру таланты кирәк шул, бала чактан мин үземнең татар-

лыгым белән горурландым, телебезнең матурлыгына сокландым, үз фикереңне әйтергә чиксез матур бизәкле сүзләр, әйтемнәр, җөмләләр табып була, моңа безнең даһи язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең әсәрләре, иҗаты дәлил.

Бүгенге көндә Тара шәһәрендә татар, урыс, немец, латыш бүлекләрен берләштергән Милли мәдәниятләр берләшмәсе эшләп килә. Татар милли үзәге башкарган күркәм эшләрне күргәч, сокланмый, якташлар белән горурланмый мөмкин түгел. Бер кайтуымда «Иң оста шигырь сөйләүче» дигән конкурс оештырганнар иде. Жюри әгъзасы буларак, Тәвриз, Усть-ишим, Үлән-күл һәм башка районнардан килгән балаларның татар телендә чытырдатып шигырь укуларына таң булып кайттым, Тарада, авылларда ансамбльләр, үзешчән түгәрәкләр һ.б. эшли. Милли мәктәпләребез ябылып беткән булса да, телебез әле яши. җыр-моңнарыбыз саклана, димәк киләчәккә дә өмет белән карарга була дигән сүз бит ул. «Очрашу» да катнашканнарның күбесе юк инде, өстәл артында утырган бабайларның барысы да, Алтынбаев Идрис тә, безнең очрашуның спонсыры, Тара мәчетенең даими спонсоры, һәрвакыт мәчетне төзекләндерде (ремонтлады): түбәсен дисеңме, бинасын һ.б. Ул да юк, өйгә кайтып машинасын гаражга куйганда, кинәт 2015 елның 10 январендә гомере киселде, аңа 63 яшь кенә иде, аны озатырга бик күп халык килде, Идрис үз милләтенә чын күңеленнән хезмәт

итте. Барлык, миннән дога өмет иткән әрвахларның рухлары шат, гүрләре якты, авыр туфраклары җиңел, урыннары җәннәттә булсын!

## 11. Иҗтимагый эш белән күп шөгыльләндем

Мәктәптә укыганнан бирле мин иҗтимагый эш белән шөгыльләндем. мәктәптә укыганда безне, яхшы укыган, тәртипле укучыларны тантаналы рәвештә элек октябрятка, пионерга, аннан комсомолга кертәләр иде. Бу чаралар узганда, мәктәптә һәрвакыт бәйрәм булып, күтәренке рух сөрде. Иң күңелле минутлар пионерга кергәндә иде, анда безнең муеннарга кызыл галстук бәйләүләр, яңа гына пионерга кергән балаларның кукрәк киереп горур йөрүләре истә калган.

Октябренок чагымда мин чисталык артыннан күзәтүче санитарка идем, пионерга кергәч, башта звенононы җитәкләдем, аннан пионер дружина советы рәисе, комсомолга кергәч, мәктәп комсомол комитетының секретаре (сәркатибе) идем. Хәзер исем китә, нигә шулай чаптым икән, әнием әйтә иде шулкадәр атаңа ошарсың икән дип, әтием бит безнең 4 еллык мәктәпне 7 еллык итү артыннан чапкан, мин дә мәктәптә укуымнан башлап иҗтимагый эш белән шөгыльләндем,

Татар Милли Университеты артыннан йөредем, кем белгән ул йөрүнең Сизиф эш (Сизифов труд) булып чыгасын. Мәктәптә укыганда дәресен аңламаганнарга аңлатып, иртә белән дәрескә килеп, ниндидер мәсьәлә беркемнең дә чыкмаган булса, классташларымны парта артына утыртып, тактада

шул мәсьәләне аңлатып, күчерергә тыйганым, имеш тыңлагыз, аннан соң үзегез эшләгез диюләрем. Математиканы яхшы аңлау, ярату барлык кешегә бирелми шул. Шуны укытучы булгач, аңладым. Институтта кырык елга якын математика укыттым, һәр сентябрьдә, яңа уку елы башланганда, дәрескә дулкынланып керә идем, беренче курс студентларына дәрескә кергәндә, аларның күзләреннән күрә идем, кем яхшы укыячак, ә кем юк, укытучы ул психолог та дип уйлыйм.

Без абыем белән китап укырга ярата идек, элек керосин лампасы утында аннан соң электр лампасы яктысында, өйдә бер генә лампочка яна иде, сугыш барганда безнең өйгә электр да, радио да керде. Исемдә без абыем белән өстәлгә менеп утыра идек лампочка яктысына якынрак булыр өчен, икебез дә шәһәр китапханәсеннән чыкмый идек. Китапханәгә килгәндә, китапханәче Елена Николаевна Муромцева миңа нинди китапны бирим дип баш ватып, «син Кулеева бу китапны укыдың, моны укыдың, тагын ниндине бирим», – дип әйтә иде. Рәхмәт аңа, ул минем маягым булды. Өлгергәнлек аттестатына инша (сочинение) язырга хәзерләнгәндә дә мин үземнең яраткан китапханәмнән чыкмадым. Күбрәк ул вакытта идол булган Ленинга әһәмият бирдем. Интуициям миңа, аның образы белән бәйләнгән тема булыр диде, мин ялгышмадым. Имтихан көнне комиссия инша темалары белән конвертны ачканда,

дулкынланып мин хәтта урынымнан тордым. Беренче тема: «Русс язучылары әсәрләрендә даһи Ленин» иде. Мин шул минутта ук матур эпиграф белән яза башладым, миңа бернинди шпаргалка кирәкмәде. В. Маяковскийның «В.И. Ленин» поэмасын, шигырьләрен, М. Горькийның иҗатын файдаландым.

Мәктәпне тәмамлап 30 ел узгач кына, мин Тарага кайткач, бер мәктәптә минем иншамны китапчык итеп чыгарып, үрнәк итеп кулланганлыкларын белдем, кызганыч, миңа ул китапчыкны табып бирә алмадылар. Ул елларда мин КАИ да югары математика кафедрасында эшли идем һәм туган шәһәрем мәктәпләрендә институтым турында безгә керергә үгетләп лекцияләр укыдым, 8 укучы Казанга укырга барырга теләк белдерделәр, үз якташларыма ярдәм иттем, тырышып укыдылар, гаиләләр кордылар, кайберәүләре рәхмәт хатлары яздылар, балалар белән төшкән фотоларын җибәрделәр. Икенче тема Л. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романы буенча Кутузов белән Наполеон образлары, өченче – Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» әсәренә багышланган иде. Мин генә беренче темага яздым.

Язма эшләремне: математикадан һәм иншамны Омскига җибәрделәр, анда мәктәптә куелган бишләрне расладылар, белмим ул раслауга күпме вакыт киткәндер. Әйе, шулай ничек яхшы укый алдым икән? Минем әтием ягыннан математиклар һәм физиклар аз түгел, шатланам, аларның генна-

ры миңа, балаларыма, оныкларыма көчте, барысы да яхшы укыдылар, югары грамота белән язалар. Шулай итеп әтием, Гайнетдин абыем, мин – математиклар, Гайнетдин абыемның улы фәннәр докторы һәм оныгы, Булат абыем физиклар, оныкларым Тимур белән Артур КДУ ның физфак факультетын, улым Айдар, кызым Җәмилә, оныгым Марат КАИ ны, оныгым Мәрьям банк мәктәбен тәмамладылар, быел Мәрьям читтән торып институтның эконом факультетына керде, Вильнюс шәһәрендә чыгарылыш сыйныфында укыган оныгым Әскәр математикадан, шахматта уйнап олимпиадаларда призлар яулый, музыкаль мәктәп оркестрында ул контрабаста, ә сеңлесе Әдилә скрипкада уйныйлар.

Улым Айдар балачакта, мәктәптә укыганда берәр кирәкмәгән эш эшләсә, җәзага аңа текстлар, шигырьләр ятлата идем, аңа инде 50 яшьтән артык, ә ул һаман аларны онытмый. Ул-минем горурлыгым – медицина өлкәсендә бик күп приборлар уйлап тапты: диабеттан, паразитлардан, компьютер-пульс диагностикасыннан, лазер белән, инфра-кызыл нурлар белән дәвалау һ.б., һ.б., хәзер кулланышта алар аз түгел.

Балачактан мин максатчан идем, Казанга укырга барам дидем, мине беркем дә тота алмады. 17 яшемдә чыгып киттем, Омскига кадәр 400 километр араны Иртыш буйлап пароходта йөздем, аннан соң ике тәүлек поезда Казанга барып, төнге 12 дә ки-

леп җиттем, юк бит иртәнгә кадәр көтәргә, киттем бирелгән адрестагы йортны эзләп, ул тимер юлы вокзалыннан ерак түгел Чернышевский урамында булып чыкты, йортны таптым, кирәкле фатирның ишеген шакыйм, беркем ачмый, бер күрше чыгып, алар дачада диде. Мин моны көтмәгән идем, хәзер кайда барырга? Шунда ук ишек алдында, җиргә кереп бара торган йортның тәрәзәләренең, алар өчме дүртме иде исемдә юк, берсенә express кактым, бер апа «без төнлә белмәгән кешеләргә ишек ачмыйбыз», дигәч, мин «паспортымны карагыз, мин Себердән университетка укырга керергә килдем, бер төнгә кертегез, миңа 17 генә яшь», – дидем. Шул апа ишекне ачып, мине кертте, мине биек караватка үзенең артына, стена буена салды. Яшьлек белән кереп шул ишек алдын, йортны, апаны эзләмәдем, соңыннан да нигә кереп рәхмәт әйтмәдем икән, хәзер үкенәм, минем характерымда түгел яхшылыкның кадерен белмәү. Ул чакта мин бик ашыктым.

Иртән университетка киттем, ул ерак түгел иде, мине бит хат белән собеседованиегә чакырганнар иде. Барып төп бинаның (колонналы) икенче катында физматны таптым, аның деканы Лаптев Борис Лукич минем белән әңгәмә (собеседование) уздырды, математикадан төрле сораулар бирде, миңа университетка кабул ителүем турында әйтте, мин «инде 1 нче сентябрьгә кадәр колхозгамы?» – дип сорагач, Борис Лукич, көлде, «башкалар ничек колхоздан ко-

тылырга белмиләр, ә сез үзегез барырга сорыйсыз, өегезгә кайтыгыз, 1 нче сентябрьгә килерсез», – диде.

Шатлыгым эчемә сыймады, 1955 елның 22 июлендә Казанга килдем, ә 23 ндә – өйгә, өйгә, тагын бер айга туган илемә! Аны сагынып, мендәремне чылатып елауларым әле алда дип кем уйлаган ул чакта? Тимер юлы вокзалына йөгердем, саклау камерасыннан чемоданымны алып, Мансура апага, безнең мәктәптәге укытучыбыз Фания апаның туганына калдырдым. Инде билет алып, поездга гына утырасы калды һәм 48 сәгать барасы.

Мин университетка кергән елны, укыганда Казаннан Омскига кадәр поездлар ике тәүлек баралар иде, чөнки, алар станцияләрдә бер сәгатьләп торып, анда биек өстәлләрдә пассажирларны тулы кайнар аш-су көтеп, барысы туенып, ашханәдән кайткан кебек, поездга утырып, юлны дәвам итәләр иде. Ә хәзер поездлар 5-6 минут, сирәк чакта – 30 минут, анысы да, санасаң, бер кулның бармаклары да күп. Станцияләрдә хәзер чүп-чар: чупа-чупс, доширак, кока-кола, пепси-кола – төрле, минемчә, саулыкка зыянлы «нигъмәтләр» сатыла, юлга мин үзем пәрәмәч яисә өчпочмак, яисә ат казылыгы алып, үзем пешергән чәемне эчеп барам, чөнки бер мәртәбә проводникның стаканнарны кер порошогы белән юганын күрдем.

Казан белән Омски арасындагы тимер юлны миңа, бер дә арттырып әйтмим, 100 мәртәбәдән дә

ким үтәргә туры килмәде. Туган илемнән китүемә быел, 2015 нче елда, 60 ел тулды. Мин тагын да читкә тайпылдым, собеседованиене узып, яңадан поездга утырганга бер тәүлек узмады, ә мин туган ягыма юл алдым, мин Казанга киткәндә, бер елдан соң гына кайтам дип елый-елый киттем, алламның рәхмәте белән 2,5 тәүлектән газиз әнием белән әтиемне, туганнарымны күрәм!

Минем Тарамнан 300 километр ераклыкта урнашкан Омскида институтлар, ә миңа Казанга, татарлар янына, Ленин укыган университетка барырга кирәк иде, ул вакытта аның авызыннан беренче мәртәбә концентрацион лагерьлар турында сүз чыкканын белгән булсам, иншамны аңа багышлаган булыр идемме, аның исемен йөрткән университетка барасым килгән булыр идеме икән. Белмим.

19 гасырның башыннан 19 ел буена бөтендөньяга танылган неевклид геометриясен ачкан, мәһабәт биналарны һәм зур колонналысын да төзегән галим Николай Иванович Лобачевский безнең университетның ректоры булган. Физматта укыганда, без аның ачышын җентекләп өйрәнгән идек, хәтта аның буенча имтихан да бирдек, ул фән «Основание геометрии» (Геометрия нигезе) дип атала иде, барлык билгеләр 5 ле - 4 ле генә, күбесе бишле иде. Безнең барлык теләгебез: университетыбызның Н. И. Лобачевскийның исемен йөретүе. Бу теләк әлегә кадәр хыял, бәлки бервакыт тормышка дөреслек ашар, ел

артыннан ел ага, тормышлар үзгәрә (все течет, все меняется) бит.

Без университетта укыгада күбебезгә тулай торак тәтемәде. Өченче курста укыганда, без студентлар үзләренә тулай торак салачаклар дигән хәбәр ишеттек, ул дөрес булып чыкты. Икенче семестрда дүрт ай буена, укудан буш булганда, без курсларга йөредек, кайсыбыз балта остасына (плотникка), кем ташчыга (каменщикка), кем штукатур-малярлыкка, һ.б. белгечлеккә өйрәндек, без дустым Лидия Рожкова белән штукатур-малярлыкка өйрәнергә булдык, укып бетергәч, безгә 4 нче разряд таныклыгы бирделәр. Безнең төзелеш – комсомол төзелеше дип аталды, прорабыбыз юрфак студенты Леша Кондраьев иде, без иртәнге һәм төшке ашны бушлай ашап, янәшәдәге тулай торакта яшәдек, безгә эш хакы түләмәделәр. Көн дә Лида белән 18 квадрат метр, һәрберебезгә – 9 дан мәйдан штукатурларга тиеш идек, әлегә кадәр барлык штукатурлар әсбапларының атамалары, һөнәре, истә. 27 яшемдә кооператив фатир төзегәндә, өйдә ремонтлар ясаганда, Себердә әнием белән әтиемә ярдәм иткәндә штукатурлык эшен белү миңа артык булмады.

Дүртенче курста без үзебез салган тулай торакта яши башладык. Үзебез салгач, безгә теләгән бүлмәне сайларга рөхсәт булды, без икенче каттагы 41 нче бүлмәне сайладык, бүлмәдә барысы да өр-яңадан иде: караватлар, тумбочкалар, урындыклар, урынжир әйберләре һ.б.

Университетта укый башлаганда, мин ике ел буена уку залыннан чыкмадым, иртәнге 8 сәгатьтә укуга, аннан соң ашханәгә, аннан соң кичке 9 сәгать 30 минутка кадәр, шуңа кадәр уку залы эшли иде, анда ул ябылганчы хәзерләндем. Бик тырышырга кирәк иде, чөнки беренче семестрда безнең төркемнән өлгермәгәнгә 6 студентны кудылар. Минем мәктәбемне, шәһәремне көлкегә калдырырга хакым юк иде, беренчедән, минем алтын медалем, икенчедән, минем Себер характерым моңа ирек бирмәде. Шуның өстәвенә мин ике ел буена көн дә мине куарлар дип курыктым, чөнки әтиемә 1957 елда гына реабилитация белешмәсен (справкасын) бирделәр, ул саргаеп (пожелтевшая) минем архивымда саклана.

Якын дустым Лидия Рожкова турында язасым килә, 1955 елның 1 сентябреннән без аерылмаслык дусларга әйләндек, бер парта артында биш ел утырдык, уку залында да бергә, колхозда бәрәңге алганда да, үзебезнең тулай торакны төзегәндә дә. Бер үк арзанлы тукымадан, бер үк фасонда күлмәкләр тектереп, без игезәкләр кебек йөри идек, тик Лида чын блондинка, ә мин чын брюнетка идем, кызык җәй көне урамда барганда бер аңа бер миңа карыйлар иде, улларыбыз да бер ел да, минем улым 28, Лиданың – 29 апрельдә тудылар. Лида Лаештан, анда аның әтисе райкомның беренче секретаре булып торганда, 1937 елның 13 январенда кулга алына һәм бер елдан «халык дошманы» булып атыла. Нинди ачы

язмыш: Лиданың әтисен аңа дөньяга килергә биш ай калганда, ә минем әтиемне – миңа якты кояшны күрергә ай ярым калганда алып китәләр, мин бәхетлерәк булдым, әтием 32 яшендә алынып, 42 яшендә бетерешкән, какшаган (дряхлый) карт булып кайтты, ә минем җан дустымның – атылган, Лида тугач, әнисенең күкрәк сөте яна, мәктәпне тәмамлаганчы, аллага шөкер, ул әбисе, бабасы белән яши, ә абыйсы Геннадий әнисенең апасында 7 сыйныфны тәмамлаганчы, аннан соң интернатта. Лидага «халык дошманы» кызы булганга ул лаек булган көмеш медален дә бирмиләр, Лида әйтте миңа, «медалемнән ваз кичеп, университетка керә алдым», – дип. Геннадийны Казанда бер кайда укырга алмыйлар, Мәскәүдә недобор булган Бауман исемендәге институтның тау (горный) факултетына гына ул керә ала.

Лида белән икебез дә күп еллар буена югары математика кафедраларында укыттык. Мин ерак Себердән, Лида Казаннан, мин татар кызы, ә ул рус кызы, биш ел буена без бер дә бәхәсләшмәдек, Башка студентлар безнең татулыкка көнләшәләр иде, дус булып, дуслыклары бетүләре булгалады. Укыганда без тешебез – тырнагыбыз белән тырыштык, эчебез дә ут янса да, тышка чыгармадык, ким хур булмадык, туганнарыбыз йөзенә кызыллык китермәдек, без бит данлыклы Казан университетында укыдык, бүгенге көнгә кадәр мин моның белән горурланам, ике оныгым Тимур белән Артур минем факульте-

тымны тәмамлаганга мин чиксез бәхетле. Университетта, мин укыган чакта, безне танылган укытучылар укыттылар, бу – профессорлар, фән докторлары: Б.Л. Лаптев, В.В. Морозов, Н.П. Норден, Р.Г. Бухараев, В.А. Яблоков, Л.И. Чибрикова, Ш.Т. Хабибуллин, В.В. Гагаев, А.Д. Дубяго, С.А. Альтшулер һ.б., алар чит илләрдә танылган галимнәр иде, безгә төпле фундаменталь белем бирделәр, үз эшләренең олы профессияналләре иделәр.

Бик аяныч, Сталин репрессияләре безнең гаиләләрне тар-мар иттеләр, ата-бабаларыбызны аттылар, концлагерьларда череттеләр, бездә көчле геннар шул, без югалып калмадык, яхшы укыдык, югары белемне үзебез генә алмадык, балаларыбызга гына түгел, оныкларыбызга да бирдек. Күп еллардан соң очрашуларга килгәндә, күпчелегебезнең гаиләләре Сталин репрессияләренә дучар булганлыкларын белдек, без укыган елларда бу темага авыз ачу куркыныч иде. Безнең юл көн дә бер иде: университет, лекцияәр, практик дәресләр, ашханә, аннан соң уку залы, көн дә ябылуга кадәр. Безнең уку залы дүртенче физмат залы дип атала иде, хәзер анда бик матур музей.

Шулай итеп, университетта укыган еллар да үтеп китте, кем юллама белән ерак шәһәрләргә, кем туган илләренә эшкә киттеләр, мине КАИ (Казан Авиация институт) ның югары математика кафедрасына укытучы итеп җибәрделәр. Кафедра мөдире профессор

Мангим Шакир улы Аминов башта миңа кичке укудагы төркемнәрне генә бирде. Беренче дәресемне һич онытасым юк, кереп бастым кафедра артына, миңа 22 генә яшь, беркем әһәмият итми, бер кызчык кереп баскан дип уйлыйлардыр, ә минем телем аңкауыма ябышкан, бер сүз дә әйтә алмыйм, студентларым үземнән олырак булып, бик каушадым, бала чактан укытучы буласым килгән иде, ниһаять, теләгемә 1960 елның 1 сентябрендә ирештем. Башта укыту җиңел булмады, еллар үтү белән осталык һәм тәҗрибә тупланды. Улым Айдар улларына: «әбиегез кебек оста, профессионал укытучы Казанда 5-6 гына» дигәне бар, ул КАИ ны кызыл диплом белән тәмамлады.

Институтта укытучыларны берәр группага җитәкче итеп билгелиләр иде, студентларны тәрбияләүгә мин көчемне кызганмадым, атна саен тулай торакларына барып, тормыш – көнкүрешләре белән кызыксынып, математикадан консультацияләр уздыра идем, студентларымны мәдәни яктан да үстердем: театр, музейларга йөреттем, классик музыканы, орган музыкасын яратырга өйрәттем, Бетховен, Бах, Шопен пластинкаларын алып барып, тыңлата идем, әле плеерлар, дисклар заманы түгел иде. Этикетны да читтә калдырмадым, үз-үзеңне җәмгыятьтә, өстәл артында ничек тотарга, дус-ишләреңне ихтирам итәргә өндәдем, күршеңә генә кунакка кергәндә дә матур киенергә кирәк, чөнки син өс-башың

белән кешегә мөнәсәбәтеңне күрсәтәсең дип әйтә идем. тәмәке тартуның зыяны турында сөйләү – көн үзәгендәге мәсьәлә булып калды. Студентлар мине һәрвакыт ихтирам иттеләр.

КАИда 25 ел укыткач, мин китәргә булдым, монда эшләгән дәвердә җиде кафедра мөдире алышынды, кафедра составы үзгәреп торды, җиденче яңа мөдир КАИның 2 нче «Двигатели» дигән факультетын тәмамлаган иптәш иде, Бу факультетта математикага аз сәгатьләр бирелеп, аны тәмамлаган инженер математикадан төпле белем бирә алмавы билгеле, әлбәттә, тик яңа мөдир аларны үзе белән алып килде, берничә нигезле университет белеме алган, әле пенсиягә чыгып та өлгермәгән укытучыларны кыскартты. Миңа бу кагылмады, тик мин мондый хәлгә чыдыйсым килмәде, 25 елымны тутырып, китәргә булдым һәм КХТИ (Казан химик-технологик институт) га югары математика кафедрасына конкурс белән уздым.

Монда татар мөхите көчле иде, миңа Урта Азиядән килгән студентлар белән дә эшләргә туры килде, мамык плантацияләрендә ярты еллап эшләп, аларның белемнәре тирән түгел иде, әмма белемгә тартылуларына һәркем көнләшер. Бу – үзбәк, казах, кыргыз, таҗик балалары булып, мин алар телен, алар мине аңладылар, чөнки безнең әдәби татар, күхнә, себер татарлары телендә бик күп уртак сүзләр бар, менә ни өчен без телебезне сакларга тиеш, һәрберебезнең теленең нигезе – төрки тел бит.

КХТИ да бер төркемдә математиканы татар телендә укыту бәхетен татыдым, татар төркемендә башка мөхит, студентлар тыйнак, кайда анда кемдер игътибарын читкә юнәлтсен, дәрестә үземне бик комфорт тойдым, үзеңнең телеңдә дәрес укыту минем өчен зур казаныш булды, имтихан алганда, шәкертләрнең җаваплары, математика терминнарын татарча кулланып бирүләре үзе бер могҗиза иде. Бу төркемне мин Г. Камал театрына, «Галиябану» спектакленә алып бардым, мәдәни яктан тәрбияләргә тырыштым, шуңа мин чиксез шат идем, чөнки кайберәүләрнең театрга беренче килүе булып, алар инде тагын килүләрен, театрга йөрүләрен әйттеләр.

## 12. Тму – тормышка ашмаган иң зур хыялым

1993 елның 20 сентябрендә Казанда тарихта беренче мәртәбә ТМУ (татар милли университеты) ачылды. Университет ачылган көн бүгенге кебек исемдә. Бу чара Профсоюз урамындагы укытучылар йортында узды, ул чакта бу йортта безнең балалар уку-мәдәни, музыка, җыр, бию, театр, әдәбият белән һәм башка түркемнәрдә шөгыльләнделәр, озак та булмады бу учак та сүнде, шәһәр үзәгендә, җайлы урында урнашкан укытучылар йорты ябылды, түркемнәр урамда калдылар, бик аяныч хәл.

Университет ачылган көн зур тантана белән узды, зал шыгрым тулы иде. Дәрәҗәле кунаклар, фән эшлекләре, чиновниклар, хәтта мәгариф министры булды, ул да чыгыш ясады. Ачылу тантанасыннан соң без – барлык укучылар, укытучылар Нариман урамыннан ерак түгел бер ПТУ бинасында беренче дәресләрне, юнәлеш лекцияләрне уздырдык. Барыбызда да күтәренке рух, шатлык иде.

Татар халкы энтузиастлары бик авыр йөкне үз җилкәләренә алдылар. Без бит беръюлы ике урында эшләдек, төп эшебездә эш хакы алдык, ә ТМУ да бушлай эшләдек, студентлар да бушлай укыдылар. 6 факультетта: икътисад, филология, тарих-археология, медицина җиһазлары, техник-технология, юридик 700 гә якын студентларыбызны югары квалификацияле кадрлар укытты, алар арасында өч

Татарстан фәнни Академия әгъза корреспондетлары, фән докторлары, фән кандидатлары һәм башка югары мәктәпләрдә укыткан тәҗрибәле укытучылар дәресләр алып барды.

Без КДУ (Казан Дәүләт университеты), КАИ, КХТИ, Казан педагогик институты, авыл хуҗалыгы, төзелеш институты укытучылары идек, үзеңнең милләтеңә ана телендә яраткан фәнеңне өйрәтү бәхет иде, әйе, Биктимирова Тәэминә әйткәнчә. елыйсы килә иде, шатлыктан елый-елый укыттык.

ТМУ ачылу тантанасында мәгариф министры, чиновниклар һәрберсе бик матур нотыклар сөйләде, аннан соң без аларны күрү бәхетенә ирешә алмадык. 20 ел элек бомж дигән атама юк иде кебек, ә без ул вакытта инде бомжлар идек, үз бинабыз булмады, лекцияләрне, практик дәресләрне Казан буйлап төрле урыннарда уздырдык: КДУ да, авыл хуҗалыгы институтында, 6 нчы татар гимназиясендә, аның директоры Таң Мәхмуд улы Еникеев безнең белән бергә борчылды, укытырга классларын, акт залын бирде, Школьная урамындагы 4 нче мәктәптә, хәтта мәгариф министрлыгында да дәресләр барды, исемдә шундый күренеш: бүлмәгә сыймаган студентлар коридорда урындыкларга утырып, ачык ишектән такта янындагы укытучыны тыңлап, тезләрендә лекцияләрне язулары, нинди кызганыч күренеш!!! Үз илебездә, үз мәмләкәтебездә ни Илбашы, ни хөкүмәт, ни Югары Совет, ни Бөтендөнья

татар конгрессы безгә ярдәм итмәде. Бүген милли каһарман булып йөргән бер зур түрә ул вакытта безгә, милли университет дип җан атып йөрүчеләргә «Сезгә нечего терять, а мне есть, сез йөрегез», – дип кенә кул селтәп шаккатырды. Әйе, шуңа карамастан, ТМУны теркәү артыннан Илһамия Курганова белән армый-талмый чаптык. Мин өйдә 88 яшьлек Себердән килгән әниемне калдырып йөредем. Әнием миңа «шулкадәр атаңа ошарсың икән, ул да 4 сыйныфлы мәктәпне 7 еллыкка әверелдерү өчен күп йөреде», – диде, аннан соң аны 32 яшендә «халык дошманы итеп 10 елга концлагерьга озаталар.

Хәзер безгә ярдәм итмәгән депутатлар, чиновникларның туган телне саклау турында фәлсәфә сатканда. минем икейөзлелеккә (двойной стандартка) исем китә, нигә аларга ярдәм сорап килгәндә, кул селтәделәр икән, исемнәрен атыйсым килми, ата-бабаларымның, туганнарымның «халык дошманнары» булып, доностан интегүләре искә төшә. Ул елларда телевидение аша бер туры эфирда иң югарыдагы өч җитәкченең берсенә: «Кайчан безнең ТДМУны (Татар Дәүләт Милли Университеты) рәсми рәвештә ачасыз да дәүләт тәэминатына куясыз соң инде?» – дип сорау биргән идек, чөнки аның ачылуы 1990 елда Дәүләт программасына кергән һәм һич югы 1995 елда аңа рәсми уку йорты дәрәҗәсе бирелергә тиеш иде сыман. Тик түрәбез «Безнең укытучы-

ларыбыз да, әсбапларыбыз да юк», – дип кенә кырт кисте Ничек инде юк.

ТМУ эшләп тора, димәк укытучылар да, шәкертләр дә бар. Ә укыту әсбапларына килгәндә: КАИ дагы физико-математика фәннәре докторы Гали Юнус улы Даутов татар телендә 4 томлы физика, КХТИ галиме Абрик Вәлиуллин «Гамәли механика» (Сопромат), Химия фәненнән Хисамиев, төзелеш институтыннан Шакирҗанов теоретик механикадан, Үзем Рәфкать Рәхматуллин белән берлектә математикадан ике дәреслек язган идек инде. Берсе «Сызыкча алгебра һәм аналитик геометрия элементлары» һәм «Дифференциаль исәпләү» (Техник – технология, медицина җиһазлары инженерлары, финанс-икътисад белгечләре өчен), «Интеграль исәпләү» дәреслеген дә тәмамлап килә идек. КДУ-да Равиль Һади информатика буенча ике дәреслек, Гөлнара Арсланова инглиз теленнән татар теленә күчереп методик кулланмалар, күнегүләр хәзерләде.

Шулай итеп, безнең ана телебездә математика, физика, химия, информатика, инглиз теленнән һ.б. фәннәрдән, һәрбер югары уку йортында зарур булган уку-укыту, календарь планнары, һәрбер факультетның расписаниесе бар иде, кыскасы, безнең югары уку йорты проблемалары хәл ителде, без бит тәҗрибәле укытучылар, деканнар, уку-укыту мөдирләре идек, иң мөһиме безнең энтузиазмга теләсә

кем көнләшер иде. «Укытучылар җитми яки дәреслекләр юк», дип сылтау табу, асылда, туган телдән йөз чөерү булды. Хәтта Омск өлкәсе, Тара шәһәреннән Фәткуллина Фәния Хөсәен кызы шигырен безгә җибәргән иде.

*Бүген минем күңелем шатлык кичерә.*
*Бу шатлыктан тәмам башым исерә,*
*Чөнки бүген хәбәр алдым Казаннан,*
*Халкым анда олуг җиңү казанган*
*– Бит татар университеты ачылган,*
*Шушы хәбәр матбугатта басылган,*
*Килде бүген Тукайны уятасым,*
*Бу хәбәрне аңа әйтеп шатланасым.*
*Үлмәгән, Тукай, татарың ул яшәр,*
*Аның даны әле галәмгә ашар.*
*Калмас, Тукай, безнең татар тик сакаллы,*
*Булыр әле киләчәктә маллы, данлы.*
*Син күрәсе килгән арысланнар да*
*Бик күп хәзер безнең Татарстанда.*
*Бу эштә без догада һәм теләктә,*
*Милли хисләр көйри бит һәр йөрәктә.*
*Төрле илләрдән бер чак яшьләр килерләр,*
*Татар илен алар күреп белерләр.*
*Татарның Сорбоннасы булсын ул,*
*Киләчәккә ходай аңа ачсын юл.*

ТМУ ның ачылуы зур резонанс (яңгыраш) тапты, безнең университетта башка милләт шәкертләре һәм чит төбәкләрдән дә укучылар бар иде. Безнең

уку йорты тулы канлы тормыш белән яшәде, тик җитәкче даирәләр моны танырга теләмәде ахыры.

Укытуны дәвам иттек, берьюлы юридик теркәлү белән шөгыльләндек, Илһамия Курганова белән икебез Юстиция министрлыгы юлын таптадык. Ниһаять, безгә Татар Милли Университетына (ТМУга) ярдәм итү буенча ТР югары йорт эшлекләренең иҗтимагый берләшмәсе (Общественное объединение работников высшего образования РТ по поддержке деятельности ТНУ) дигән лицензия бирделәр, бу – ТМУ ны тану була түгелме соң, чынбарлыкта ТМУ ны танымыйлар, ә булмаган университетка ярдәм итәргә лицензия бирәләр – мәсхәрә! Без моңа да риза идек, чөнки уку-укыту эшчәнлегенә рөхсәт алдык. ТМУны теркәргә рөхсәт булмады, аны 1995 нче елда дәүләт ачачак ТДМУ (Татар дәүләт милли университет) ның нигезе булыр дип өметләндек. Өметләр акланмады. Пикетлар, митинглар белән ТМУ укучылары, укытучылары, ата-аналар Ирек мәйданына, Казан Кремленә президент каршысына бардык, матбугатта, радиода чыктык. Безнең күтәреп чыккан лозунглар, плакатлар:

1. Теле барның иле бар.

2. Кайчан татар халкы югары белемне ана телендә алачак.

3. Милли университетка бина һәм финанслау!

4. Татар дәүләт милли университетын ачуны тоткарлаучылар – халык дошманнары!

5. Ни өчен югары белемне ана телендә алуда халыкларның хокуклары тигез түгел?

6. Хөрмәтле Президент, татар милли университетын ачуда ярдәм ит!

7. Телебезне торгызу – балалар бакчасы, мәктәп, югары уку йортлары аркылы!

8. Милли университетны – 1995 елдан башлап дәүләт казнасына!

9. Барлык телләргә дә югары уку йортлары дәрәҗәсендә бердәй хокук!

Дәүләт даирәләре безне күрмәде, ишетмәде.

Татар дәүләт милли университетын ачу – аерым энтузиастларның гына кайгысы булмасын иде, ә бөтен Татарстан фәнни-техник җәмгыятенең, мәгариф министрлыгының, югары фән белгечләренең, дәүләт җитәкчеләренең, сәнгать эшлекләренең, язучыларның, галимнәрнең һ.б. төп бурычы, көн кадагы булсын иде дип йөредек.

Татар милли университетын оештыруда мин бик актив катнаштым, икътисад факультетының деканы булып, беренче 14 белгечне хәзерләп чыгардым, аларга төпле, тирән белем бирергә тырышлыгым бик зур булды. Казан югары уку йортларыннан, икътисад белгечлегендә татар телендә укыта ала торган дәрәҗәле укытучылар эзләүгә вакыт кызганмадым. Студентларым мине икенче әниләре итеп саныйлар иде, кайда укытсам да шәкертләрем мине яраттылар, ихтирам иттеләр. Филология факультетында

бик дәрәҗәле, саллы педагоглар укытты менә алар кайберләрен атап китим: Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Фәүзия Бәйрамова, Хәләф Гарданов, Анвар Хуҗиәхмәтов һ.б., башка факультетларда: Ильдус Әмирханов, Рафаэль Тукшаитов, Тәэминә Биктимирова, Кәрим Долотказин, Равиль Һади, Ринад Галимуллин, Рафкать Рәхматуллин, Баграм Кочкарев, Альберт Борһанов, Фоат Галимуллин, Ким Шакиров, Сәвия Михайлова, Әнисә Мусина, Гөлсинә Мурзакова, Наиль Газетдинов, Анис Галимҗанов, Гөлнара Арсланова, Илһамия Курганова, Фәрзәнә Кулеева, Мәрьям Ахиярова, Әзһәр Мөхәммәди, Хаҗип Наҗипов һәм тагын бик күп милләтпәрвәрләр Татар Милли Университеты дип җан аттылар, кайберләре арабызда юк инде, урыннары җәннәтләрдә булсын!

Яңа үзгәрешләр (перестройка) җиткәч тә, университетка ярдәмне күтәп ала алмадык, ул сүнде. Энтузиастлар көче генә җитми икән шул шудый зур эшләрне башкарырга. Үз телеңдә, Ана телендә укытуга ни җитә, безнең студентларга үз телләрендә математиканы үзләштерү күпкә җиңел иде. Үзебезнең тәҗрибәдән чыгып әйтергә була: татар төркемнәрендәге студентлар башка төркемнәргә караганда яхшырак укыйлар, тырыш һәм эшчән булдылар. Димәк гореф-гадәтләр, әхлакый сыйфатлар сакланып кала дигән сүз. Мин югары математика укытучысы буларак, математиканы ана телебездә укытуның нин-

ди өстенлекләргә ия булуын мисаллар белән раслый алам. Терминнарга килгәндә халык-ара терминнар саклана: интеграл, дифференциал һ.б., ә татар терминнарының күбесе мәгънәләре белән математикадагы күп гамәлләрнең үзенчәлекләрен төп-төгәл тасвирлый. Мәсәлән, математикадагы вакланма, ваклаучы, санаучы дигән атамалар. Бөтен сан ваклануп, күпмедер өлеше саналып алына. Мисал өчен: уннан өч вакланмасы бөтен сан унга бүленеп, өч өлеше саналып алынганлыкны аңлата. Һәрбер атаманың килеп чыгуы аның беренче кулланышына бәйле була. Аныклагыч дигән атаманы алсак, ул сызыкча тигезләмәләр системаларын чишкәндә, системаларның чишелеше бармы юкмы икәнен аныклап бирә.

Ана телеңдә укуга ни җитә! Миңа калса, безнең татар телебез иң матур тел, барлык уйларыңны искиткеч итеп фикерләргә мөмкинлек бирә, шуңа бу истәлекләремне туган телемдә язам, урыс телендә дә бик шәп яза алсам да. Мин телне саклап калу, өйрәнү, үстерүнең зарури юлларның берсе – югары белемне үз ана телебездә алу, ул чакта телгә балалар бакчасында да, мәктәптә дә әһәмият бирелә дип уйлыйм, икенче юл, ичмасам КДУ ның һәрбер факулкультетында татар төркемнәре булдыру, үткән гасырның 30 нчы елларында шулай булган да. КДУның Лобачевский исемендәге китапханәсендә татар телендә төрле фәннәрдән дәреслекләр бар, мин ТМУ

да укытканда 1953 нче елда И.А. Алексеев тарафыннан татар телендә язылган һәм Казанда басылган «Югары математика нигезләре» дигән дәреслектән файдаландым, 10 көнгә генә биргәннәр иде. Соңгы вакытта, 23 ел узгач, без ТДМУ мәсьәләсен күтәрә алабыз, моңа 2012 елның 19 декабрендә РФ Президенты В.В. Путинның 1666 № астында чыккан «Стратегия государственной национальной политики РФ на период до 2025 года дигән Указы этәрә, анда» Стратегия направлена на активизацию всестороннего сотрудничества народов РФ, развитие их национальных языков и культур» дип язылган.

Безнең университетны ачар өчен ике нәрсә кирәк дип уйлыйм беренчесе – энтузиастлар, алар бар әле, икенчесе – президентыбызның ярдәме. Татар халкының киләчәк язмышы аның үзенә, ихтыярына, эшчәнлек сәләтенә һәм дә аңының никадәр анык булуына бәйле. Үзебезгә бәйле безнең язмышыбыз. Татар милли университетын аякка бастыру, үстерү аерым кешеләрнең генә кайгысы булмасын иде. Татар милли университетын Сорбонна, Оксфорд университетлары дәрәҗәсенә җиткерү югары фән белгеч ләренең, дәүләт даирәләренең дә бурычы булсын иде. «Теле барның иле бар» дигән әйтем безнең барлык эшләребезнең байрагы булсын!

## 13. 30 Октябрь – репрессия корбаннарын искә алу көне

1997 елның 3 ноябрендә мин Казан шәһәре Идел буе районы репрессия корбаннары оешмасын җитәкли башладым, бу эштән мин ваз кичә алмадым һәм аны җилкәмә йөкләргә тиеш идем, моңа минем атылган бабаларым, тагын сигез ир туганым, концлагерь тормышын татыган әтием, әниемнең энесе, безнең «халык дошманы» булып йөрүебез, әниемнең җафа чигүләре этәрде, мине рәис итеп сайлауга каршы булмадым. Ул чакта КХТИ да һәм ТМУ да эшли идем, үземә тагын бушлай эшли торган бер йөкләмә алдым.

1999 елның җәендә мин социаль тәэминат Министрлыгының архивыннан чыкмадым, үземнең оешма әгъзаларының, алар 657 иде, җиде пункт буенча исемлеген төзедем, минем өчен иң мөһиме: аларның нинди репрессия мотивлары булган, кем ничә ел төрмәдә утырган, кемнең әтисе атылган, кемнәр махсус сөргеннәрдә 5, 8, 10, 16, 18, 25 елын сарыф иткән. Безнең оешмадагы кешеләрнең өченче өлешенең әтиләре атылган!!! Шулай архивта, кем нинди җаза алганын ачыклап утырганда, укыйм, Изатуллин Минулла Минзариф улының әтисе 1937 елның ноябрендә Омск өлкәсе, Тара шәһәрендә атылган дип, урындыгымнан егылып төшә яздым, минем дә 10 туганым туган илемдә, Тарада шул ук вакытта

атылганнар, нинди вәхшилек! Минулла 1937 елның гыйнварендә туган, әтисе атылганда аңа әле 1 яшь тә тулмаган, безнең оешмада, атасы кулга алынганда карында калган, мәсьәлән, мин үзем, аннан соң дөньяга килгәннәр дә бар, моны алар әтиләре атылып, реабилитация белешмәсе килгәч, белгәннәр.

20 ел инде мин ОРПР (Организация реабилитированных Приволжского района) ны җитәклим, әтисе нахактан атылганнар барысы да минем исемдә, аларның атасыз интегеп яшәүләрен оныта алмыйм, исемлектә аларның мотив репресии графасында ОР (отец расстрелян) дип язылган, башкаларның я Вәлиева Фәнзия Әхмәтсафа кызы кебекнең – спецпоселение 25 ел, я раскулачен, выслан, я узник лагерей, я заключение. Төрмәдә туганнар исемлеккә кермәгәннәр. Ицкович Людмила Николаевна лагерьда туган да инде, аның исән калуы могҗиза, аның сөйләүен тыңлагач, ничек кан басымы күтәрелмәсен, ничек чәчләрең үрә тормасын, Людмила тугач, аны әнисеннән аерып алалар, имезергә рөхсәт бирмиләр, әнисенең сөтен лагерь түрәсенә эчәргә йөртәләр, ә балага, чүпрәккә мякиш (ипи йомшагы) салып, имезәләр, аны да яшертен, чөнки баланы юк итәргә әмер була, әнием сөйли иде ди Ицкович Л.Н. «Ничек син исән калдың икән» – дип.

ТР сы репрессияләнгәннәр берләшмәсе оешканда, аның составында 6000 нән артык кеше булып, ТР районнары да керә иде. Берләшмәдә кемнәр генә

очрамый иде: әтисе атылып, әнисе лагерьга озатылып, бертуган балалар булсалар, төрле балалар йортларына җибәрелә, Яушев Карл Гариф улы энесе белән ике төрле шәһәргә озатыла, Мөхетдинова Азалия Мирсәед кызының әтисен аталар, әнисен АЛЖИР (Акмолинский лагерь жен изменников Родины) га җибәрәләр, үзен – балалар йортына. Берничә ел элек Азалия Мирсәед кызы очраклы рәвештә Мәскәүдә Донской монастырендә бер каберлектә әтисе Мирсәед Сафинның (танылган биолог, генетик) Якир, Тухачевский, Убаревич, Блюхер һәм башкалар белән бергә ятканын белде, бу аңа әтисен яңадан югалту иде, күпләр ата-аналарының кәберләрен белмиләр, алар миллионнарча, Азалиягә әтисенең яткан урынын белү, анда барып чәчәкләр кую, догалар уку, үзенә бер тынычлану булгандыр. Мондый очраклар санап бетергесез, барысы турында язып бетереп булмый.

Лагерьда аналары белән бергә утырган (срок мотать итүче) балалар да аз түгел иде, мәсәлән, Хисамутдинов Рөстәм әнисе белән төрмәдә имчәк баласы вакытыннан биш яшенә кадәр утыра, әтисе атылган хәбәре килгәч, аны әнисе белән бергә азат итәләр, шунысы игътибар итәрлек, узники немецких концлагерей социаль льготаларга, әһәмияткә (вниманиегә) ияләр, ә безнең совет лагеренда туган яисә төрмәгә эләккән бала әсирләренә бернинди яклау, әһәмият, ярдәм юк, алар инде моны көтеп ала алмаслар, чөнки олылар.

Нинди генә мотив репрессиясенә дучар булсак та, безнең геннар үз эшләрен эшлиләр, безнең арабызда атылган «халык дошманы» улы – Марсель Хәернас улы Бакиров. Ул КДУ профессоры да, ТР ның атказанган фән эшлеклесе дә, Кол Гали исемендәге халыкара лауреаты да һ.б. , без аның белән горурланабыз, мондый исемлекләрне дәвам итеп була – фән докторлары, фән кандидатлары, дәрәҗәле табиплар, укытучылар, җырчылар, шагыйрьләр, кемнәр генә юк. «халык дошманнары» арасында.

Сталин репрессиясенә дучар булганнар ТР да басылган 18 томлык Хәтер Китабында теркәлгән, аның баш редакторы Анатолий Александрович Иванов иде. Раскулаченныйларның да 8 томлык Хәтер Китабы дөнья күрсен өчен ул күп эшләде, арабызда ул да юк инде. Аның хезмәтен киләчәк буыннар бер дә онытмаслар. Урыннары җәннәттә булсын! Хәтер Китабында гомеренең 10 елын Свияжск лагеренда утырган, 7 елын Новосибирск урманнарын кискән безнең Хәсән Туфаныбыз, Ак Диңгездә 4 елын уздырган Бакый Урманчыбыз, 36 ел гомеренең 8 елын төрмәләрдә, лагерьларда газап чигеп, ахыр чиктә Бөек Ватан сугышына озатылып, Калининградта 1945 елның 2 маенда һәлак булган Фатих Кәримебез, 1910 елдан башлап һәр ел саен ике пьеса язган, халкыбызга «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Американ», «Җилкәнсезләр» әсәрләрен бүләк итеп, 1938 елның 7 маенда атылган, атаклы Кәрим Тинчурины-

быз да бар, Тинчурин Казанның Архангел зиратындагы билгесез урынында, дүрт чокырның берсенә 2756 «халык дошманы» арасына күмеп тигезләнгән. «Яшь йөрәкләр», «Таһир-Зөһрә», «Камали Карт» һ.б. әсәрләр авторы Фәтхи Бурнаш Самарада 1942 елның 1 августында атылган, кабере билгесез.

Шамиль Усмановның язмышы утырып еларлык, ул кичергән җәзаларга тагын кем генә дучар булды икән? Соңгы сулышына кадәр Ш. Усманов большевик – ленинчы булып кала, әмма ләкин аны кызган тәрәзәсез тимер камера – «мунчада», аннан муенына кадәр батырып сәгатьләр буе «бозлы ваннада» тоталар, допрос конвейры бер дә туктамый, сорау алучылар бер берсен алыштыра, аннан аны канлы измәгә (до кровавого месива) әверелгәнче кыйныйлар, допросларның берсендә ул һәлак була, бер генә аңа яккан яланы танымый. Мондый газап чиккән зыялыларыбыз исемлеге чиксез.

Миңа оешмабызның рәисе буларак күп авыр язмышлар турында белергә туры килде. Күптән түгел безнең оешмага Демко Юлия Анатольевна исемле бер ханым мөрәҗәгать итеп, бабасының кайда, ничек һәлак булуын ачыклыйсы килгәнен әйтте. Мин, безнең илдә андый теләк белән миллионлаган кешеләр яналар, әмма ләкин андый мөмкинчелек юк дидем, Әгәр ГУЛАГ картасын карасаң, безнең ил концлагерьлар челтәрендә ятканын күрәсең, кемнең кайда ятып калганын белеп була мени? Юлияне

үзебезнең атна саен реабилитацияләнгәннәрне кабул итү бүлмәсенә чакырдым. Ул бабасының 1943 елның 13 ноябрендә йөрәк авыруыннан үлүе турында белешмә китергән иде. Шуннан мин Хәтер Китабының кирәкле томын киштәдән алып, Юлиянең бабасын таптым, анда аның бабасы Донов Макарий Михайлович 1938 елның 7 июлендә үк атылган дип язылган, нинди вәхшилек! Шунда икебез дә елап җибәрдек. Юлия Анатольевна «ниһаять, бабамның язмышы ачыкланды дип шатланды, балаларыма, оныкларыма кайтып сөйлим, алар бабаларының ничек юкка чыгуы белән күптән кызыксыналар», – диде. Бик дулкынланды ул, елый-елый миңа гаилә фотосында төшкән бабасын күрсәтте, ярый әле сезнең кебек олы йөрәкле кешеләр бар диде, ничек соң мөмкин булганда, кешеләргә ярдәм итмәскә, минем гаиләмдә 10 кеше атылган!!! Аларның рухлары шат булып минем бу эшләремнән риза булсыннар!

Беренчедән, мин ярдәм итүемә шатлансам, икенчедән, безнең илдәге «мәсхәрә» (кощунство) турында тагын бер нәсел беләчәк дип уйладым, чөнки минем эшемнең төп максаты, ә быел, 2017 елда, сәяси репрессияләрнең югары ноктасына 80 ел тулганда, безнең халыкка Сталин репрессиясе турында мәгълүматне җиткерергә аеруча мөһим, югыйсә кайбер кешеләр аны «сагыналар «хәтта аңа, бу дөньядагы иң зур җинаятчегә, һәйкәл кую турында хыялланалар. Ул белмәгән имеш?! Юлия Анатольевна

миңа шалтыратып, кәефе юклыгын, әле мин һаман шок кичерәм диде, кичерерсең, якын кешеңне ике мәртәбә үтерсәләр.

Атаклы Дмитрий Менделеевның Россия демографиясе белән шөгыльләнүе билгеле, ул 2000 елда Россия халкының 500 миллионга җитүен раслый. Тик аның бу хыялы гамәлгә ашмый, чөнки безнең илгә бик күп фаҗигаләр кичерергә туры килә, фәнни тикшеренүләргә күз салсак, алар безнең халыкның кимүен дүрт дулкын нәтиҗәсендә дип саныйлар: Беренче дулкын – Рус-япон сугышы, 1905 ел революциясе, Беренче дөнья сугышы, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, масса-күләм эмиграция, 1921 ел ачлыгы, миллионнарча халыкның кимүе, Икенче дулкын – авылларны көчләп коллективлаштыру, эшчән, уңган гаиләләрне раскулачивать итеп ерак җирләргә көчләп сөрү, 30 нчы елларның ясалма ачлыгы, масса-күләм репрессияләр, халыкларны депортацияләү һәм тагын миллионнарча корбаннар. Өченче дулкын – Бөек Ватан сугышы, нәтиҗә: 26 дан 40 миллионга якын киселгән кеше гомере – нигездә (в основном) яшь ирләр. Дүртенче дулкын – үзгәртеп кору (перестройка) һәм җимереклек, бөлгенлек (разруха), 1992 елдан үлүчеләр саны туучылар санныннан күбрәк, 10 елда халык саны 6 миллионга кимегән, һәр ел безнең илдә халык 1 миллионга кими һәм хәзер статистика аның саны 146 миллион ди. Бу хәлне В. В. Путинның материнский капиталы туктатты.

*Авыр һәм газаплы 37 нче ел.*
*Аерды ул безне әти – әниләрдән,*
*Туганнардан, якыннардан, дуслардан,*
*Калдырды ялгызыбызны ул чакта,*
*Олы кайгы хәсрәт белән киләчәккә.*
*Бүген без врачлар да, укытучы да,*
*Профессор да, директор да, артист, та*
*Шәфкать туташы да, журналист та,*
*Һәм депутат та хәтта Госсовет та.*
*Ничек ирештек без уңышларга?*
*Кем булышты безгә ул елларда?*
*Уйлыйсызмы сез шул хакта?*
*Кем булышты безгә исән калырга?*
*Кем булышты безгә ул чакта?*
*Без бит ялгыз идек, ятим идек,*
*Якламады безне беркем,*
*Чолгап алган иде безне салкын*
*Һәм рәхимсез өер-төркем.*
*Ачлык, суык өтте безне ул вакытта,*
*Бер кем кул бирмәде безгә,*
*Кинәт арты белән борылды бар да,*
*Көтмәгәндә бер мизгелдә.*
*Тик ихтиар көче безнең бик нык иде,*
*Шул булышты безгә исән калырга,*
*Барлык кыенлыкларны җиңеп,*
*Көч һәм дәрт-дәрман алырга.*
*Үз көчебез белән ирештек без уңышларга,*

*Өлге булдык көнләшергә башкаларга,*
*Үрнәк булдык балаларга, оныкларга,*
*Иптәшләргә, хезмәттәшләргә, дусларга.*
*Үтеп китте ул дәһшәтле еллар,*
*Килеп җиттек без бүгенге көнгә.*
*Рухыбыз безнең әле һаман нык һәм көр,*
*Кайвакытта без хәлсезләр, авырулар.*
*Сындыра алмады безне авыр еллар,*
*Акыл һәм дөреслек рухландырды безне,*
*Һәм ярату туган илебезне!!!*

Авторлар: репрессия корбаннары Сәлимова Флюра Рахман кызы, урыннары җәннәттә булсын! Муртазин Нәҗип Мөҗип улы.

Россия кичергән фаҗигаларның иң коточкычы Сталин репрессияләре, шунда безнең халык исәпсез-хисапсыз кырылган да инде. ОРПР рәисе буларак миңа бик күп эшләр майтарырга туры килде. Идел буе Район администрациясе, социаль яклау бүлекләре белән тыгыз бәйләнештә булып, алар ягыннан һәрвакыт ярдәм тойдым. Маркелов Вадим Сергеевич администрация башлыгы булганда, аңа турыдан-туры кереп бөтен сорауларны чишеп була иде, рәхмәт аңа, ул безнең оешманы ихтирам итте.

Безнең оешмада күбесе зыян күрүчеләр (пострадавшие) булып санала иде, Активистларыбыз Бурлаков Вячеслав Георгиевич, аның әтисе атылган Һәм Гатин Габдрахман Бари улы Ерак Көнчыгышка, Амур өлкәсендә гаиләсе белән сөрелеп, биш

энесен (алар анда үлгәннәр) калдырып кайткан, 250 ләп суд утырышларын уздыргач, без аларга бик рәхмәтлебез, безнең зыян күрүчеләр (пострадавшие) репрессия корбаннарына (репрессированные) әверелде. Оешма идарәсенә дә күп эшләргә туры килде, үзебезнең кешеләргә хәбәр итеп, гаризалар яздырып, суд утырышларына чакырып, үзебез дә шунда йөреп, вакытыбызны, көчебезне кызганмадык.

Шулай ук безнең энтузиастлар – репрессия корбаннары Архангел зиратында нахактан атылган 2756 корбанның исемнәре стелаларда язылсын өчен күп энергияләрен сарыф иттеләр, бу – В. Г. Бурлаков, А. Ф. Степанов, Н. П. Ананьев. Каримов Равиль Каюм улына без чиксез рәхмәтлебез, ул барлык стелаларны үз акчасына ясатты, Идел буе районы Администрация башлыгы булганда безгә күп ярдәм итте. 1998 елның 30 октябрендә өч стела куелды, аннан соң берничә елдан соң барысы да торгызылды.

Кайбер репрессияләнгәннәр шул стелаларда туганнарын таптылар, мәсьәлән, безнең В. А. Митькога КГБ дан сугыш вакытында әтиең үпкә ялкынсынуыннан (пневмониядән) үлде дигән белешмә килә, ә Митько әтисенең 1937 елда ук атылган икәнен стеладан белде, бер ай урын өстендә ятты, андый зур кайгы кичерүчеләргә, икенче мәртәбә үтерелүне белүчеләргә бик авыр булды, мин моңа шаһит. Безнең икенче казанышыбыз – университет скверында репрессия корбаннарына һәйкәл торгызу. Монда да

безнең инициативасыз булмады. Һәйкәл барлыкка килгәнче күп еллар узды, без җиңдек, җиңүне яуларга, әлеге дә баягы В. Г. Бурлаков, Г. Б. Гатин, А. Ф. Степанов йөределәр, казырга, техника кулланырга һ.б. акча эзләделәр, әлбәттә, иң башта һәйкәлне торгызырга, урыны турында рөхсәт һәм проект кирәк иде, аны әнисе репрессия корбаны булган Ирина Александровна Аксенова эшләде.

Ул вакытта Казан шәһәре башлыгы (мэры) хөрмәтле Камиль Шамиль улы Исхаков иде, ул без күптән көткән һәйкәлне торгызу турында карар (решение) кабул итте, моның өчен без аңа чиксез (безмерно) рәхмәтлебез, һәм проект турында сорады, безнең проект әзер иде.

Ахыр чиктә барлык Татарстан репрессия корбаннары көткән һәйкәл үзенең урынында 2004 елның 30 октябрендә торгызылды. Ул НКВД бинасына карап тора, аның подвалында безнең газиз туганнарыбызны җәзалаганнар, яккан ялаларын таныту өчен нинди генә җәза: кул бармакларын ишеккә кыстыру, ирләрне ялангач чишендереп, итекләр белән женси органнарын таптау, моны «колун» кушаматын йөреткән монстр эшләгән, аның кулына эләккәннәрнең 100% «гәепләрен» таныганнар. Җәзаларның төрләре санап бетергесез булган.

«Халык дошманнарының» ыңгырашканарын һәйкәл торган урында көне-төне берәр хәбәр көтеп торучы якыннары ишеткәннәрдер. НКВД бинасы

Дзержинский урамында тора, без – репрессия корбаннары мондый исемле урам булуын теләмибез, хәтта минем 30 мең халкы булган туган шәһәремдә бу Дзержинский урамы юкка чыкты. Казанда да ул урамның исеме үзгәртелергә тиеш, кайда гына хатлар язмадык: президентыбызга да, Министрлар кабинетына да, Югары Советка да, Мэриягәдә һ.б. барысы 8 урынга, безне тыңламадылар да, ишетмәделәр дә, хатларны Казан администрациясенә, Андреева Л. Н. га төшерделәр, ул формаль җаваплар белән чикләнде, имеш күздә махсус сквер төзү тотыла, анда репрессия корбаннары исемнәре язылачак, әл дә бу вәгъдә тормышка ашмады, акча юк һ.б. сәбәпләр белән юкка чыкты.

Шунда шагыйрә ЕленаЖукованың сүзләре искә төшә:

*Великие стройки великий народ*
*Построил, отдав свои жизни:*
*Норильск и Омлаг, Воркута и Дальстрой,*
*Интлаг, Магадан и, Наушки.*
*Челябинск, Стройлаг, Особлаг, Уренгой,*
*Стрижавка, Берлаг и «сухуми»,*
*Мосты и причалы, в Москве метрострой,*
*Заводы, плотины и верфи.*
*Да разве же все перечислить,*
*Что зек наш построить сумел.*
*На стройках их тысячи гибли,*
*Кому не достался расстрел.*

*Отцы, умирая, телами*
*Согрели земли мерзлоту.*
*Построенными городами*
*Потомкам несли теплоту.*

Ф. Э. Дзержинский ВЧК рәисе булганда масса – күләм террорның инициаторы булып, «кызыл террорда» актив катнаша, күп кеше гомере аның намусында (на его совести), кушаматы да бит аның «железный Феликс». Нигә Казанда һаман да Дзержинский урамы бар, ә Мәскәүдә аның исемендәге Мәйдан яңадан Лубянка дип атала һәм һәйкәле дә төшерелгән. БВС (Бөек Ватан сугышында) һәлак булганнар һәм НКВД корбаннары бер дәрәҗәдә булырга тиешләр, алар барысы да безнең ватандашларыбыз бит, язмышлары гына аларның төрле.

Һәйкәлебез бар, НКВД корбаннарына багышланган урам да булырга тиеш дип өметләнәбез. Бакчага барганда, миңа Латыш укчылары урамы тукталышын үтәргә туры килә, Казан топонимика комиссиясе ул урамны атаганда бераз тарих белән кызыксынды микән?

30 Октябрь – репрессия корбаннарын искә алу көне, шул уңайдан Архангел зиратында ел саен 30 октябрьдә, сәгать 10 да гаепсездән атылган корбаннарны искә алу була, төрле конфессиядәге дин әһелләре, ислам, православие динен тотучылар, католиклар, яһүдләр, лютераннар репрессия корбаннары рухына дога кылалар. Бу чараны Идел буе районы

хәзерли, безнең һәм Вольфович Инесса Моисеевнаның монда өлеше бик зур: тавыш көчәйткеч табу, төрле дин әһелләрен чакыру, чараларга шәһәр администрциясеннән рөхсәт алу һ.б.

Бер мәртәбә, бу 2007 елда булды, халык җыелды, төрле дин конфессияләре килде, ә безнең имамыбыз юк, вакыт уза, ни эшләргә, халык арасыннан коръән укучыны эзлим, бер кем дә риза түгел, ТРсы репрессия корбаннары берләшмәсенең рәисе миннән «Сез башламассызмы икән», дип сорады, әлбәттә, башта каушап калдым, чыгып бастым микрофон каршына, бөтен энергиямне туплап, башладым, миндә ораторлык һөнәре юк түгел, 40 ел укыткач, матур иттереп коръән укыдым, нахактан атылып, шаһит булып киткәннәргә догаларымны багышладым, шул минутлар өчен газиз эткәем лагерьдан кайткач, 10 яшемдә миңа догалар өйрәткән икән дип уйладым, шундый зур эшне башкарып чыгуыма мин чиксез шат идем, ничә ел үтте, ә мин һаман зур канәгатьлелек кичерәм. Икенче көнне ниндидер гәҗит имам килмәде, бер ханым launched зиратта коръән укыды дип язган, минем исемемне язмаганнарына шатландым, нигәдер оялдым.

Аннан соң безне автобусларда һәйкәл янына алып баралар, анда без үзебезнең якыннарыбызны искә алабыз, нигә күп льготалар юкка чыккан, аларны кире кайтару юлларын эзлибез, шәһәр чиновникларының чыгышларын тыңлыйбыз, мөһим сораулары-

бызга җавап көтәбез, алар безгә нәрсә әйтә алсыннар, кайбер регионнарда безнең льготалар сакланган, бу мәсьәлә регион башлыгы тарафыннан хәл ителергә тиеш, безнең Республикада моны уңай чишеп була, репрессия корбаннарының саны бик кимеде, без китүче категория, урта яшебез 78-80, өстәвенә барысы диярлек сугыш балалары. Шундый ачы язмышлы кешеләрнең калган гомере фатир өчен түләгәч, ничек ашарга җиткерим икән дип үтмәсен иде.

2007 елда 1937 елның канлы репрессияләренең югары ноктасына (пику репрессий) 70 ел булды. Шул уңайдан минем башыма әтиләре атылганнарның күңелләрен күтәрерү турында бик яхшы фикер килде, Менә нәрсәдән бу фикер гыйбарәт иде: без Һади Такташ урамындагы бер кафега әтиләре атылган мөселманнарны җыеп, абыстай чакырып, коръән укыттык, һәркем әтисен атады, алар рухына дога кылынды, аннан соң башка көнне православие дине тотучыларны җыеп, панихида уздырдык. Мөселманнарга безнең милли ашлар, ә христианнарга үз ашларын хәзерләдек, монда безгә кафенең хуҗасы ярдәм итте, ике очракта да өстәл тулы ризык иде, христианнар шәмнәр яндырдылар, һәркемнең нахактан һәлак булган атасының рухына догалар багышланды, ул көннәрдәге килгән кешеләрнең һәм үземнең зур канәгатьлек кичергәнебез әл дә истә.

2017 елда 37 елларның канлы Сталин репрессияләренең пигына 80 ел тула, спосорлар биргән акча-

ны хәзерләп куйдым, инде саулык булып, шундый чараны аллам тагын да насыйп итсә иде дип йөргәндә, акчабыз сакланган Анкор Банк банкрот булды, акчабызны кайтарырга бернинди өмет юк, ни эшләргә дигән сорау миңа тынычлык бирми. Тагын спонсорлар эзлим, бу юнәлештә мин 20 ел буена остардым, иманым камил, барысы да, аллаһы боерса, гамәлгә ашачак.

Атна саен үзебезнең администрация тарафыннан бирелгән бүлмәбездә оешма әгъзаларын кабул итәбез, бүлмәбез 2015 елдан башлап, КЗИО (комитет земельных и имущественных отношений) тарафыннан безгә арендага бирелде. Ул рөхсәтне алыр өчен ярты еллап йөредем, без хәзер бүлмәбездә законлы утыруыбызга бик шат. Килгән кешеләребезгә репрессиягә кагылган төрле консультацияләр бирәбез: таныклыгыбызны ничек алырга, таланган малларга компенсация алу юлларын өйрәтәбез, гаризалар язабыз, бездә булган Хәтер китапларын, гәҗитләр, спонсорлардан алган даруларны, ведомость белән акчаларны һ.б. әйберләрне, концертларга, театрларга билетлар таратабыз. Ул билетлар артыннан хатлар белән җырчыларга, төрле чаралар уздырылган урыннарга йөрибез, нинди генә һава булмасын, үзебезнең кешеләрне ишек янында кертергә көтәбез.

Күп җырчылар безне үз концертларына бушлай кабул иттеләр. 30 лап кешене китерергә рөхсәт биреп, концертта күп тамашачылар булса да, безне

яхшы урыннага утырттылар, аларга олы рәхмәтебезне белдерәбез, Менә алар: Илһам Шакиров, Салават, Хәния Фәрхи, Резедә Шарафеева, Габдельфәт Сафин, Айдар Галимов, Зөфәр Хәйретдинов, Илсур Сафин һ.б. Спонсорлар белән эшләү җиңел эш түгел, моның белән безнең оешмада өч кеше генә шөгыльләнде, кадерле Сабирҗанов Мостафа Гариф улы 2016 елның 24 июнендә арабыздан китте, гаиләсе белән Красноярск краена сөрелеп, шуннан 1942 елның октябрендә 20 яшендә сугышка алына, элемтәче булып Мәскәүдән Калининградка кадәр җиткән, бөтен күкрәге орден, медальләр белән тулган рядовой булып алынып, рота командиры дәрәҗәсенә җиткән өлкән лейтенант булып сугышны тәмамлаган, көләч йөзле, юмарт, безнең оешма өчен спонсорлардан төп акча табучы иде. Потенциаль спонсор тапкач, миңа кем икәнен, адресын әйтеп, үтенеч хаты язарга сорый иде, мин шунда ук, язып, печатебезне басып, аңа тапшыра идем, рәтләп күзләре күрми башлады, йөрүләре дә авырайды, әмма ләкин ярдәм итәргә, утырышларыбызга килергә һәрвакыт әзер иде, рухлары шат булып, безгә риза булсын Мостафа абыебыз.

Икенче булып спонсорларга үзем йөредем, күп хатлар яздым, бу гамәльдә остарып беттем, барысыннан да уңай җавап булмады, уңай җавапларга әле рәхмәт хатлары да язырга кирәк була иде. Өченче спонсорлар белән эшләүчебез әтисе атылган, 47 ел

стоматолог булып эшләгән, югары категория табибе Нәҗипова Земфира Габдрахман кызы булды. Аның бурычы – дарулар табу иде, ул бу эшен яхшы башкарды, берничә мәртәбә «Татхимфармпрепараты» дан бушлай дарулар алып кайтты, әлбәттә, сорау хатларын мин язам, ә нинди дарулар, аны биргәч, нинди машина белән китерү аның баш авыруы иде. Шулай итеп, акчаны, даруларны, китап-гәҗитләрне кешеләрне чакырып, таратабыз.

Бер вакыт безгә яхшы сыйфатта немецлардан килгән хатын-кыз киемнәре бирделәр, нәрсә генә юк иде анда: көзге, кышкы пәлтәләр, чалбарлар, костюмнар һ.б., үзебезнең кешеләребезне чакырып, алларына куябыз, нәрсә ошый, шуны сайлап алалар, Исемдә, Фәнзия апа Вәлиева апасы белән килде, ике кышкы, ике көзге пәлтәне карыйлар, кайсын сайларга белмиләр, баш ваталар. Мин сорыйм, «Фәнзия апа, дүртесен дә аласыгыз киләме? Ярыймы?» – диде ул, «алыгыз» дигәч, аларның шатланганын күрү үземә дә зур шатлык иде. Күп вакыт үтмәде, Фәнзия апа килгән, өстендә норка якалы пәлтә. Мин, «Кайдан бу матур пәлтә», дип сорагач, «үзең бирдең ич», – ди. Ул безгә еш йөри иде, өемә дә күп мәртәбәләр килгәне бар, хәзер картайды, фатирыннан чыкмый, бирәсе әйбер булса, кураторы Рахимова Резидә Фатих кызы өенә алып бара. Резидә белән без оешмабызда очраштык, икебез дә КДУ ның физматында, бер үк белгечлектә бер үк педагогларда укыган-

быз икән, мин 5 ел элек. Ул намуслы, принципиаль кеше, үзенең карамагындагы репрессия корбаннары турында барысын белә, чын күңелдән аларга ярдәм итә.

Идарә әгъзалары саны буенча без Идел буе районын 7 участокка бүлдек, һәркемнең үзенә беркетелгән урамнары, исемлекләре, адреслары, телефоннары бар. Берәр нинди хәбәр, яңалык булса, кураторлар үзләренең кешеләре белән элемтәгә керәләр, өйләренә баралар, йөри алмаганнарның хәлләрен беләләр, Кураторлар үзләре дә репрессия корбаннары, барысы да түләүсез эшли. Менә алар: Нәҗипова Земфира, әтисе атылган, Рахимова Резидә, әтисе 9,5 ел концлагерьдә урман кискән, Шигабутдинова Дилара, әтисе атылган, Габдрахманова Илсөяр, әтисе 9 ел гомерен концлагерьда сарыф иткән, Таишева Сания әтисе, әнисе биш балалары белән мәҗбүри рәвештә Магнитогорск металлург заводын төзергә сөрелгән, 18 елдан соң аларга кайтырга рөхсәт биргәннәр, Митько Вячеслав, әтисе атылган, Хуснутдинова Рәхимә Гарей кызы бөтен гаиләсе белән Амур өлкәсенә сөрелгән, барысы да тормышның ачысын күргәннәр, аларга мин үземә ышанган кебек ышанам, алар үзләренең кешеләрен уңайсыз хәлдә калдырмаячаклар, ярдәм итәчәкләр.

Спонсорлар табу теләге белән сайлау компанияләрендә катнашкаладык, кандидатларга ярдәм иттек, гадәттәгечә сайлауларга кадәр алтын таулар би-

рергә ризалар, аннан соң син кем дә димиләр. Хәзер дә Госсоветта депутат булып йөрүче бер адәм элек безнең оешмага 40 мең, аннан 20 мең, киметә-киметә бер мең дип әйтергә оятына көч килмәде, үзеңә калдыр, дидем. Аның сайлаучылар белән очрашуларына күпме йөредем, исемдә кар ерып баруларым, аның өчен тавыш бирегез дип үгетләүләрем, шундый кешеләр гади халыкның ихтыяҗларын аңлый мени, бик үкенечкә калды, юкка йөрүем. Эх, Сизиф хезмәте белән шөгыльләнгәнмен икән дип уфтандым.

Безнең льготалар бөтенләй диярлек юкка чыккач, ярдәм сорап, РФ Думасына, ТР президентына, Госсовет депутатларына, Министрлар кабинетына хатлар язып, имзалар җыеп, күп йөредек, файдасы гына булмады. Бер мәртәбә кышның суыгында, 25 градус салкында, өч мәртәбә Госсовет утырышына туры китереп, юл билетларын (проезднойларны) калдыруны таләп итеп, Ирек мәйданына чыктык, хөрмәтле депутатыбызТуфан Миннуллин шунда: «Әбиләрне соңгы шатлыкларыннан да мәхрүм итмик», – дигән, рухлары шат булып, урыннары җәннәттә булсын. Туфан абый үз милләте өчен янып-көеп йөреде, шуңа да йөрәге чыдамагандыр.

Безнең илдәге канлы репрессияләр кебек үз халкың өстендә геноцид кабатланмасын өчен мин радио, телевидение, матбугатны файдаланырга тырышам, мәкаләләр язам, үз илемә дә: туган шәһәремә

«Тарское прииртышье», Омскига «Татар дөньясы» газеталарына һ.б., барлык идарәбез белән мәктәпләрдә, көллиятләрдә репрессия темасына лекцияләр укыйбыз, концертларда тамашачыларга Хәсән Туфан сүзләренә, Марс Макаров музыкасына язылган «Киек казлар» ын еш җырлыйм.

Ел да Кызыл байракка Салих Сайдәш бәйрәменә йөредек, быел да, 2016 елда бардык. Галиасгар Камал театры администрациясе рәхим итеп, автобуста безгә урыннар бирде.

Ел ахырында, шул елның юбилярларын җыеп, спонсорлар акчасына өстәл хәзерләп, мәктәп укучылары белән концерт күрсәтеп, үзебез дә катнашып, безнең репрессия корбаннарына бәйрәм, тагын бик күңелле чара уздырганда безгә Казан шәһәре 95 нче мәктәп директоры Бакиров Равиль Сайфулла улы һәрвакыт колач җәеп каршы алып, ярдәм итә. Картлар көненә, Җиңү бәйрәме инвалидлар, һ.б. уңаеннан мәктәп укучылары концерты белән танталы очрашуга чакыра, өстәл хәзерли, хөрмәтли, шуңа Равиль Сайфулла улына без бик рәхмәтлебез. Мәктәп музеенда репрессия корбаннарына багышланган урын бар, анда Хәтер китабының барлык томнары, безнең темага кагылышлы әдәбият, гәҗит, журналлар һ.б. җыелган.

Бер картлар көненә социаль яклау бүлегеннән безгә 30 талон бирделәр Газовая урамындагы «Стрелка» дигән кафеда 30 кешегә 1 нче, 2 нче 3 нче-

не ашап китәргә, мин бу хәлне бәйрәмгә әверелдерергә булдым. Кафега барып, безнең теләкне аңлаттым, өстәлләрне янәшә куерга сорадым, бакчамнан матур алмалар, укроп, петрушка китереп, спонсорлар акчасына конфетлар сатып алып, җылы ашны, пешкән ризыкны кафе хәзерләп, баянчы чакырып, банкет оештырдык, ул вакытта С.П. Шашурин депутат иде, мин аңа: «Килеп безнең кешеләрне шатландырмассызмы икән?», – дип сорадым, ул үзенең ярдәмчесен җибәреп 100 сумнан тараттырды, ул вакытта 100 сумга яхшы гына ризык алып була иде. Барысы да бик канәгать булдылар С.П. Шашурин юмарт иде, ул безгә берничә мәртәбә матди ярдәм күрсәтте, шуңа без аңа рәхмәтлебез.

Баянчы Илгиз Усманов баянда уйнап, җырлап, биеп, мин гадәттәгечә үзем җырлап, кәеф-сафа кылдык. Төрле истәлекле вакыйгаларга: Җиңү бәйрәменә, картлар, әниләр, инвалидлар көненә һ.б. чараларга безнең социаль яклау бүлеге чакыру билетлары биреп безне чакыра, билетлар күп булмый 10-15, элек 30-40 була иде. Шулай итеп, без Болгарда да, әле җимерек чагында борынгы кабер ташларын күрдек, хәзер Болгарны күреп, горурланабыз, Свияжск төрмәләрендәге казематларда Хәсән Туфанның, Фәтхи Бурнашның һ.б. газап чиккәннәрен белдек. Анда репрессия кобаннарына һәйкәл ачылганда да, безне автобусларда алып бардылар, аннан соң җыелыш булды, шунда газап чиккән, һәлак бул-

ган репрессия корбаннарының туганнары чыгыш ясадылар, үзем дә тетрәнеп, Хәсән Туфанның «Киек казларын» үксеп җырладым, чөнки мин аның монда гына 10 ел гомере узганын белеп, шаккаттым, бу җырны аңа кадәр дә еш җырлый идем, «Киек казларны» без гимныбыз итеп саныйбыз.

Күп еллар элек Раифа монастырендә дә булдык. Ул чакта экскурсия җитәкчесе Раифада репрессия елларында «халык дошманнарын» тотканнар, җәзалаганнар, пыткалардан соң ярым үлгән кешеләр янына ач күселәр җибәргәннәр дип сөйләде, нинди вәхшилек (кощунстсво)!!! Шундый җәзаны уйлап тапкан кабахәтне нинди ана тудырган, күкрәк сөтен имезгән икән? Хәзер Раифада 30 елларда төрмә булуын сөйләмиләр.

Безнең башкарган эшләрнең иң күңеллесе: Идел буйлап теплоходларда йөзү. Биш мәртәбә, башта өч ел рәттән 2007, 2008, 2009, аннан 2015, 2016 елларда льготный бәяләр белән Әстерханга, Ярославльга, ике мәртәбә Волградка, Кинешмага, Уфага бардык, льготалы, ташламалар белән юлламаларны (путевкаларны) безгә һәрвакыт «Волжские путешествия» фирмасының Генераль Директоры Самолин Вячеслав Андреевич бирә, ул безне ихтирам итә, безнең материаль мөмкинлегебезне белә, ярдәм итәргә тырыша.

Волгоградка китәр алдыннан мин ТР Конгрессына кереп, андагы татар үзәгенең телефонын алдым

һәм теплоходта килүебезне, милләттәшләребезгә концерт бирүебезне әйттем, Безнең Конгресс нәрсә белән шөгыльләнәдер, мин ярдәм сорагач, ваемсызлык күрсәттеләр, ярдәмнәре – телефон номерын бирүдән артмады, шунда ТР Конгрессыннан күңелем кайтты. Шулай итеп, Конгресстан, коры кул белән (не солоно хлебавши) Волгоградка йөзеп киттек, аның пристанендә безне өч машина көтә иде, безнең «Гөлҗамалны» паркка алып киттеләр, 30 градус эсседә концерт бирдек, сәхнә кояшка карап тора, безгә эссе, ә тамашачылар зонт, агач яфраклары асларында безгә кушылып җырлыйлар, безне гөлләргә күмделәр, яраткан җырларын Сарман, Рәйхан, Рамайларны җырларга сорадылар, без, битебездән тир акса да, милләттәшләребезгә рәхәтләнеп җырладык, концерттан соң өстәл артына утырттылар, ничек кенә сыйларга белмәделәр.

Кайтыр вакытлар да җитте, безне теплоходыбыз көтә иде. Волгоград милләттәшләребез «Җидегән чишмәне» җырлап, моңсуланып озатып калдылар, тагын килүебезне сорадылар. Әйе, безнең Казан чит төбәк татарлары өчен Мәккә, аларны күбрәк кайгыртырга иде шул, тик бу аерым ансамбльләр хәленнән генә килә торган эш түгел шул. Кочак, кочак чәчәкләребез белән Жолио-Кюри дигән теплоходыбызга юл тоттык, безне машиналарда озатып куйдылар.

Без герой шәһәребез Волгоградны, Мамай курганын калдырып, Идел буйлап йөзеп киттек, барлык чәчәкләрне палубадан суга ташладык, Идел су өсте чәчәк белән тулды, чәчәк аткан сыман, шулай без һәлак булган сугышчыларыбызга баш идек.

Кичен теплоходта безнең «Гөлҗамал» ансамбле Җиңү бәйрәменә багышланган концерт бирде, башта татарча, аннан соң интернациональ концерт, без татарлар бик сәләтле халык бит: кирәк икән татарча, кирәк икән урысча җырлыйбыз, шунсы әһәмияткә ия, җырны башласак, сүзләрен ахырына кадәр беләбез. Шулай бер ветераннар мәҗлесендә мин бүләк итеп, русча «Не пробуждай воспоминаний» дигән романсны җырлый башладым, бер урыс ханым «мин дә җырлыйм», – дип, яныма чыгып басты, мин аңа микрофонны сузып, «җырла», – дидем, «мин сүзләрен белмим» диде, – менә шулай. Татарча җырлаганыбызны яратмыйлар, үз телләрендә җырларлар иде – сүзләрен белмиләр. Без үзебезнең татар моңын Идел буйлап йөзгәндә, палубада, безнең белән бергә туктап торган теплоходтагы милләттәшләргә җырладык, яр буеннан кул болгыйлар, теплоходларда бергә җырлыйлар иде, үзебезнең палубада көн дә татар моңын яңгыраттык.

Зур хәзерлек белән без ел да Репрессия корбаннарын искә алуга багышланган 30 октябрь көнен уздырабыз, бу чарада безгә киң күңел, ачык йөз белән, Чулпан мәдәни үзәге, хәзер ул ябылды, Автотранс-

порт техникумы дирекциясе һәм Казан шәһәре 5 нче музыкаль мәктәп директоры Айрат Загир улы Ярул-лин, 2007 елдан 2014 елга кадәр җыелышларыбызны уздырырга ярдәм итте. Алдан ук хәзерләнүдә, алып баруда үзенең көчен дә, вакытын да кызганмады. Концертка төрледән төрле югары дәрәҗәле номер-лар: җыр, музыка коралларында уйнаучы укучыла-рын, укытучыларын бирде, концерт барганда, аның белән музыка пульты артында утырып, җитәкчелек итте, чын музыкант, үз эшен яратып башкаручы югары профессиональ белгеч итеп күрсәтте ул үзен алып баручы укытучылар да үзенә иш (подстать) иделәр. Айрат Загир улына без, репрессия корбанна-ры, бик рәхмәтлебез, аның яхшылыгын бер дә оныт-маячакбыз, без һәрвакыт аның ягында.

Күп эшләгән кешене бездә бик яратып бетер-миләр шул. «Нигә мин түгел», – диләр, ә үзләренең хәленнән килми. Бер вакыт әтием, мәрхүмгә, бер ханым турында зарланган идем, «синең бауыңны ишә алмаганга, кызым, ул үзен шулай тота», – дигән иде. Безнең репрессия корбаннарын искә алу җые-нында зыялы атылган, лагерьларда һәлак булган, сөрелгәннәрнең һ.б. балалары җыела, хәзер инде ба-лалары гына, чөнки турыдан туры үзләре төрмәдә утырганнар, лагерьда газап чиккәннәр һ.б. урын өстендәләр яисә бакыйлыкка күчкәннәр, алар бик аз. Безгә ата-бабаларыбызның асыл геннары күчкән, без аларны күрү бәхетенә ирешә алмасак та, юга-

ры мәдәниятнең нәрсә икәнен беләбез, бөтендөнья классикасын тыңлау үзе зур бәйрәм, моңа 8 ел дәверендә Айрат Загир улы мөмкинлек бирде. Мәсьәлән, 2007 елның 31 октябре, сәгать 13, зал тулы, сәхнәгә мәктәп укытучыларының скрипка ансамбле чыгып баса һәм Иоган-Себастьян Бахның «Жалобасы «яңгырый, беркем дә ваемсыз кала алмады, күзләребездә яшь, йөрәгебездә әрнү иде, аннан соң Рөстәм Яхинның «Киек казлар китә» дигән моңы яңгырады, шулай бу юлы да самими җыр, моң, чыгышлар 1,5 сәгать дәвам итте, безнең җыеннан күңелләре китек кешеләр канәгатьлек тойдылар, администрация тараткан символик бүләкләр дә кәефне боза алмады.

2015 елның 30 октябрен безгә Идел буе районы администрциясе Һәм социаль яклау бүлеге уздырдылар, Казан мәдәни институтының студентлары үзләренең чыгышы, мини спектакльләре белән безне канлы репрессия көннәренә, кичерешләргә алып кайттылар, чөнки сәхнәдә кулга алулар, чуар киемнәрдәге зеклар, сорау алулар, җәза кулланулар һ.б. сүрәтләнделәр, кайберәүләр валидолга тотынды, студентларның безнең язмышны тирәнтен аңлап, сәхнәдә күрсәтүләре, бу яшь буынга мондый нахаклыкны, югалтуларны кичерергә туры килмәсен иде дип уйларга кала. Мин ОРПР рәисе булып, ике зур дәфтәр (конторская книга) көндәлек алып бардым, шунда үземнең оешма да эшләнгән эшләрем турында да яздым, көндәлегем бу истәлекләремне язарга

мөмкинлек бирде, барсын файдалансаң, ялыктыргыч фәлсәфә булыр иде. Тагын сәясәтче һәм язучы Иван Ильин сүзләрен китерәсем килә:

«Килер шундый вакыт ки, гаделле тикшеренүләр нәтиҗәсендә юк ителгән, лагерьларга хөкем ителгән, куылган, сөрелгәннәр саны ачыклангач, бөтендөнья үз күзләренә һәм колакларына ышанмас».

Шуңа без дәүләтебез безнең җимерелгән тормышыбыз, һәлак булган ата-бабаларыбыз өчен гафу үтенер микән, таланган мөлкәтебез, мораль һәм физик югалтулар, зыян китергәне өчен бер генә мәртәбә (единовременно) булса да компенсация түләр микән, без моны реабилитацияләнгән моменттан көтәбез. Ул вакытта чит илләр халкы да безне ихтирам итәрләр иде.

## 14. ТАтар халык җыры – моң чишмәсе ул 70

Татар кешесе үзенең шатлыгын да кайгысын да гасырлар буена җыр, моң аркылы чагылдырган. Нинди генә татар халык җырын алма, аның моңында да, сүзләрендә дә тирән мәгънә ята, моны мин җырлый башлагач аңладым.

Минем җырлауым бик соң башланды – пенсиягә чыккач, әниемне югалткач, әтием инде юк иде, аның «Уеллары», «Иске кара урманнары», «Саҗидәләре» исемә төшә башлады, ә мин бит аларны 10 яшемдә, әтием совет концлагереннан кайткач, тыңладым, аның тавышы искиткеч матур, моңлы иде, 10 ел буена нахактан лагерьларда газап чиксәң, кайткач та 9 ел һаман «халык дошманы «булып саналсаң, яраткан укытучылык эшеңә юл ябылса, моңланырсың да.

Безнең һәрбер халык җырын мини спектакль дип санап була, аларны тыңлагач, эчтәлеге күз алдыңа килеп баса. Моңа бик күп мисаллар: «Гөлҗамал», «Порт-Артур», «Көзге ачы җилләрдә», «Уел», «Себер татарлары җыры» һәм башка бик күп җырлар, алар санап бетергесез, мин аларны бик яратып башкарам. Безнең җырларны матур, моңлы җырласаң, башка милләт кешеләренең дә тәне чымырдый, бу хәлне мин Себердә, Вильнюста, Мәскәүдә, башка төбәкләрдә күзәттем. Безнең җырларның шундый тәэсиренә мин, әлбәттә, бик шат идем.

Минем җырлый башлауым очраклы башланды, КХТИ да югары математика кафедрасында укыткан чагым, укытучылар бүлмәсендә пианино булып, безнең бер профессор төрле көйләр уйнап утыра, мин Рөстәм Яхинның «Син кайда идең» җырын уйнарга сорадым, ә ул җырлап күрсәтегез диде, мин җырлап күрсәттем, уйнаучыга ошагач, мине ул чакта Идел буе студентлар олимпиадасында җырларга сорадылар, мин риза булдым, шуннан халык алдында (публично) җырлый башладым.

Казанның һәрбер районында ветераннар өчен Көндезге ял итү үзәге (Стационар дневного пребывания) дигән нәрсә бар иде. Бу – стационарларда гомер буена эшләп, ялга чыккан ветераннар яртышар көн ике атна буена ял итәләр иде, иртән бер сумса белән бер стакан чәй эчеп, көндез беренче, икенче, өченчене ашап, аннан соң төрле лекцияләр тыңлап, концертлар карап, үзләренең талатларын күрсәтеп, ә алар аз түгел иде: рәссамнар, шагыйрьләр, җырчылар, төрле музыка коралларында уйнаучылр, һ.б., төрле экскурсияләргә барып, үзе китергән дарулар белән уколлар, массаж алып, кәеф-сафа корып, кайтып китәләр иде, себерәк әйтмешли бу ветераннарның мәдәни-күңел ачу үзәкләре кемнеңдер итенә тигән ахыры, алар барысы да берәм-берәм ябылды. Ул вакытта министрлар кабинеты рәисе Минниханова, Метшинга, Мөхәммәтшиннарга, Һ.б. имзалар җыеп, үзәкләрне калдыруны сорап хатлар җибәрдек, файдасы булмады.

Без хатларда бушлай әбәтләрдән ваз кичәргә ризабыз, шул Р. Зорге урамы, 35 йортындагы 4 бүлмәле квартирада урнашкан мәдәни-ял итү үзәген без – Бөек Ватан Сугышы, тыл ветераннары, Сталин репрессияләре корбаннары, Ленинград блокадасын, немец балалар концлагерьларын узганнар һ.б. калдырырга үтенгән идек. Булмады.

Башта без курайда, мандолинада татар халык көйләрен профессиянал башкаручы Вольфрам Газеев белән «Гөлҗамал» исемле вокаль-инструменталь дуэт (ВИД) ны оештырдык, шул көндез ял итү үзәгендә ул ябылганчы атна саен концерт бирдек, нинди генә җырлар җырламадык, Вольфрам мандолина, курайда татар халык көйләрен, чит ил мелодияләрен искиткеч моңлы, тәэсирле башкарды, безнең концерт биргән урыннар аз булмады: бу галимнәр йорты, күпме югары эрудицияле, талантлы кешеләрнең, балаларның белем, мәдәни үзәге иде. Кайда алар? Федосеев урамындагы картлар йорты, матур Казансу буенда иде, анда әби-бабайларга концертлар биреп, зур канәгатьләнү белән кайтып китә идек, аларның җырлауларын, язмышлары турында сөйләүләрен тыңлап, күңелләрен күтәрә торган чакларыбыз аз булмады, ул йорт та ябылды, урамның эзе дә калмады. Арча картлар йорты бик йөрәкне әрнетте, андагы әби-бабайларның күбесенең балалары бар, бер әбинең өч баласы әниләрен калдырып киткәннәр, араларында кызы да бар, үз картлыкларын

уйламыйлар микән алар, әтием мәрхүм әйтә иде, «табаклы аш кебек алдыңа килә барысы да», – дип. Күп мәртәбә җырлап йөрүебез Казандагы «Сөләймән» мәчетендә булды, анда без акопело җырладык, күзләре начар күргән, бөтенләй күрмәгән, төрле төбәкләрдән килгән дин кардәшләребезгә: Чечня, Ингушетия, Дагстан, Башкортстан һ.б. җирләрдән килгәннәргә, алар безнең белән бергә җырлыйлар иде, хәзер, чакырсалар, шатланып, мәһабәт «Ярдәм» мәчетенә барабыз, алар анда күчте.

Троицк урманындагы Казан радиосында чыгышлар ясадык, интервьюлар. бирдек, зыялы кешеләр, һәрберсе үзенең белгечлекләре өлкәсендә файдалы фикерләре, киңәшләре, фән яңалыклары белән теләгәннәргә аң белемнәрен күтәрәләр иде, хәтта шул радио аша мине туганнарым тапты, бервакыт мин радиодан «Гөлҗамалны» җырлагач, фамилиямне атагач, алар шалтыратып, без табыштык, ул да юкка чыкты.

8 ел буена безнең «Гөлҗамал» ансамбле ай саен Медиклар клубында концерт бирде. Ул мәһабәт сарайны (дворецны) җир белән тигезләделәр, аның холлары, икенче катка менә торган инкрустацияләр белән бизәлгән баскыч рәшәткәләре, грим бүлмәләрендәге матур өстәлләр, креслолар артистларга бизәнү көзгеләре һ.б. бик күп элекке заман предметлары (предметы старины), исемә төшсә, seберәк әйтмешли, эчем ачый. Клуб мөдире Сәйфутдинов Айдар Илдус улы безнең ансамбльне һәрвакыт мөләем

йөз, ихтирам белән каршы алып, концерт уздырырга берсүзсез рөхсәт бирә иде, без аңа зур рәхмәтләребезне әйтәбез, бик кызганыч клубның юкка чыгуы, күп татар моңын сөюче ветераннарның без күңелен күтәрдек, елаттык та, бергә җырлаттык та.

6.09.05-16.09.05, шундый периодка безнең Идел буе районының 4 репрессия корбанына Казан-Мәскәү-Казан круизына Казанның мең еллыгы уңаеннан оештырылган ветераннар фестиваленә юллама (путевка) бирделәр. Мин Идел буе районы өчен концертта катнашып, Гала-концертка үттем, татар җырлары, атап әйткәндә, борынгы халык җыры «Гөлҗамал», милли калорит белән башкарылган дип, миңа рәхмәт хаты һәм бүләк бирделәр, шуннан соң ансамблебезне «Гөлҗамал» дип атадык, безнең состав 7 кешедән тора башлады, исеменнән җисеме (суть) күренә: безнең максат татар халык җырларын, мәшһүр татар композиторларыбызның әсәрләрен башкару, яшьләргә дә җиткерү, саклап калу.

2005 елдан башлап җырлау дәверендә без үзебезнең Идел буе районында, шәһәребездә, авылларда күп чыгышлар ясадык, сабантуйларда, Республика көнендә катнаштык, «Балкыш» ветераннар фестивалендә яулаган дипломнарыбыз, грамоталарыбыз, рәхмәт хатларыбыз, хәтта Волгоградтан да алып кайткан мактау грамотабыз бар.

Безнең җырлаган урыннарыбыз санап бетергесез: Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан ел да

музеенда, Константин Васильев музеенда Бауман урамына күчкәнче, Сәйдаш музеенда һ.б. музейларда, күп мәртәбәләр «Санта», «Крутушка», «Волжанка», «Ливадия», «Васильево, «Дельфин» һ.б. санаторияләрдә,

Питрәчтә Күн авылындагы картлар йортында, Кайбычтагы Борындык авылында да, барлык җирдә бушлай җырладык һәм күп вакытта үз акчабызга юл расходын күтәрдек, Борындыкта җырлап кайткач, «Дулкын» гәҗитендә чыккан мәкаләдән өзек: «Менә кемнәрне сәхнәнең түренә менгезергә кирәк! Менә кемнәрне телевизордан күрсәтергә кирәк! Менә кемнәр ул чын татар моңын халыкка җиткерүчләр! Фәрзәнәнең башындагы калфагыннан да, өстендәге камзулыннан да, бала итәкле күлмәгеннән дә чын татар рухы сирпелеп тора. Моннан да зуррак бәя була аламы!

Идел буе районы администрациясе оештырган чараларда виртуоз баянчы Илгиз Усманов белән күп җырладык, минем дискомда җырларны ул уйнады алар арасында, «Гөлҗамал» көен уйнавы – минем өчен-шедевр, калган җырларны мандолинада Вольфрам Газеев уйнады. Ел да Сталин репрессия корбаннарын искә алган җыелышта без Илгиз белән Марс Макаров музыкасы, Хәсән Туфан сүзләренә язылган «Киек казлар» ны, репрессия корбаннарының гимнына әверелгән җырны башкардык, башка баянчылар, гармончылар, алар арасында Ринат Ва-

леев, Кирам Сатеев, Әнвәр Гиниятуллин һ.б. белән татар халык җырларын җырладым. Ансамблебез белән биргән концертларыбыз санап бетергесез.

2015 елда Дуслык йортында үзебезнең җыр эшчәнлегебезнең 10 елы уңаеннан чыгыш ясадык, шунда Бөтендөнья татар конгрессы «Гөлҗамал» ансамбленең һәрбер җырчысына, уен-коралында уйнаучысына – барыбызга рәхмәт хатлары тапшырды. Бу күңелле мизгелләрне кичерү-бәхет, зур шатлык иде.

Туган шәһәрем Тарада беренче мәртәбә концертымда җырлагач, туганна рымның, сабакташларымның, якташларымның исе китте, баянда икедән туган сеңлем Җинан уйнады «Фәрзәнә, син җырламый идең бит», – диләр. Мин көләм. Ә дөресен әйткәндә минем йөрәгем гаиләмдәге, нәселемдәге Сталин репрессияләрендә, сугыш кырларында һәлак булган туганнарым өчен, зур хыялым – татар милли университеты эшләп китмәгәнгә, анам телебез бетеп барганга әрнидер, шуңа моңланамдыр. «Ашказарлар», «Мәдинәкәйләр», «Сәгать чылбырлары» бөтенләй җырланмыйлар, «Сарманнар», «Шахталар», «Уеллар» онытылып бара. Хәзерге кайбер яшь композиторларның язган, җырланган җырларындагы сүзләрне урыс телендә җырласаң, татар, җырын, моңын танып булмый, бу минем шәхсән карашым, кайбер хәзерге заман татар җырларында кисәк-кисәк урыс мелодияләре дә сизелеп китә. Мин үземне чит

илләрдә: Австралия, Кытай, Финляндия, Америка һ.б. илләрдәге милләттәшләребез динне дә, моңны да, телне дә саклыйлар дип тынычланам.

«Мөгаллим» хорына мин очраклы рәвештә килеп эләктем. Мине «Гөлҗамал» ансамбле җитәкчесе буларак Идел буе администрациясенә «Балкыш» – 16 фестиваленә катнашу йөзеннән чакырдылар. «Гөлҗамал» ансамбле шәһәр җыелма (сводный) хорында һәм Идел буе районы өчен җырларга тиеш булып чыкты. Сводный хорны Алберт Зариф улы Шакиров җитәкли, ә Идел буе һәм Вахитов районнарының хорын Мулланур Гаян улы Габитов алып бара диделәр. Шуннан без ике урынга: Саид Галеев сараена һәм укытучылар йортына йөри башладык. Хорда җырлау җиңел эш түгел икән, әмма ләкин Мулланур Гаян улы үзенең эшенә җаны, тәне белән бирелгән, югары профессионал җырчы һәм хор җитәкчесе, тавышы, теләге булган һәркемне өйрәтә ала дип уйлыйм. Беренче мәртәбә «Мөгаллимнең» җырлауын тыңлап, таң калдым, шундый хорыбыз булганга бик шатландым. Мондый хорыбыз булгач, безнең телебез, моңыбыз үлми икән. Тик хорны югары биеклеккә күтәрергә кирәк, Казанда гына, Татарстанда гына түгел, ә РФ ның төбәкләрендә дә. Хорның уңышлы эшләүенә, күп булмаса да шартлар кирәк. Беренчесе, музыка белән алып бару (музыкальное сопровождение), хорның рәтле баяны да юк, ансы да начар янгыраса, бәргәләп алалар, элек телевизор начар күр-

сәтсә, аны бәргәли торган гадәтебез бар иде. Урыс әтмешли «и горько и смешно». Җырчыларга матур костюмнар да кирәк, хәзергеләре хан заманында тегелгән, ирләрнең бөтенләй юк. Бурановские бабушки бөтен дөньяны гизеп йөриләр, без алардан киммени?

Моң ул җанны-тәнне чистарта, күңелләрне йомшарта, тормышыңны яңа өметле юлга салырга, өндәргә мөмкин, мин моңа шаһит. Бервакыт бакчада агач төбендә өч ир эчеп яталар, мин яннарына килдем дә «Әйдәгез мин сезгә җырлап бирим», – дидем. Күз алдымда концлагерьда 10 ел гомерен сарыф иткән әтием өстәл артында «Уелны» җырлый. Нигәдер мин дә «Уелны» сузып җибәрдем. Җырлап туктагач, бөтен тәнен наколкалар каплаган урыс ире «минем тәнем чымырдый, каз тәне чыкты, нинди тормыш белән мин яшим», – дип сукрана башлады. Татар моңы уйландыра да, дәвалый да, җырлата да, елата да.

Безнең максат: онытыла барган җырларны хор, җыр ансамбльләре, төркемнәр, аерым җырлаучылар аркылы халыкка, яшь буынга җиткерергә. Татарстанда дүрт тавыш белән җырлаган, атап әйткәндә: сопрано, тенор, альт, бас белән бердәнбер «Мөгаллим» хорына ТР мәдәнияте, аерым җыр, моңны яратучы, милләтен ихтирам итүче кешеләр ярдәм итсеннәр иде.

## Йомгаклау сүзе

Бу китаптагы хәтирәләремне балаларыма, оныкларыма, оныкчыкларыма истәлек булсын дип яздым. Алар ата-бабаларының кем булуларын, чыгышлары кайдан, шөгыльләрен, аларның кешеләр сокланырлык сыйфатларын, эш сөючән, таза-сау, матур-чибәр булуларын белсеннәр, балаларын ятып, дөрес тәрбия биреп үстерүләрен белеп, горурлансыннар. Минем нәселем авыр язмышка дучар булган: карт бабам, карт әбиемнең балалары белән ерак Себергә сөрелүе, канлы репрессияләр, Бөек Ватан сугышы, ил кичергән авырлыклар, нахаксызлык аркасындагы зур югалтулар – барысы да аларны сындырмаганнар, Минем газиз туганнарым югалып калмаганнар, барлык авырлыкларны җиңеп, матур тормыш корганнар, балаларын хезмәт сөючән, телен, динен милләтен ихтирам итуче итеп тәрбияләгәннәр.

Мин – Алтынбаевлар һәм Кулеевлар нәселеннән. Безнең тормышның нәсыйхәте: таш белән атканга аш белән ат, тау белән тау очырашмый, кеше белән кеше очраша. Яхшылык җирдә ятмый. Минем ике балам: улым Айдар, кызым Җәмилә, оныкларым: Тимур, Артур, Марат, Мәрьям, Аскар, Әдилә, оныкчыкларым: Артур, Кәрим, Амалия, Радель, Регина

бар. Тимурның тормыш иптәше – Адилә, Артурның – Гөлназ, Маратның – Айгөл. Оныкларым татар кызлары белән никахлашып, өйләнештеләр Мин шуңа чиксез бәхетле. Минем нәселем исән-имин булсын, бәхетле булсыннар, татар булулары белән минем кебек горурлансыннар!!!

Казан шәһәре, Идел буе районы репрессия корбаннары оешмасы рәисе, Татарстан Республикасы репрессия корбаннары җәмгыятенең, Казанның тарих-агарту, хәйрия-хокук яклаучы «Мемориал» җәмгыятенең идарә әгъзасы, «Гөлҗамал» фольклор ансамбленең җитәкчесе

Кулеева Фәрзәнә Галләм кызы.
Октябрь, 2016 ел



*Мөхәммәтшәриф Әбүбәкер улы, Фәгыйлә Гани кызы Кулеевлар балалары белән, урталарында уллары минем әтием Галләметдин. 1912 ел*



*Галләметдин Мөхәммәтшәриф улы, Васфиҗамал Фәтхулла кызы Кулеевлар. 1937 ел*



*Кулеев Булат сеңлесе Фәрзәнә белән. 1943 ел*

*Кулеевлар :сулдан уңга Булат, Фәһмия, Фәрзәнә, Фәрхәнә 1944 ел, әтиемнең концлагерьдан кайтуына әле дүрт ел.*





*Кулеев Галләметдин Мөхәммәтшәриф улы дуслары «халык дошманнары» белән Углич төрмәсендә. 1946 ел*



*Тара шәһәре 8 нче номерлы татар мәктәбе пионер дружинасы. 1949 ел*



*Тара шәһәре Кулеева Фәрзәнә белән Алтынбаева Нурҗиһан. 1950 ел*



*Кулеева Фәрзәнә мәктәп мактау тактасыннан. 1952 ел*



*Яхеев Ильдус, классташым. 1953 ел*



*Апаларым – утыра Фәрхәнә, басып тора Фәһмия Кулеевалар. 1955 ел*



*Тара шәһәре татар урта мәктәбенең 1955 елгы чыгарылыш классы, укытучылары һәм директоры утыра икенче рәттә сулдан уңга Иштиряков Кафи Абдулла улы, класс җитәкчессе Варкентин Корней Арон улы*



*Тара шәһәре 8нче номерлы урта татар мәктәбе укытучылар коллективы. 1955 ел*



*Кулеева Васфиҗамал кызыФәрзәнә белән. Казан, 1956 ел*



*Кулеевлар: Булат һәм Фәрзәнә. 1956 ел*



Утыра Кулеева Фәрзәнә, Рожковаи Лидия, университет сабакташлары. 1956 ел



Кулеева Фәрхәнә Галләметдин кызы. 1956 ел



Сафин Айрат, Кулеева Фәрзәнә.1958 ел



*Кулеева Фәһмия Галләметдин кызы. 1959 ел*

*Кулеева Фәрзәнә, КАИ да укыткан чакта. 1968 ел*





*Кулеев Галләметдин, Кулеев Васфиҗамал уллары Булат гаиләсе белән. 1964 ел*



*Кулеева Фәрзәнә Фәһмия апам белән. 1969 ел*



*Галләметдин Мөхәммәтшәриф улы һәм Васфиҗамал Фәтхулла кызы Кулеевлар, Тара шәһәре. 1971 ел*



Кулеев Игорь Гайнетдин улы фән докторы. 1980 ел



Кулеева Фәрзәнә мәңгелек ут янында. 1982 ел



Әнием Васфиҗамал Фәтхулла кызы, әтием Галләметдин Мөхәммәтшәриф улы онықлары Рәшит белән



*Кулеева Фәрзәнә. 1983 ел*



*Сафин Айдар. 1986 ел*



*Фазлиева – Кулеева Җәмилә. 1986 ел*



*Беренче рәт сулдан уңга Фазлиев Марат, Сафин Артур, артта Сафин Тимур – оныкларым. 1991 ел*



*Тара шәһәрендә 8 нче номерлы урта татар мәктәбенең «Очрашу» бәйрәмендә. 1995 ел*




*«Очрашу» бәйрәмендә. 1995 ел*



*ТМУ икътисад факультетының беренче чыгарылышы, сулдан уңга утыралар икенче Рәхмәтуллин Рәфкат, Кулеева Фәрзәнә, Таҗиев Г. 1998 ел*



*Макаренко Мәрьям, оныгым.1999 ел*



*ТМУ икътисад факультеты деканы Кулеева Фәрзәнә. 1998 ел*



*Кулеева Фәрзәнә оныклары белән, утыралар сулдан уңга Артур, Мәрьям.Тимур, басып тора Марат. 2003 ел*



*Сафин Айдар үзе уйлап тапкан лазер-терапефт приборы белән. 2003 ел*





*Репрессия корбаннарына һәйкәл ачылган көн. 30 октябрь 2004 ел*

*Татарстан Республикасы көне, Кулеева Фәрзәнә, оныгым Мәрьям, Гаязетдинова Сания – якташым, якын дустым. 2004 ел*



*Оныгым Фазлиев Марат әнисе, сеңлесе, әбисе белән мәктәпне тәмамлаган көнне. 2005 ел*



*Идел буе районы репрессия корбаннары Г.Камал театры артистлары белән Кызыл Байракта, Сәйдәш бәйрәмендә. 2005 ел*



*Кулеева Фәрзәнә оныклары Әскар, Әдилә Сафиннар белән. 2006 ел*




*Кулеева Фәрзәнә – җырчы. 2007 ел*




*Халык җырла-
рын яратып
башкаручы
Кулеева
Фәрзәнә.
2007 ел*



*Халиков-Алтынбаев Рифкат Шафи улы хатыны, оныгы Юлия белән. 2007 ел*



*«Гөлҗамал» ансамбле: сулдан уңга Гөлсинә Хәйдарова, Мингазов Ризван, Нәҗипова Земфира, Кулеева Фәрзәнә, баянда Хәсәнова Фәүзия. 2008 ел*



*Идел буе районы репрессия корбаннары. 2008 ел*



*Архангел зиратында исемнәре стелаларда теркәлгән 1937-1938 елларда гәепсездән атылган «халык дошманнары янында». Хәтер китабы редакторы Иванов А.А., Корбангалина Н.Ю. 2008 ел*



*Кулеева Фәрзәнә улы Сафин Айдар белән. Вильнюс, 2010 ел*



*Кулеева Фәрзәнә 95нче Казан шәһәре мәктәбендә укучыларга репрессия гә дучар булган ата-бабалар турында сөйли. 2012 ел*



*Сулдан уңга Гөлназ, Артур, Тимур Аделя Сафиннар балалары белән 2012 ел, оныкларым, онықчыкларым.*



*Кызым Җәмилә Фазлиева һәм улым Сафин Айдар. 2014 ел*



*Туган тел көне, җырлый Кулеева Фәрзәнә, гармунда Әнвәр Гиниятуллин. Казан, 2015 ел*



*Фазлиева – Кулеева Җә-милә. 2016 ел*




*Оныгым Фазлиев Марат әнисе Фазлиева Җәмилә белән. 2015 ел*



*Оныгым Марат хатыны Айгөл, улы Радель белән. 2017 ел*



*Оныкларым Әскар контрабаста Әдилә скрипкада уйныйлар. Вильнюс, 2017 ел.*





*Сафиннар: Айдар, Даля, Әскар музыкаль мәктәпне тәмамлаган көнне. Вильнюс, 2017 ел*

*Онығым Марьям Казан Банк мәктәбен тәмамлаган көн. 2016 ел*

Эчтәлек

Кереш сүз .............................................................................. 3
1. Алтынбаевларның Себергә сөрелүе ................................ 7
2. Кулеевлар нәселе турында................................................ 20
3. Канлы репрессияләр – минем нәселем дә фаҗигасы ..... 25
4. Әтием дә сәяси репрессигә дучар булган ........................ 34
5. Әниемнең йорттан йортка йөрүе ..................................... 39
6. Бөек Ватан сугышында минем туганнарым
да катнашты ....................................................................... 53
7. Һич онытасым юк! .......................................................... 57
8. Әнием – нәселем йөзек кашы ......................................... 62
9. Мәктәбебез белем бирү генә түгел –
мәдәни-агарту үзәге дә иде ............................................. 76
10. Очрашу ........................................................................... 92
11. Иҗтимагый эш белән күп шөгыльләндем .................. 100
12 Тму – тормышка ашмаган иң зур хыялым .................. 116
13. 30 Октябрь – репрессия корбаннарын
искә алу көне ................................................................... 124
14. Татар халык җыры – моң чишмәсе ул 70..................... 152
15. Йомгаклау сүзе ............................................................. 161

Фарзана Кулеева

# Мама – драгоценный камень в перстне нашего рода

На татарском языке

Фәрзәнә Кулеева

# Әнием – нәселем йөзек кашы

Компьютерная верстка *Левина В.А.*

Подписано в печать 10.05.2017. Формат 60 х 84 1/16.
Гарнитура «Times New Roman». Усл. печ. л. 10,9.
Тираж 200 экз. Заказ 10.05/17.

Издательство Академии наук РТ.
420111, г. Казань, ул. Баумана, 20.